

Ркаил Зәйдулла

# Мәгарә

Шигырьләр, поэмалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос = Тат) — 5
З 87

**Зәйдулла Ркаил**

З 87 Мәгарә: Шигырьләр, поэмалар.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.– 351 б.

Ркаил Зәйдулланың яңа җыентыгы шигърият сөючеләрне битараф калдырмас. Күзендә Татар моңы булган һәркемгә дә юллана әлеге шигырьләр. Газиз халкыбызның язмышы хакында уйланулардан тыш, биредә – ихлас мәхәббәт хисләре, хушлашу сагышы һәм киләсе көнгә өмет...

ISBN 5-298-04083-7

© Татарстан китап нәшрияты, 2005



# I БҮЛЕК

*Көн кичкә авышкан иде инде. Башка кабарлык эссе сүрелгән, талгын һаваны дулкынландырып бераз гына җил дә исеп куйгандай булды. Әтәй кулындагы тустаганны читкә этәрде. Андагы чәй әле суынып бетмәгән – буы чыгып тора, шул бу белән тирәюньгә мәтрүшкә исе, тагын әллә нинди әтәй генә белгән үләннәрнең исе таралып, борын эчләрен кытыклый иде.*

*Әтәй чалгысын кулына тотты, янады, аннары, кискен генә селтәнеп, печән чаба башлады. Әле генә үзара ни турындадыр пышылдашып утырган кыяклар, каерылып, киң пакуска ава барды. Ә-әх! – әтәйнең шат, көчле тавышы бөтен болынны яңгыратты, кайтавазы ерак тауларга бәрелеп кире кайтты, үлән арасындагы чикерткәләр, өркеп, чык тамчылары сыман тирә-якка сибелеште. Әтәй киң алдырып алга бара, кояшта янган ялангач аркасындагы мускуллар нәни бурсыклар сыман бер-берсенә таба йөгерә иде.*

*Мин, учны җәеп, аның артыннан чабам, печән арасыннан сикергән эре-эре җир җиләкләре учыма төшә, битем, кулларым кып-кызыл җиләккә буялган иде.*

*Без шулай барабыз да барабыз, сызгырып чалгы чала, кыштырдап печән ава, кояш офыкка тәгәри. Алачык артындагы атыбыз койрыгы белән кигәвеннәрне куа, вәкарь белән генә пошкырып куя. Мавыгып-нитеп бик еракка китмәгез, янәсе. Болын киң, иркен, анау кызгылт офыкка ук барып тоташа.*

*Күз бәйләнә башлагач, әтәй учак тергезеп калды, мин, йөгерә-атлый, су буена төшеп киттем. Гөлҗимеш, карлыган куакларын, кураларны ера-ера биек ярга килеп чыктым. Аста каракучкыл су ашкынып каядыр ага, мине ымсындырып чакырып тора иде. Мин, чишенеп тә тормыйча, түбәнгә томырылдым, агымсуның кара куе яллары мине урап алды, гөрелтесе, уйларымны бүлеп, кан тамырларына күчте, астан бәргән чишмәләрнең салкыны йөрәгемне учына алды.*

*Мин шомланып күккә күз салдым, йолдызлар каядыр югалды, тик ярымай гына сиртмәле бишек төсле чайкала-айкала башлады. Җил чыкты, тыгыз дулкыннар мине ярдан читкә, билгесезлеккә өстерәде. Кулларымны ишкәк кебек ян-якка ташлап, мин ишеп тә карадым, тик еллар сыман аяусыз дулкыннар миннән көчлерәк иде шул.*

## ӨМЕТ

Кулын чәбәкләп йолдыз сикерә,–
тезләнеп эзен эзлим үзәннән.
Өзелгән җаннар сиздерми генә
сүземне көтә...
Мин тик бүзәрәм.

Бүзәрәм – офык читендә болыт
сискәнеп җилдә кымшанган төсле.
Серле үткелгә очар алдыннан
безгә бу төштә туктап үтешле.

Чыклы үләнгә чума бер чибәр,
кочагы кемгә диеп ачылган? –
Ябышып калам җиләк чеменә,
пакуслар монда балга манчылган.

Ябышып калам – ызан сизелми:
үкенеч белән өмет арасы.–
Офыкка кадәр пакуслар буйлап
сабый йөгерә...
сабый...
нарасый...

## ХӘЛВӘ

Элгәре хәлвә бик тәмле иде;
бик тәмле булып күренгән иде.
Сары кәгазьгә төрелгән хәлвә...

Җилне бөгәрләп
мин кесәгә салдым.

Чиратта торам.
Беләм тәгаен
сатып алачакмын...
Көз төсендәге зәгъфран кәгазьдә
әллә хәлвә, әллә бала чагым.

## БУРЫЧ

Мин бурычтан куркам гомерем буе.
Бурычлы булудан...
Нишлим, холык.
Мәҗүсидәй табынам мин җилгә.
Кызыктыра мине ап-ак болыт.

Газап булса булсын, азат яшә!
Мөмкин түгел...
Вакыт төшенергә:
Мин бурычлы, һәрберебез кебек,
Әниемә, күккә, кешеләргә.

# ТӨСЛӘР

Балачакның күп төсләре җуелган,
Ә бу –
Бүген булган кебек тоела.
Суларда чайкады апа керләрен,
Карап тордым шуны, өйгә кермәдем.
Бәләкләгән чакта күзләр чагылды,
Яктыртты ул балкыш тирә-ягымны.
Агара икән кер агымсуларда.
Тик куллар гына никтер алсулана...
Күз алдымнан китми менә һич кенә
Ике кызыл кисәү ак кар өстендә.
Ут каба калса керләргә әгәр дә,
Өйдәгеләр әзер андый хәбәргә.
Мине генә борчый: очкын эләгеп
Янып китмәсен, дим, юган күлмәгем.
Тәрәзәдән карый әнкәй килә дә.
Керергә вакыт җиткәндер өйләгә.
Мин, ахрысы, ул көн шуны искәрдем:
Суларда чайкады апа хисләрен.
Ут каба калса карларга әгәр дә,
Ике алма кайсы якка тәгәрәр?..

## БАБАЙ

Шәфәкъләрдә алма алсулыгы.
Сыер мөгри якын-тирәдә.
Авылыбызга төн иңүен көтеп,
Без ятабыз дымлы чирәмдә.

Еллар үткән саен шул күренеш
Күз алдыма килә.
Кочакка
Арадагы барлык көнне җыеп,
Кузгаласы иде шул чакка.

Тырыштык без тизрәк караңгыны
Тартып төшерергә чирәмгә! –
Без яткан җир күршедәге картның
Алма бакчасына терәлә.

Теңкәбезгә тия алма исе.
Татлы да соң алма татлысын,
Эте бар шул.
Без беләбез аның
Алмаларны уяу саклыйсын.

Миңа гына бары койрык болгый.
Төшенә калса эшнең серенә,
Ул миңа да өрер иде, бәлки...
Җөрьәт итми ләкин өрергә.

Шуңа күрә гел мин генә керәм,
Кирәк түгел безгә жирәбә.
Шәфәкъ кебек алсу багалмалар
Тәгәриләр дымлы чирәмгә.

...Иртән мине бабай дәшеп ала.
Әллә нинди генә ул бабай –
Алма суза. Һәм нигәдер минем
Йөзем алсулана алмадай.

Еллар үткән саен шул күренеш
Күз алдыма килә.
Кузгалам
Кочагыма җыеп көннәремне...
Ул шул иде минем үз бабам...

## ӘБИ

Нидер көйли бер почмакта, намазлык өстендә,
шул безелдәү генә, болай тып-тын йортта...
Ике өйне бер итеп йөгереп йөргән хатын –
карт әнкәем?! Шулмы соң бу кортка?

Мине искәрми дә, утырган да бер почмакта
иренenә кысып Коръәннең бер аятен.
Ике өйне бер итеп хәзер яшь килен йөгерә,
Моның – бер намазлык бөтен вилаяте.

## ЯЗ — 1979

Торналарның эзе калды күктә,
Кыйгылдашып кайтты киек казлар.
Ярсып түгел, күкрәп түгел, әмма –
Быел да, дим, язлар килде, язлар.

Күнеккәнбез дәртле, ярсу язга –
Ә кояшсыз ярсып булмый икән!
...Сыерчыклар тынып калган, суык,
Һәм башларын таллар түбән игән.

Яз түгелдер, көздер, димен, көздер –
Кочып алган җирне куксел томан.
Утырып калган бозлар, туган җирдә
Шул язмыш та рәхәт, дигән сыман.

## КАЕН КЫЗЫ

Төш җитә бит инде, каен кызы,
Ә син менә һаман йоклыйсың...
Уян инде, сине сагындым мин,
Чәчләреңнән килә сыйпыйсым.

Зәңгәр күктә ак болытлар эри,
Җирне назлап җылы җил исә,
Уян инде, йоклап каласың ич,
Шушы гүзәллекне күрмичә.

Кошчыклар да синнән көлә әнә,
Ямансулый кояш, уртәлә...
Уян инде, кызый. Бу табигать
Бүтәнчәрәк булыр иртәгә.

# УЕН

Бер шук малай күршесенә төртте.
Болай гына. Юк кинәсе, үче.
– Тапшыр! – диде.
Китте шулай йодрык,
Бер күршедән бер күршегә күчеп.
Нәни кулы белән төртте кызый –
Болай гына. Уенда юк кинә...
– Тапшыр! – диде.
Китте шулай йодрык
Бер кешедән бер кешегә кинәт.
«Йодрык белән муен тамырына!» –
Уеннарның була шундый төре.
Әллә берсе уйлап тапкан,
Әллә
Шаяралар олылардан күреп.
– Тынычлык! – дим синең колагыңа!
Син – күршеңә! Кагыйдәне үтә:
– Тапшыр! – диген.
Һәм яхшы сүз,
Иң кирәк сүз бүген,
Тоткарлыксыз дөнья буйлап китәр.

## ҮЗГӘРЕШ

Иртән торсам, бөтен дөнья үзгәргән!
Эт тә хәтта бүтәнчә өрә –
аның янындагы мөлдерәмә тазда
кояш су керә.
Иртән торсам, бөтен дөнья үзгәргән.
Иң гаҗәбе: үзгәргән күрше кызы –
Тәнзилә...
Мин дә үзгәргәнмен...
Теләкләрем бүтән –
бер биисем килә, бер җырлыйсым...
Һәм елыйсым килә аз гына...
Иң гаҗәбе: эндәшәсе килә
Тәнзиләгә – күрше кызына.

## ДӘРЕС БАРА

Сузыла куллар...
Учларга «күгәрчен» килеп төшә,
сизми кала укытучы.
Маршрутлары элеккечә:
«Малайлар – кызлар»,
«Малайлар – кызлар».

Дәрес кайгысы – иртәгә.
Язга авышкан көннәр.
Чәчкә тиеп очып үтә
ул кәгазь «күгәрченнәр».

Кызлар кызаралар күргәч,–
хискә тиядер, күрәсең...
Кәгазьләрдә шул бер рәсем югыйсә:
пар күгәрчен.

## САБАКТАШ

Тукай шигырен без ятларга тиеш.
Болай үзе озын түгел дә...
Тик бер дустым һич яратмый шигырь.
Ятламый да...
Лутчы сүгенә.

Ул калыккач, барыбыз да тындык.
Булыр микән, ай-һай? Шик керде...
Сөйли теге... Туктый-туктый булсын,
Ерып чыкты тәки шигырьне.

Мәктәп белән сөендек без ул көн.
Шигырь җиңде, имеш. Ә чында
Сер бик гади – без соңыннан белдек –
Сыйган шигырь аның учына.

Тракторда хәзер эшли бугай.
Һаман шундый – әйбәт сүгенә.
Күрешкәндә кочак җәеп килә...
Болай үзе начар түгел дә.

Күңеле дә нечкә. Учларында
Өзек-төтек тормыш сызымы.
Анда хәзер Тукай шигыренең
Сыяр иде иң-иң озыны.

* * *

Типте тупны шаян малай –
Күңеле алгысынган!
Югалды туп офыкларда
Кичке кояш сыман.

Кара урман карынында
Шулай төн яралды,
Дәү имәннәр арасыннан
Сузылып чыкты караңгы.

Шулчак усак ботагына
Элэгеп калган яктылык
Малайга тел күрсәтте дә
Күккә менде атылып...

Ә малай?
Чөйде өскә түбәтәен,
Чөйде – менә нишләде!
Чәчелде күктә яктылык.
Тик түбәтәй, тик түбәтәй
Җиргә кире төшмәде.

Менә нишләде...

# КӨТҮЧЕ МАЛАЙ

*(Бүгенге әкият)*

Шик төште күңелемә, тик
Башладым җөрьәт итеп.
Гыйбрәтле сүз, ләкин менә,
Йомгак сүткәндәй сүтеп,
Бу сәер вакыйганы
Ничек калыпка саласы?
Кайда, кайсы олысларда
Әсәрем бисмилласы?
Эш шунда ки, кереше юк,
Ахыры да юк аның!
Күрәм диеп кергән идем,
Чыгалмадым, югалдым.

Әйдә, син минем белән!
Сине дә алып керәм!

Борын-борын заманда, дип,
Әкиятләр башлана.
Яисә берәр изге затка
Риваять багышлана.
Монда ул юк. Һәрбер сүзне
Һәркемгә багышлавым.
Фәрештәләрнең ишет син
Канаты кагышларын!

Йә, ияр, ярән бул миңа,
Әсәрем сиңа таман.
Әллә бүгенге заман бу,
Әллә киләчәк заман.
Ияр!
Тиз!
Сүз иярендә
Җилдерик бер тагын да,

Кояшлы, айлы, йолдызлы
Әкиятләр ягына.

* * *

Беркем дә аның шикелле
Чыбыркы шартлаталмый!
Үләннәр беренче булып
Аның табанын таный.
Ул белми әле никадәр
Яратуын дөньяны.
Шуңа күрә дә кешеләр:
«Көтүче!» –ди бит аны.
Аларның да бу җиһанда
Була, дөрес,төрлесе:
Сарык йә дуңгыз көткәне...
Ә бу – ат көтүчесе!
Булса да бер үк кавемнән,
Үзгәлеге нидә соң? –
Ул көтә...
үзенә...
кучүен
Атлар күзендәге моң.
Сары яфракларның суда
Чагылуларын көтә.
Камылларның табанына
Кагылуларын көтә.

Көтүче һөнәре болай
Кызык ул кызыгын да...
Тик менә... ачу килгәли
Көннең озынлыгына.
Үзәккә үтә кайчакта
Чамасыз яңгырлары.
Төмсә куккә карый-карый
Малай күп каңгырады.

Малай да малай, дим һаман,
Дикъкатьсез исеменә:
Дәян ул!
Туры киләме
Исеме җисеменә? –
Әйтә алмыйм. Мәгънәсе ни?
Төшмәде бит искә дә...
Гомәр Саттаров китабы
Юкка чыккан киштәдән.

Актырнак атлы эте бар –
Назланып борынын суза.
Усал булсын, өрсен диеп,
Койрыгын кискән хуҗа!
– Теләсә кемгә болгамас! –
Дип күкрәк каккан, имеш...
Тик эттә чебен куарлык
Койрык булырга тиеш!
Көтүчегә шәп эт кирәк!
Бер дусты киңәш биргән...
Киңәш тотып, Дәян этен
Мунчага алып кергән.
Дусты кычкырып калган, ди:
«Ташына күбрәк су сал!
Мунчада чабынган этләр
Булалар, ай-һай, усал».

Ләүкәгә менгереп аны
Әй чапкан, чапкан Дәян.
Эт... яткан, ди, рәхәтләнеп.
Ә Дәян... хәлдән тайган.
Актырнагы атна саен
Килә мунча янына.
Өреп куя. Ул, күрәсең,
Шул ләүкәне сагына.
Эт турында күп сөйләдем.
Әйтмә: «Тукта, булмаса...»

Бит әсәрне башлавыма
Эт сәбәпче ләбаса.
Үз йомышы белән бу эт
Яр буена килгән, ди.
Ә анда... ишелгән ярда
Зур бер чүлмәк күргән, ди.
Гаҗәпләнгән хәтта эт тә:
Юкмы күз буу, ялган?
Әллә чынлап хәзинәме,
Шәкүр карактан калган?!

Дәян да килә. Чүлмәкне
Күтәреп карамакчы.
Ай-һай авыр!
Башын кашый,
Кузгатып булмый, бакчы.
Язулы мөһер капкачта.
Укый алмый, шыр надан!
Күмгән кеше дә хәйләкәр:
Уңнан сулга сырлаган.
Шул язуны белеп кенә
Укыйсы иде менә,
Ачылып китәр иде шулчак
Хикмәтле чүлмәге дә.
Дәян озак уйлап тормый.
Мәктәпкә йөрми тәккә –
Башы бар! Бер ташны алып
Ора авыр чүлмәккә.
Чәлпәрәмә килә чүлмәк,
Чәлпәрәмә килә көн,
Ватык өемнән җай гына
Сузылып чыга төтен.
Бер сакаллы, пәйда булып,
Төтеннән күтәрелә.
Тамагын кыра, гүяки
Әйтерсең бер зур түрә:

«Әй, егет, мин бу дөньяның
Мең төрле серен беләм.
Алып кайт син мине өйгә
Серләрем-нием белән!
Күрешмәс идек дисеңме,
Тапмаса әгәр этең?
Ялгышасың,
Мин бит сине
Гасырлар буе көттем!
Өмет иткәнсеңдер әле
Таптым дип алтын-фәлән.
Борчылма, һәр минут саен
Хәзер мин кыйммәтләнәм!»

Дәяннарның өе тып-тын
Каршы ала кунакны.
Актырнагы вәкарь белән
Кәнәфигә кунаклый.
Дөрес булмас сакаллыны
Бик кыяфәтсез дию.
«Сизгәнсеңдер,– ди Дәянга,–
Булам мин – абзаң Дию!
Этеңнең койрыгын кискәч,
Якынайдың син миңа.
Булдыклы бәндә булырга
Калмас бу, дидем, соңга.
Дустыңның каләмен чәлгәч,
Кыскарды тәмам ара.
Бу тәвәккәл егет кенә
Мине, дидем, коткара.
Син – малаем булдың хәзер,
Мин сиңа булдым ата!» –
Шулай диеп, Дию абзый
Диванга кырын ята.
Тәмәке каба авызына,
«Тартканым юк,– ди,– мең ел!»

...Ул синең әфәндең хәзер.
Ә син Дәян – кол!
Кол! Кол!
Тик шундый кол – ни теләсәң,
Барсы тормышка ашар.
Бал-май эчендә йөзәрсең,
Колбаса гына ашап!
Дәян көлә: «Бездә ит күп,
Тансык түгел ит миңа.
Булдыралсаң, бүтән бирәр
Нәрсә тәкъдим ит миңа.
Берни эшли алмассың шул
Син, Дию, минем өчен».
Ни майтара алыр икән,
Янәсе, сихри көчең?
Дию әйтә: «Көндәлеккә
«Ике»ле төшсә әгәр,
Өйдәгеләргә күңелле
Булмас бит мондый хәбәр.
Мин сиңа канат бирермен.
Кагылсаң шуның белән,
«Биш»леләр генә калырлар
Бер букча «ике»леңнән.
Шаркылдап җибәрә Дәян:
«Мин аның серен беләм –
Юдырып кына төшерәм
Химик сыекча белән!»
Һәм Дию кала тотлыгып,
Химиядән чи надан.
Ни дисәң дә, Дәян сыман
Дию бит укымаган.

Малай да шактый хәйләкәр,
Мыскыллый юри генә:
«Син,– ди,– Дию түгел бугай,
Ахрысы, пәри генә».

Диюнең дә нервысы бар.
Кимсенеп сала сөрән:
«Ә син башта җаныңны ач,
Түренә үтеп керәм!
Сихерем артыр йөзләтә,
Артыр синдә мәкер, кер.
Без икәүләшеп дөньяны
Таңга калдырырбыз бер».

Якынлаша ул Дәянга,
Җилкәсенә кагыла.
«Өегез дә, сарай сыман,
Балкып торыр авылда.
Булыр ул биек капкалы,
Салырбыз аны таштан.
Әйтәм ич, һәрбер теләгең
Булыр тормышка ашкан».
Шундый зур форсат барында
Риза бул бары, кавыш.
Ләкин шулчак ишетелә
Атлар кешнәгән тавыш.
Искә төшә йолдызлы күк,
Чыклы үләннәр күзе.
Атлар кешни, атлар кешни...
Их, булмый, булмый түзеп.
Ә Дию пышылдый һаман:
«Киңәшемә сал колак!»
Кайтавазы: кол... кол... а-а...
Җавабы: Олак! Олак!

Дерт итә малай. Кузгала.
Ни соң бу, әллә төшме?
Дию факыр да юк түрдә,
Бүлмәдә юк бер кеше.

* * *

Шул вакыт ишек ачыла.
Ә аннан аңа таба
Бер сүз дә эндәшми-нитми
Атлый бер ап-ак бабай.
Өстендә яшел чапаны,
Кулында яшел таяк.
Бу тарафка каян килгән,
Китеп барышы кая?
Башыннан сыйпый малайның,
Каршына килеп басып.
«Җаның шулай чиста калсын,
Күңелең булсын ачык.
Дөнья шундый, улым.
Фәкать
Бер кырын адым яса, –
Күңеленә өере белән
Диюләр якынлаша.
Ә мин андый диюләрне
Тотып чүлмәккә ябам.
Аны кыек эш эшләгән
Кешеләр генә таба.
Сау бул, Дәян. Ашыгам мин,
Югыйсә Дию тагын
Юл чатында калганнарга
Салыр үзенең сукмагын...»

...Дәян атлары янында,
Ул монда, кабат монда!
Очып килде әйтерсең лә
Хыялы канатында.
Йолдызлы күк. Җилләр исә.
Ай балкый, китә йөзеп.
Атлар кешни... Атлар кешни...

Их, булмый, булмый түзеп.
Әкияти бер чынбарлыкта
Елады ул, җырлады.
Сөенеп өреп җибәрде
Өтек эт – Актырнагы.
Бу ни хикмәт, койрыгы бар,
Шатланып болгап тора,
Борынгы, иске җыруны
Ис китеп тыңлап тора.

Кайчак, айны күләгәләп,
Күктә болытлар ага...
Күренеп ала шулвакыт
Болында ап-ак бабай.
Яшел чапанын бөркәнгән,
Тоткан яшел таягын...
Безнең гөнаһлы җаннарны
Аясын ул, аясын...

## КАЧКЫН

Сукранып йөри әни,
Ырыс капка – шыр ачык,
Сыер тагын түзмәгән,
Көтүдән кайткан качып.

Уйлана бугай үзе,
Моңаеп башын игән,
Аркасында алсу эз –
Нидән икән, ни икән?
Чыбыркы эзе микән?

Алсу чыбыркы эзе!
Күзендә моң диңгезе –
Кеше сыман башын игән,
Хафаландырып безне.

Сызланадыр...
Әрнидер.
Авыртадыр ла тәне.
Кыйныйлар шул
Көтү белән
Йөрисе килмәгәнне.

## МӨГЕЗДӘГЕ ЙОЛДЫЗ

Яңа ел кергән, ди, ул көнне җирдә,
Ул көнне җирдә булган бәйрәм.
Ул көнне йолдызлар да бәйрәм иткән күктә –
Алар да уйнаган әйлән-бәйлән.

Бер шаяны шунда сикергән, ди, җиргә...
Дуслары югалткан аны –
Йолдыз югалган!

...Ә ул ихатада торган сыерның
Озын мөгезенә эләгеп калган.

Мөгездәге йолдыз чәчкән икән нур,
Булган, ди, шунда, әй, күңелле!
Әйлән-бәйлән уйнаганнар
Сыер тирәли
Ике малай һәм берсенең сеңлесе...

## ХӘБӘР

Өйдә һәммәсе дә бер уйда иде,
бер атна вакыт бар, диеп, тагы...
Унбер яшьлек малай гына менә
алай уйламады.

Ә олылар? Алар ялгыш уйда
йөргәннәр икән кайчаннан бирле.
Малайга сөенеч: сөтлебикә
нәкъ бу таңда бозау китерде.
Шулай менә!

Өлкәннәрнең борынына чиртте малай!
Ул нарасый түгел инде, янәсе.
Күпме гомер көтеп кара син
элпә каплаган ул җан иясен.
Шулай менә...

Ә олылар? Алар ялгыш уйда
йөргәннәр икән кайчаннан бирле!
Малайның тантанасы: дус кызына
хәбәр сөйләргә йөгерде.
Шулай менә.

# МАЛАЙНЫҢ БОЗАУ БЕЛӘН ХУШЛАШУЫ

Бозау муенына ыргыттылар элмәк
Әти белән күрше Сабир абзый.

...Базар көне. Тотып элмәгеннән
Бүген аны алып китәләр миннән.
Бу – көз инде, моңсу чагы җирнең.
Мин бит...
Бозауларга дөнья киң дип йөрдем.
Яфрак коела.
Яфрак коела юлларына.
Бар да әйбәт... Ничек түзәр соң анасы?
Кешеләрнең ит ашыйсы килә икән.
Мин еламыйм.
Мине кочып
Елый капка баганасы.

# АВЫЛ МАЛАЕ

Ни ара тагын көз килгән –
Торналар китеп бара...
Очасы иде ияреп
Күз күрмәгән якларга –
Ерак-еракларга.

Минем күрше авылны да
Күргәнем юк бит юньләп.
Кузгалырга иде менә,
Төенчекне төенләп,
Күз күрмәгән якларга –
Ерак-еракларга.

Сыерым бар шул минем,
Аны кирәк сакларга...
Шуңа китә алмыйм инде
Күз күрмәгән якларга –
Ерак-еракларга.

Ерак-еракларга
Торналар китеп бара,
Дөнья киң шул аларга...

## ЯҢГЫР. БОЛЫН. АТ

– Синең йокы сәгатең...– ди,–
Йокла,– ди әни,– миңа.
Ә яңгыр ява, ява,
Ява да... Җиргә сеңә.

Тамчылар күктә, һәрберсе
Нәни кояшлар хәтле,
Һәммә кеше, шулар сымак,
Елмая башлар әле!

Ничек йоклап ятмак кирәк –
Мин чыгып сыздым өйдән.
Тиргәсә тиргәр әнием,
Бу көн бер генә килгән.

Тездән су ерып йөгердем,
Болынга... дөнья башка!
Орындым йөрәгем белән
Яңгырга һәм кояшка.

Бөҗәкләр яфрак астында...
Яңгыр элпәсен ертып,
Ат утлап йөри болында...
Хыялымны куертып.

Көндез йоклап ятулары
Егет кешегә оят.
Болында ат утлап йөри,
Тышаусыз, йөгәнсез ат.

## ТӨНГЕ РӘСЕМ

Хуш исле печән җәелгән
Арба теркелди юлдан.
Хуш исле печән өстендә
Малай йокыга талган.
Янәшәсеннән баралар
Абыйсы да әтисе...
Ә дөнья...
Дөнья шундый –
Дөньяда чәчәк исе.
Мәңге онытылмас бу төн.
Сәхра, йолдызлар, ирек.
Нарасый бара арбада,
Әнисен төштә күреп.

## РӘХМӘТ

Бүген минем туган көнем!
Шәп тә соң туган көндә:
Кичә мин гадәти идем,
Ә бүген –
Игътибар үзәгендә!

Минем өчен генә бары
Яралган икән ул көн:
Нәкъ әниләр ындырына
Ташлап калдыргач төлке,

Тапканнар мине...
Сөенәм
Тирәнгә керми генә.
Рәхмәтләр укыйм дөньяның
Хәйләкәр төлкесенә.

* * *

Карт этне алып чыгалар
авылдан...
Төн.
Бабай да малай гына.
Төбәлә бабай мылтыгы
карт этнең маңгаена.

Бетәшкән, өрми, йоклый тик,
теше коелып беткән.
Арынмакчылар файдасыз,
күзләре дымлы эттән.
Маңгаенда кара тишек,
мылтык тавышы кырда.
Бабай канәгать – куллар шәп!
...Оныгы карап тора.

...Кузгалалар өйгә таба.
Дәшмиләр, никтер читен...
Кайталар җуеп
дөньяның
күзләре дымлы этен.

* * *

Өй артында өнсез-тынсыз эт оясы...
Почмагында йомарланып йоклап ята
җан иясе.

Җылы сулыш чыга суырылып оя
төннегеннән...
Сукбай мәче бүген монда кунарга дип
кергән.

Төн эчендә өнсез-тынсыз эт оясы...
Дөнья белән алыш-биреше юк аның,–
үз дөньясы.

...Сискәнмидер инде хәзер шәхесләрнең
ае...
Ләң-ләң килеп атылып чыкмас аннан
эт малае.

Төнге күккә, хуҗа абзый, караганың
бармы?
Этең хәзер ләң-ләң килеп коймый инде
йолдызларны.

Өй артында эт оясы, җиргә сеңгән...
Җылы сулыш чыгып ята төннегеннән.

Өй артында өнсез-тынсыз, өнсез-тынсыз
эт оясы...
Почмагында йомарланып йоклап ята
җан иясе.

# СӘРБИ КУАГЫ ТУРЫНДА ТҮГЕЛ БУ ШИГЫРЬ

Искә төште авыл,
өебез каршындагы
тузан кунган сәрби куагы,–
шул тузанлы килеш күңелемдә ул!
Һәркемгә дә газиз туган ягы:
инешләре аның, кызыл яры,
сыер ирене тигән ромашкалар,
шау тузанлы сәрби куаклары.
Һәркемгә дә газиз туган ягы.
Төште искә, моңсу булып китте,
кочаклыйсым килде
шау тузанлы сәрби куагын.

Аның хакында беләләрдер кешеләр,
сез әйтерсез, әгәр белмәсәләр,–
шау тузанлы сәрби куагы ул!
Аның турында мин
язмак булдым гаҗәеп бер әсәр.
Әмма минем тынчу тар бүлмәмдә
сүз башыннан йөри бәла-каза,
аңым ялкынсынды, аңа карап
ник ике сүз төшсен ак кәгазьгә...
Дөньялыктан аллергия йөздә,
язылмаячак, күпме генә аһ ор-
саң да!
...Әни бүген төштә
мине тагын шәрә күрер, бахыр...

## КАЗ ӨМӘСЕ

Атлар чаба урамнан,
Чалулый чаналары.
Җилдерәләрме белеп,
Белмичә чабалармы?

Каз өмәсе ич бездә.
Карда – каз түшкәләре.
Саклаган бәбкәләрем
Исемә төшкәләрме?

Каурый-каурый кар ява.
Җырлары апаларның
Тылсымлыдыр...
Бикләре
Коела капкаларның.

Фәрештәләр тирбәлә
Көянтәле иңнәрдә.
Кемнәргә килен төшәр
Басып яңа мендәргә...

Җиргә иңәме җырлар,
Һаваларга ашамы? –
Тальян тавышларында
Казлар каңгылдашканы.

# ТУПЫЛ

Дерелди салкын җилдә
Назлы тупыл агачы.
Авылда җилләр усал,
Авылда җилләр ачы.

Ташлаган да киемен,
Белми кайдан эзләргә.
Сулар ята җыелып
Яфрак төшкән эзләрдә.

Дерелди тупыл.
Җилне
Ничек тыясы менә?
Җылыталмый бит инде
Карга оясы гына...

Назлы тупыл кызына
Карга оясы чит тә...
Ләкин көзге яңгырда
Аңа да чират җитә.

Мондый көзге яңгырда
Кош оясы да – бүрек.
Чәчләрне саклар иде
Киялсаң әйләндереп.

Тимәс иде йөзенә
Яңгыры да, кары да...
Ләкин тупыл кызына
Бер язгы уй сарыла:

Җитәр бит, җитәр ул яз –
Каргалар хәбәр салыр...
Мөлдерәтеп бөресен,
Тупыл кызы оялыр...

Тик инде бу тирәгә
Өзелер кошлар юлы...
Һәм тупыл сылуына
Бик тә күңелсез булыр...

## БУРАН

Көтмәгәндә килде буран,
Бөтерелде бар җирдә.
Теләде бетмәс куәтен
Дөньяга күрсәтергә.

Дулады: у-у-у...
Янәсе,
Биетә урман-кырны.
Өстән аңа мәгърур карап,
Имәннәр көлеп торды.

...Сакалы эри башлагач,
Эзләп китте төньягын.
Ә юлында... сынып калды
Япь-яшь чия куагы.

# КЫШНЫ ОЗАТУ

Ап-ак киңлекләр!
Офыккача кар...
Шулкадәр якты, якты, яп-якты.
Әй чапты атлар шул киңлекләрдән,
Туктамый чапты,
чапты,
чапты,
чапты.

Башланды фасыллар талашы!
Күктән җиргә ауды
Җирән алаша,
аунады...
Үкенечкә калмады –
Яллары офыкка сибелде,
Ябагасы карга:
Җем-җем! Җем-җем!
Сузылдылар язга
Күгелҗем урамнар.
Ә анда
Ап-ак киңлекләр!
Офыккача кар...
Шулкадәр якты, якты, яп-якты.
Әй чапты атлар шул киңлекләрдән,
Туктамый чапты,
чапты,
чапты.

# КӨРӘШ

Җил илереп елый.
Тилеләрчә көлә.
Нинди уй кузгаткан аны?
Нинди юләр теләк?

Килмәде дә башка!
Кермәде дә төшкә!
Күрмиләр – агымсуларның
Күзенә ак төшкән.

Көләч, мөлаем, дип,
Нигә алдап язу?
Минем кебек үҗәт
Һәм куәтсез яз бу.
А, мәңгелек көрәш!
Белмим, кайда кыйбла?
Ялгыз алмагач
Тәрәзәмә сибелә.

* * *

Бәреп чыккан дөньялыкка
талның тамырлары.
Өстә эссе икән, кая
җәйнең яңгырлары?

Коргаксыган, сузыла күккә,
саумы, дөнья, саумы?
Кояш кына баса алмый
икән бу сусауны.

Сызлагандыр тәне, бәлки,
телеп-телеп-телеп –
кисеп алдылар тамырны
оста куллар килеп.

Кисеп алдылар тамырны,
үзе чыккан, уңай...
Ул рәссамга Шүрәлене
хәтерләткән бугай.

...Коя, коя дөньялыкның
җылы яңгырлары.
Тәрәзәгә сарылганнар
талның тамырлары.

# ЗИЛЗИЛӘ

Телен асылындырып,
Кечкенә көчек сыман,
Мыштым җил шуышты башта
Үләннәр арасыннан.

Аннан куерды болытлар,
Кыңгыраулар чыңлады.
Гөрселдәде барабаннар.
Барсын да күрдем,
тыңладым.

Элдерде көн дә хушлашмый,
Соры киемен киеп.
Егылып кычкырды берәү –
Булгандыр, бәлки, бөек.

Тавышы бәрелде болытка,
Яңгыр җиргә савылды.
Каравыл кычкырып кына
Туктатып булмый давылны.

* * *

Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр,
Нәрсә әйтер туганнарыма?!

*Х.Туфан*

Түбәдә шыбыр-шыбыр яңгыр
тамчылары,
Яңгыр тамчысының әйтер сүзе бармы?
Чоланда – мин, ә тышта – күк,
өянкеләр, авыл.
Тыңлап ятам дөньяны, яңгыр
шыбырдавын.
Сибәли дә тора тынлык күкрәгенә –
Әкиятидер бу яңгырның күренеше,
Тик тәрәзә юк шул.
Әмма сизенәм мин –
Яңгыр тамчысында күз яшенең төсе.
Ачып булмый каерып – юк шул тәрәз.
Өянкеләр күккә дога кыладыр.
Ә һава исә...
Гаҗәп бит – бу безнең үзгәрмәс мохиттә
Яңгырдан соң... һава... сафланарак төшә!..
Түбәдә шыбыр-шыбыр яңгыр тамчылары,
Эзлиләр тәрәз, вакытны җилтерәтеп...
Кайдандыр хәбәр алып килгәннәрме
алар?
Кемнәрнеңдер сәламенме китергәннәр?

# ПЕЧӘН ӨМӘСЕ

1

Пакуслар офыкка кадәр!
Татарныкы – чалгылар.
Шул чалгыны кулга тотып,
Болын буйлап бар да бар...

Элгәре дәрт баш күтәрә,
Тамырларда кан уйный.
Кистереп кенә төшерә –
Чалгылар – кылычмыни!

Учка кысып чалгы сабын,
Бер адым алга күчәм;
Нәкъ безнеңчә чалгы чыңлый,
Безнеңчә ава печән.

2

Пакуслар, хыяллар кебек,
Офыкларга тоташа,
Болын буйлап йөгерә сылу,
Күңелләр
        таша,
            таша...

Чалгыны ташлап калдырам,
Элгәре дәрт тамырда,
Онытыла дөнья гаме,
Утлы караш – яндыра.

Омтылам аның артыннан,
Йөрәгем кага – тоймыйм.
– Сөям! – дип шашып кычкырам,

Кайтаваз килә:
– Сөй-мим!

...Офыкка китеп югалды,
Җәлләде карашын да.
...Яраланган өмет кебек
Ятып калды баш яулыгы
Пакуслар арасында.

3

Болында печән өмәсе,
Болында бүген бәйрәм.
Мичкәдә сыра күперә,
Тустаганнарда – әйрән.

Эңгер шикелле җәелә
Җиргә түгәрәк табын.
Кызлар җыры. Шат авазлар.
Минем моңайган чагым.

Ишетелә чак-чак кына
Җирдә гомер агышы...
Һәм кызмача агайларның
Чәрдәкләнгән тавышы.

Ә чалгылар йоклый. Төн бит.
Монда тын, рәхәт. Кадер.
Авыр сулый пакус арасында
Онытылган хәтер.

4

Пакуслар, хыяллар булып,
Тоташа офыкларга.
Болын буйлап йөгерә сылу,
Әй, егет, куып кара!

Пакуслар офыкка кадәр!
Офыкка кадәр өмет...
Учка кысып чалгы сабын,
Әй, селтән, селтән, егет!

Басылмасмы җан әрнүләр,
Йөрәкнең сулкылдавы?!
Чалгы йөзендә – далалар,
Кара урманнар шавы.

Барыбер куып тотар ул,
Йөгермә, сылу, юри –
Синең якка таба аны
Чалгы үзе өстери.

Учка кысып чалгы сабын,
Бер адым алга күчәм.
Нәкъ безнеңчә чалгы чыңлый,
Безнеңчә ава печән...

## АЛМА БАКЧАСЫНДА

Төнге бакча тып-тын юкса...
Чишмәләрне уятып,
Шул тынлыкның күзләреннән
Алма тама тып та тып.

Үләннәрне сыйпап үтә
Төннең сихерле тыны.
Алмалар булып коела
Серләремнең ыртыны.

Көзләр шундый сагышлы ла
Өйдә, туган ягымда:
Алма ауганда чыккан җил
Чәчләремә кагыла.

Чемнән өзел тик, кул изи
Нәселең, ыру-җыгың.
Алмалар җиргә егыла
Чәчерәтеп орлыгын.

Ә без күккә үреләбез
Югыйсә гомер бакый.
Мәңгелекне дәгъва итеп
Алмалар җирне шакый.

* * *

И серле күл!
Карашыңда
Нинди сагыш, нинди моң?
Син шат идең,
        көлә идең,
            уйный идең, –
ник тындың?

Елмай инде,
и серле күл, –
Җиребездә әле җәй!

...Сыңар балык очты ярга –
күз яшедәй...

* * *

Язмышларны иңнәренә алып
Чаба җилеп, чаба чаптарлар...
Юллардагы тояк эзе кебек
Сибелгәннәр икән татарлар.

Тарта мәллә һаман туган җирләр,
Әллә тарта шушы зур бәйрәм,–
Авылдашлар кайта сабантуйга,
Авылдашлар кайта читләрдән.

Шушы изге сабантуйлы якны
Читкә кит тә, имеш, оныт, бар...
Авылдашлар кайта туган җиргә,
Балалары кайта, оныклар.

Авылдашлар кайта. Туган телдә
Теттерәләр, иеп чал башны.
Якын алар миңа. Ләкин читен
Балалары белән аңлашу.

Авылдашлар кайта сабантуйга,
Безнең бәйрәм.– Хәтта мәйдан тар.
Еллар үтә.
Моңсу.
Авылдашлар.
Алар да бит кайтмый башларлар.

# БУЛМЫЙ ЕЛАП

*(Балачакны хәтерләп)*

Мин иярдә!
Ат өстендә беренче кат.
Талгын гына аккан каным, уян!
Алты яшьтә мин үземне менә
Тәүге тапкыр егет итеп тоям.
Ана сөте белән кергән бу хис,
Йөрәгемдә яна тояк эзе.
Гомер буе гел янәшә йөргән
Татар белән ярсу толпар сүзе.
Томырыла атым.
Җан калтырап
Ялларына аның ябышканмын.
Тик шулай да рәхәт!
Тыны кысылып
Артта калган чагы сагышларның,
Якынайган чагы кояшның!
Томырыла атым.
Хәтерендә
Чыңгыз хандыр аның,
Атилладыр...
Ә мин башка, башка.
Күңелдә дә
Бердәнбер җыр бары, бердәнбер җыр:
«Егылмаска, егылмаска!»
Чорлар ни дә атка, гасырлар ни?
Шаша-шаша ярсып оча гына
Һаман өскә.
– Җитәр! – диеп, җирем
Суырып ала мине кочагына.
Ә мин сабый, тәнем сызласа да,
Еламадым, бер елмайдым бары,
Атлар булып томырылды күккә

Балачакның ап-ак хыяллары.
Менә заман мине егет итте,
Авылыма кайттым.
Туган ягым!
Һаман истә
                жиргә егылганым.
Атның өскә
                томырылган чагы.
Сагындырган ярсу җайдак-атлар.
Кайда алар, кайда?
Тып-тын урам.
...Туган җиргә башны ора-ора
Бушанасы иде...
Елый алмый торам,
Елый алмый торам!

## ЯҢГЫР ГЫНА

Кырый йорттан мәет чыгаралар –
ялгыз карчык үлгән.
Яңгыр коя, ашыгасы иде –
өй каршында аны зиратка илтәчәк
КамАЗ машинасы.

Өч-дүрт кортка эчтә – күршеләре,
шулар утырган төне буе яңгыр тыңлап,–
елар өчен генә булса да,
бераз көч бир син аларга, Алла-а.

...Ә күк елый, дияргә хакым юк минем.
Бу – яңгыр гына...
Бу – яңгыр гына шулай ява,
һәм явачак.

Күмүчеләр дә аз булыр шуңа.
Һәм йомышчы барып җитмәс, бәлки,
күрше авыл мулласына.
Бу да шул яңгырдан гына юкса,
шул яңгырдан гына-а-а...

Корткаларның буыннары сызлый,
мыштырдыйлар – әле күзлек,
әле тегәрҗеп югалган –
гамьнәре юк, сизмиләр дә:
шоферның инде
бер литрлык кына
вакыты калган.

# ИКЕ ОЧ

Ике йөз елдан соң инкыйраз...
*Г.Исхакый*

Йорт өлгертә яшьти.
Югарочта
ыгы-зыгы. Балта тавышы.
Нәни генә малай ышкы тоткан,
кулы шундый тора ябышып.

Япь-яшь хуҗабикә чыгып баскан,
сөенечен тора чак тыеп...
Самавырны тергезергә диеп,
йомычкалар ташый сабые.

Балта томшыгында кояш көлә,
сагызланып нуры сузылган...
йокымсырап ята бүрәнәләр,
уянырлар ике йөз елдан.

...Түбәночта тыныч.
Дүрт-биш карт тик,
яннарында никтер бер хатын...
Дәшми-тынмый гына казганалар –
зурайталар авыл зиратын.

## ВӘХШИ

Кырмыска оясына кулны суздым.
Кырмыскалар учым буйлап йөгереп узды.
Гөжләп куйды бөтен бер ил!

«Кем ул анда тынычлыкны бозып йөри?»
Җанны асраганда,
Мәгънә күреп
Кыса эчендәге яшәештән!
(Бөтен бер ил дога кыла булыр
Ярдәм көтеп Тәңредән, өстән.)

Һәрбер нәрсә канунлашкан монда,
Һәркемнең үз эше үз йортында.
Мөмкин кадәр тизрәк!
Мөмкин кадәр күбрәк күтәрәсе...
Юк монда моң төшенчәсе.

Яшәү өчен яшерен көрәш бара,
Куәтсезләр бөлә, куәтсезләр үлә...
...Никтер шушы кырмыска оясын
Таяк тыгып болгатасы килә.

## КЕЛӘ

Тутыккан ишек келәсе,
Каһәрле ишек келәсе!
Чыгасы килә дөньяга.
Чыгасы... ишетеләсе...

Куркырга хәерче суздән!
Булмый кешедән теләнеп.
Әгәр күтәрелмәс икән,
Каерып ат ул келәне.

# ШӘҺӘРЗАДӘ

...Бездә шундый-шундый хәлләр менә...
Без дә шәһәр малайлары инде.
Сәер түгел хәзер таш каланың
Мәдәни күгәрчене.
Без дә шәһәр малайлары инде!
Без дә мәдәниләшәбез.

Сак-сак кына басып тротуарга,
Киногa барабыз менә...
Урам хәрәкәтен беләбез инде –
Асфальт тузаны җемелди керфектә.

...Ә кино авыл турында, ди,
                    урман турында, ди!
Сагыну хисе чит түгел бит миңа да...
Тыңлап карыйк, дустым шәһәрзадә!..
Кошлар ничек сайрый икән кинода?
Сак-сак кына басып тротуарга,
Киногa барабыз менә...
Ни гаеп? –
Ашалган үкчәбездә уч төбедәй тынлык
Биртелмәсен, дибез,
          иселмәсен, дибез,
                    сытылмасын, дибез! –
Сакланып атлыйбыз,
          сагаеп,
                    сагаеп.
...Менә шундый-шундый хәлләр безнең.

# МИНЕМ КАЙБЕР ӘЙБЕРЛӘР БЕЛӘН ХУШЛАШУЫМ

*(Көндәлек)*

## Кереш

**Якшәмбе**

Китәләр көннәр миннән!
Китәләр көннәр бер-бер артлы...
Һәм вакыттыр, бәлки,
Сорау бирергә дә:
Мин кем? Нәрсә? Мин ни атлы?
Китәләр көннәр – димәк, шулай кирәк,
Ябыла икән ишек – әйдә ябылсын...
Ни таптым мин җирдә шигырь язарлык?
Шигырь язарлык ни югалттым соң?
Мәңгелеккә китте менә тагын бер көн,
Хәбәр килде тагын киләчәгемнән,
Нәрсәнедер көн биреп калдырды,
Нәрсәнедер алып китте миннән.
Һәркемнең дә үз мәйданы җирдә:
Кем кем яклы?
Ә соң...
Ул ыргыткан сөлге кызылмы соң билдә?
Керфегемә орынып узалар көннәр,
Ак ябынчалары
    җилферди
        җилдә.

* * *

**Шимбә**

Китәләр,
Аркаларында номер яна төтенсез,
Тырнак эзе сыман.
Юлдагылардан сорыйм туктатып:

Җаннары соң кая алгысына?
Җуелырмы ул – кемдер суккан номер,
Һәм бу тырналулар төзәлерме?
...Булмаса да, бәлки, җир түгәрәк,
Бер әйләнеп кайтыр алар нәкъ үзләре...

Ябынчалары да әүвәлгечә булыр, димсез, ап-ак?
Булса булыр, ә мин шушы мәлдә,
Шушы хәлдә кулым болгыйм:
Уч төбеннән суырылып чыккан тукыма
Кулъяулыкмы, әллә бер әләмме...
Кайсы дөнья тукымасы?

* * *

**Җомга**

Китеп бара мәңге яшел имән,
Нинди яссылык бу, ни ярышы?
Күпме көтмә, күк капусын ачмас
Офыкларга тиеп ябалдашы.
Китеп бара агач, яфраклары
Йөрәк кебек лепелдиләр, гаҗәп.
Эчен тотып көлгән дөнья!
Юк шул
Йөрәкләргә, яфракларга пәрәнҗә.
Юатсаң да, китә чит-ят якка,
Сизәм: тиздән без очрашырга тиеш.
Аркамдагы эзне
Ләкин күз дияргә
Җыенмыйсыз ич сез...
Болытларны кисеп китеп бара.
Яңгыр килмәс инде, гөлләр кибәр.
Пәрәнҗәләр юк шул шагыйрь гомеренә:
Яфрак кебек тибә
Бүген йөрәк.

* * *

## Пәнҗешәмбе

Туган авылым уйсу җиргә утырган.

Бала чакта без еш кына күрше авыл күленә су коенырга йөри идек. Ике сәгатьләп, каз тәне чыкканчы, суда чупырдагач, өйгә кайтырга чыгабыз. Акрын гына атлыйбыз, хәрәкәтләрдә ниндидер хәлсезлек сизелә, буыннар татлы итеп сызлый.

Талгын гына җил исә – юл читендәге башаклар бер-беренә орынып алалар да дөньяга икмәк исе тарала. Шул исне ишетеп күкрәкләр киңәеп китә, йөрәк бөтен тәнгә рәхәтлек биреп сулкылдый башлый. Кешеләр өчен нидер эшлисе, нидер башкарасы килә. Бик рәхәт була шул чагында!

Хәзер инде менә шәһәрдә яшим. Шәһәр минем каныма сеңеп бара. Ләкин шул вакыттагы халәтне, тагын бер генә кат булса да, янә бер кичереп карыйсым килә минем, бик тә килә...

Без кайтып барабыз. Өйләр әле күренми, тик манарасыз мәчет кенә, канатсыз кош кебек, күккә омтылган килеш тынып калган мәчет кенә: «Вәгаләйкемәссәлам!» – ди кебек. Менә ул безнең авыл! Уйсу җиргә утырган булса да, ерактан күренә ул!

Без, карсак өйләр арасында әбәк уйнап үскән малайлар, беренче тапкыр шулай биеклекне тойдык. Иске агач мәчет безнең өчен серле иде, сихри-тылсымлы иде.

Зурая төшкәч, без мәчетнең эченә керергә дә җөрьәт итә башладык. Мәчет тузган, олылар анда керүне катгый тыялар иде. Тик малайлар тыелганны эшләми каламы? Сыгылып торган баскычларга басып чормага күтәреләбез.

Биеклек.

Үзәндә үскәннәр тауларга шулай кызыгалардыр, тауларга һәрвакыт мөкиббәндер алар... Нигә шулай тарта соң ул безне күк?

Ярыклардан саркылып көн яктысы керә. Аяк астында аунап яткан, иске хәрефләр белән чуарланган ниндидер кульязмалар пышылдашып ала. Без алардан күгәрчен ясап һавага очырабыз. Алар бераз җилпенеп алалар да, янып төшкән дошман очкычы сыман, борыннары белән туган җиргә кадалалар. Очкычның артыннан төтен эзе кала, монда ул да юк, ичмаса.

Ул кульъязмалар мәчетне суткәч тә әле, кар-яңгырда чыланып таралганчы, озак аунап яттылар анда. Мәктәпкә илтә торган сукмак шул нигез аша иде. Без, хәтернең бәбәгенә басып, мәктәпкә йөрдек.

Тарих янган. Тарих – таш сарайлар, кабер ташлары, чүлмәк китеге... Ул бары кульъязма гына икән. Зәңгәр күккә төтен күтәрелгәнен без күрмәдек... Ә мифлар, җырлар, риваятьләр? Алар тарих түгелмени, хәтер түгелмени? Алар шул төтен генә шул... Инде теткәләнеп беткән төтен... йөзгә сыланган корымнан без хәзер шигырь язар өчен кара гына ясый алабыз.

Авылда искечә укый алучы юк иде. Бер кешенең дә исе китмәде ул саргайган кәгазьләргә. Тик бер авыру малайның гына ул язмаларны бик тә укыйсы килә иде... Аның чәчләре, гарәп хәрефләре сыман бөтерелеп, маңгаена төшкән иде һәм...

аны өметсез, диделәр,
шулайдыр да.–
Әйле-шәйле үзе, уе өзек-өзек.
Тернәкләнү – ай-һай, кичә сәгать 8 дә
ишекне шакыган өметсезлек.

Ә авыруы әллә нинди аның:
йокысызлык һәм борынгы җырлар.
Җир өстенә ишелеп килгән болыт –
соңгы яуга ташланучы урда...
Һушын җуя ул кан тамчысы күрсә –
гүя ул яралы, яралы.
Җиде бабасыдай ыңгыраша –
җирдә
мондый чир дә бар әле!

Авылда сөйләделәр: хыялый ул.
Кемдер әйтте: акылның бу
адашып йөрүе...
Ялгыштылар,
малайда хәтәррәк чир иде –

хәтер авыруы.
Шундый кеше яшәде.
«Оныту» сүзен ул сүзлектән эзли иде,
акылы да сау иде.
Ә бүген сәгать 8 дә
авылда
елау катыш көлү ишетелде,
көлү катыш елау.

* * *

**Чәршәмбе**

Безнең якта ат кебек биеләр. Идәннәр сыгыла, тузан күтәрелә. Кан кыза, маңгайга таза тир тамчысы бәреп чыга, калын пәлтәләр, туннар почмакка оча... тышаулар кебек. Бер тугарылып алу гаеп түгел, ыңгырашсын әйдә идәннәр. Бөтерелсен әйдә егет, йөрәк яшь колынга әверелсен. Безнең халык алаша кебек сабыр бит ул, алаша кебек чыдам.

Кешенең иң төп сыйфаты: кем кебектер, нәрсә кебектер булырга тырышу. Кешелек зур үсешкә ирешүе белән шул сыйфатка бурычлы түгел микән? Диңгез ярында яшәүчеләр балык кебек булырга хыялланганнар: кораблар уйлап тапканнар. Күккә якынрак яшәүчеләр кош кебек булырга теләгәннәр: очкычлар уйлап табылган. Ни бу? Асылыңа кайтырга тырышумы?

Безнең халык гомер-гомергә ат белән янәшә яшәгән. Бөтен кешеләргә дә хас сыйфат аңа хас түгелме? Безнең дә холыкта, хәрәкәттә һәм кыяфәттә ат белән уртак сыйфатлар юк микән?

Телевизордан тау халыкларының биюләрен күрсәтәләр. Кулларын канатлар сыман җәеп җибәргәннәр, тагын бер талпынып алырлар да очып китәрләр сыман. Ә кыяфәт!

Тау халыклары бөркетләр кебек биеләр.

Һәм замана һаман үзгәрә тора. Юллардан хисапсыз машина йөгерә, кырларда тракторлар гөрелтесе, тауларны сискәндереп самолетлар оча. Машина белән уртак сыйфатлар юкмы хәзер бездә?

...Ә тышта кар ява. Янә бер кышка кереп барабыз. Авылда хәзер сугым суя башлаганнардыр. Тирә-як авыллардан, анда булмаса, еракларга китеп ат алып кайталардыр. Бу инде күптәннән килә. Ишегалдында ат егып чалу – ул байлык, муллык, бәхет билгесе. Инде дөньяда күпне күргән өлкән абзый, «Аллаһы әкбәр»ен әйтеп, җиңелчә дерелдәгән куллары белән зур пычагын аның бугазына батыра. Ак карны эретеп бугаздан кан ургый, хуҗаның киез итекләренә чәчри. Аның янәшәсендәге хуҗабикәнең йөзендә тантаналы елмаю, кулында җылы су салынган җиз комган. Ат тынып калгач, унлап ир-ат аны тиз арада ботарлыйлар да өйгә ашыгалар. Урамга яңа пешкән ит исе бәреп чыга. Бу йортта бүген бәйрәм, якын килергә кыймыйча, еракτан гына күзләрен елтыратып торган урам этләре шатлыклы чинап куялар. Аларның да бүген бәйрәм көне...

Гасырларның бугазыннан кан саркыды гүя,
гореф-гадәтләрнең бугазыннан, Гайсә!
Үзең сатып алган атны гына
суйган идең бит югыйсә, –
кып-кызыл ат зәңгәр күккә бакты соңгы кабат!

Шагыйрь туфлиедәй тузган тояклары
эт оясы авызына барып ятты,
ә хәтерне беркем уятмады, Гайсә.
Әй шатланды күрше карчыгы,
сугым суя халык,
гореф-гадәт дәвам итә, диеп,
әй шатланды соң күрше карчыгы!
Беркем күрмәде – бүген традицияләрнең
бугазыннан кан саркыды, Гайсә.
Атны мең чакрымнан алып кайткан идең.
Әй шатландың син дә:
моны сую да, имеш, бәхет әле...
беркем ишетмәде
мең тәңкәлек буаз байталның
соңгы ютәлен, Гайсә...

* * *

**Сишәмбе**

Ул туйганчы ялганлады.

Без, иреннәрне тешләп, баш селкеп утырдык. «Ялган!» – диеп кычкырырга өйрәнмәгән шул без. Ул моны белә иде, шуңа күрә, эчтән генә бездән көлә-көлә, рәхәтләнеп ялганлады.

Агачлар җиргә таба үсте, тамырлары арасыннан безнең баш түбәсенә, өстәлдәге касәләргә туфрак коелды.

Касәләрне иренгә тидереп, без аннан җир тәмен, без әлегә кадәр татымаган ниндидер әчкелтем, тозлы тәмне тойдык. Күңелебездә актарылып ташланган, кара янган җирдән дөньяга сузылган әрем үсентесе кебек нәфрәт баш күтәрде.

Кешегә ялган кояш, су, һава кебек үк кирәк микәнни? Ул сүзнең кайчагында «матур», «изге» сүзләре янәшәсендә авыз ерып утыруын башкача тагын ничек аңлатыйм мин?

Ә ул рәхәтләнеп ялганлады. Әмма аның ялганлавы матур түгел иде. Ул, эчтән көлә-көлә, безнең күңелләрдәге әремне сыга бирде, сыга бирде, бугазга әче су төйнәлде.

Без ачы тавыш белән: «Ялган!» – диеп кычкырдык.

Ярабби, бу рәвешчә дә ялганга нәфрәт уятып була микәнни? Матурына да, ямьсезенә дә...

* * *

**Дүшәмбе**

Иске мич сыенып утырган аңа...
Идәндә акшар.
Тәрәзәдән иңгән караңгының күзләренә
керә аксыл яктылык.
Һәм түшәмнән һәрдәм тамчы коела.
Киңәя аның итәгендә кара шәл...
Аяк астындагы йомгак кына һаман
югара бара... югара бара...

Кара мәче кичә минем юлны кискән иде,
балалары янына ашыккан, диделәр аны.
Җеп өзелә...
Керфекләрең дерелдиме саксызлыктан?
Ул аны ялгар, иреннең дымы белән ялгар!
Чуалмаска тиеш ул йомгак!
Аяк астында юкара бара... юкара бара...
Кайсы меридианда син, өзелгәнне ялгарга
йөгереп килеп җитәрсеңме яланаяк?
Һәм,
Офыкка ябышкан аваз кебек,
Мин күз салдым урманнар өстенә.
Мин – чишмә челтерәве.
Мин – сандугач канатын какканда чыккан җил.
Мин – япь-яшь кызның уч төбенә
өлгергән җиләк йоктырган алсулык.
Мин – синең тәрәзәдә уйнаган яшен.
Мин – кар базындагы суыкның
соңгы тәлгәше. Мин – чакма.
Ә хәзер җил исә урманнар өстендә,
йөгерә агачлар ерак-еракка,
ишетелә шартлау...
Серле урман кызы!
Син ни хәлдә?
Ни китерде сиңа бу искән җил?
Минме соң сусамаган гыйшрәт
җырына?
Тама кәгазьгә яшел сискәнү.
Борчылма... Юк, якын түгел сиңа
бу шартлаулар...
Алар минем якта.
Күтәрелә тотен, тузан
җаннарыннан,
һәм йөгерә агачлар ерак-еракка.

Офыкка ябышкан аваз кебек мин
ызанда...
Соң кая, кая барасы?
Таптап чебен гөмбәләрен,
җырга
чабып керде болан баласы.

*1981*



# II БҮЛЕК

*Үземнең төшкән ярыма, учак янында калган әтәй янына мәңге кайта алмавымны аңлаудан җаным өшеп, кулларым бәйләнде, аягымны көзән җыерды...*

*Шул чагында, сүүсемнәрне ера-ера, миңа таба ап-ак сакаллы карт якынлашты. Әкәм-төкәмнәрне, яшькелт бака ефәкләрен таягы белән аралап, акрын гына якынлашты ул миңа. Йа Хода, әллә бу әбием сөйләгән Хозыр Ильяс инде?.. Каршыма килеп баскач, җыерчыкларын җәеп елмайды, йомшак учын маңгаема куйды. «Юлың озак, олан,– диде ул,– әле син күп юлларның тузанын суларсың, хәтфә чирәмнәрнең йомшаклыгын арган аягың тоеп рәхәтләнер. Көнбатышка карап бар да бар. Юлыңның ахырында син мәгарәгә тап булырсың. Эчтә, мәгарәнең нәкъ түрендә, мәңге яшьлеккә кайтара торган даруның сере язылган. Шул даруны ясап, син әтәңә алып кайтырсың».*

*Мин сөзәк ярда чалкан яткан килеш уянып киттем. Елганың теге ягында кояш инде дилбегә буе өскә менгән, бөтен табигать нурда коена, кошлар сайрый, үлән арасында чикерткәләр черелди.*

*Кесәмнән ипи телеме чыгарып чәйни-чәйни, туп-туры кояш баешына таба киттем. Урманнар аша үттем, поезд юлларын аркылы чыктым, тузанлы, гаугалы шәһәрләр артта калды. Ниһаять, алда бер калкулык күзгә чалынды. Аның итәгендә ат көтүе утлап йөри иде. Калкулык өстендә чишмә тибеп тора, чишмә янында көтүче егет курай уйный.*

*– Исәнме, көтүче егет! – дип сәламләдем мин аны.*

*Ул җавап бирмәде, курай уйнавын дәвам итте. Сузынкы, сагышлы моң мине изрәтте, талчыккан аякларны сузып җибәреп, көтүче егет янына утырдым. Курай моңы каядыр дәшә, чакыра, нидер искәртә дә, сагайта да иде шикелле. Ниһаять, көтүче телгә килде:*

*– Бу курганда Япанчы батыр күмелгән,– диде ул.– Әнә аның аты.– Ул бармагы белән көтүдән читтәрәк утлап йөргән чем-кара атка төртеп күрсәтте.– Беркемне янына җибәрми, хуҗасын көтә...*

*Аның сүзләрен ишеткәндәй, кара ат башын өскә чөеп, ялларын офыкка таратып кешнәп җибәрде.*

*– Ерактан киләсеңме, юлчы?*

*– Ерактан, Елга үзәненнән...*

*– Юлың кайларга алып бара?*

*– Кояш баешына...– Мәгарә турында көтүчегә сөйләп тормадым.*

*– Анда өлгерерсең әле,– диде ул көлеп.– Бу җәйгә генә булса да син монда кал, көтү зур, берүземә көтүе читен...*

*Ул, минем җавапны да көтмәстән, казан асып җибәрде, учакка ут тергезде. Бераздан казанда инде быгырдап куй ите кайный, чәйнектә кыр үләннәре белән кушылган чәй пешә иде.*

## ДАЛА ҖИЛЕ

Мең кат үлеп, мең кат терелгән ил!
Мең кат туңып, мең кат эрегән ил...
Сизәсезме, исә тагын дала җиле –
Эзли, эзли сине.

Соңгы куздан үрли ялкын теле,
Тузгый сүнгән учакларның көле...
Сизәсеңме, дала җиле исә тагын? –
Газиз туган ягым.

Яшь бүреләр суырылыр өннән,
Ыргылырлар янә кан эзеннән,–
Сизәсезме, тагын дала җиле исә!
Ялгыз дәрвиш исә
Утырган да елый. Буп-буш дала –
Унлап гасыр бергә сыя ала!
Исәрләнеп исә тагын дала җиле –
Көл калырмы, илме?

* * *

Без очарга әзерләнгән идек,
Давыл купты,
Күкне яшен телде.
– Ашыкмагыз, сабыр! – диде Тәкъдир.
Очышыбыз кичектерелде.

Ә куәтләр ташып тора иде!
Давылларны җиңмәс идекмени,
Күктә булсак?
...Күз яшьләрен йотып аязганны көттек,
Йодрыкларны төйни-төйни
Көттек.

Әй кыйнады давыл безне җирдә...
Җаныбызга керде, бәгырьләрне телде.
Ыңгырашып күккә караш аттык,
Ә күк бездән көлде,
Елый-елый көлде.

Тынды давыл,
Җансыз сыман тын калды җир.
Инде безнең Тәкъдир суга набат...
Тик кая соң элекке көч?
Тешне кысып
Талпынабыз кабат
Биеклеккә.
...Теткәләнгән тәндә теткәләнгән канат.

## ЧЕЛТӘР АША

Челтәр-челтәр карлар.
Ирек исе.
Чиксезлеккә аягын терәп,
Шул челтәргә тотынган да Җир,
Көнгә карый кебек мөлдерәп.

Челтәр-челтәр-челтәр.
Ирек исе,
Күктә азат кошлар чирүе.
Ишетелә инде: кайдадыр аста
Чишмә челтери –
язга керүе...

## ИХЛАСЛЫК

Кемдер челтерәп көлде –
Ишеттем дә сокландым.
Әрнеп елады кемдер –
Ишеттем дә кызгандым.

Көлүченең шатлыгын
Уртаклашып булмады.
Елаучыга җылы сүз
Эндәшергә кыймадым.

Сау булыгыз, шигырьләрем!
Йөрәгем бүген ватык –
Йә ихластан көлүчене
Рәнҗетермен юатып.

## ЧИТ ҖИРДӘ

Кая монда туган як былбылы? –
Читен икән моңсыз чит җирдә...
Тәрәзәмне ачсам – иртәнге җил
Туган якны искә төшерә.

Һәм ямансу...
Ялгыз башым монда,–
Күңел шуны авыр кичерә.
Тәрәзәмне ачсам – кичке җилләр
Таныш көйне искә төшерә.

## ГОМЕРЕМНЕҢ...

Аккош чаңраганы ишетелә.
Дөм караңгы урман, учак төтене...
Гомеремнең гадәти бер төне.
Аккош чаңраганы ишетелә.

Гадәти бер төн бу. Менә тиздән
Яктылыкны алып килер җилләр.
Кошчык томшыгында чык тамчысы
Кояш белән кавышырга телә р.

Гамьнәремнең тәме иренемдә.
Тасвир итеп буламы соң аны!
– Сере нидә? – диеп сорау бирмә...

Ишетелә аккош чаңраганы.
Якты урман, учак төтене, тирмә.
Гомеремнең гаҗәеп бер таңы.

## ЧАКЫРУ

*(Рөстәм Кутуй иҗатына ике сәяхәт)*

1

Болын атларыдай уйлар тып-тын...
Шук үләннәр шаулый, көннәр түгел.
Аерылышуны кемнәр уйлап тапкан,
Җиргә кара күләгәләр түгеп...

Азат җилләр йөри дөньябызда,
Болыт эри, күз яшьләре кебә.
Кем чигерә кавышу минутларын,
Карурманнан сахра эзли нигә?

Көянтәле кызый шундый гади.
Җирдә карлыганнар исе генә.
Кем туздыра тып-тын уяларны,
Кара канатлы кош исеменнән?

Кагылды да вакыт тәрәзәмә,
Төн ишелде минем җаныма ук...
Кем өмете булып йолдыз калыкты?
...Бер ат йөри әнә, җайдагы юк.

2

Аргы ярда кемдер дәшә мине.
Ярдәм кирәк микән? Ә су шаулый –
Берни ишетмим мин. Шунысы хак:
Тавыш елга белән тынышалмый.

Су тавышны йота, сүрелдерә.
Хәтта кошлар аера белми аны.
Бозлар кебек саллар агып бара.
Ишетелә ярның тын алганы.

Теге ярда – тынлык. Куллар түгел,
Төтен генә сузыла теге ярда.
Кемнең соң ул сабый җаны елый,
Адашырга дәшеп томаннарда?

Үз-үземне чакырамдыр әле...
Ишетелми ләкин пычагым да...
Су өстендә бәргәләнә тавыш,
Ычкыналмый елга кочагыннан.

* * *

Җәйрәп ята анда арыш кыры,
Тартып тора әллә нинди сер...
Ник керәсе килә арасына? –
Күмеләсе килә, күрәсең...

Сары сихер йотты аны бүген,
Кая илтер инде юллары?
Сагыш кына калды аунап җирдә,
Һәм сак кына тирбәлде арыш.

# ЙОКЫСЫЗЛЫК

Һәркем шигырь яза...
Һәм Тукайга
Мөрәҗәгать итә чор аша.
Һәр кешенең үз Тукае!
Мин дә Үз Тукаем белән очрашам.

Ят итмидер. Килә.
Ләйсән булып
Тәрәзәмә минем сибелә.
Таң йолдызы булып кайчагында
Күзен сала бүлмәм түбенә.

Кыен чакларымда чакырам аны.
Даһиларга сыгыну оятмы? –
Бәгырь бит ул безнең... Әрнүләре
Йокламаска, ахры, уятты.

Ят итмидер.
Тик шунысы менә:
Ул ризамы бездән?
Белмәссең...
Мин ялварам аңа: һәммәбезгә
Бөек йокысызлык теләсен!

Таң беленгәч, ул кузгала акрын.
Хушлашулар әле соңыннан.
Кем өчендер малай. Миңа – абый!
Шуңамы мин ныграк сыгынам.

# КАВЫШУ

«Озак бaралмассың, озатырлар!
Изге затка – зират. Ят, йокла», –
Кат-кат кабатлады «ят яраткан».
Төртеп екты аннан ястыкка.

Өлешенә тигән көмеше, дип
Кешнәп куйды шулчак тук мәйдан,
Һәр шигыре, һәрбер сүзе өчен
Түләү таләп итте Тукайдан.

Сөрергә, дип сөрән салды берәү:
Гомерлеккә китсен сөргенгә!
Кагылмакчы шулай исерек ният
Шигъриятнең бөек серенә.

Сузылдылар керле куллар белән,
Аның соңгы сулышын бүлдереп.
Төкерде ул.
Тук Рәсәйнең шома маңгаена
Ябышып калды канлы төкерек.

Һәм дерт итте кимсетелгән кавем.
Язгы күкрәү кебек уянды.
Кузгалды да мескен ызбалардан:
– Ул безнеке! – диде Тукайны.

Пошаманга төшеп ышыккарак
Посты дошман. Кысты тавышны.
Төшенде ул: шушы төштә шагыйрь
Бакый дөнья белән кавышты.

# КИЛӘЧӘККӘ ХАТ

Сәлам, Такташ!
Бүген офыкларда
эзләгәндә синең чалымны,
агарды да шәфәкъ,
тагын миннән
сәмави нур читкә агылды.

Күк иңләргә яратылган җаның
моңсуланып аска күз атты,–
Күмә карлар синең канап-канап
җирдә өстерәлгән канатны.

Илаһи бер моңга төренгәнсең
бу коршауның теге ягында,–
монда исә сине сыткан чорның
капкалары иңрәп ябыла.

Карлар күмә безнең эзләрне дә,–
башка җырлар монда.
Кошлар да,
гел бүтәнчә канат җилпи-җилпи,
җәяү күченәләр кышларга.

Агарды ул шәфәкъ,
сәмави нур
тагын миннән читкә агылды,
шулай да мин ерак офыкларда
эзлим синең таныш чалымны.

Канатларым җирдә өстерәлә,
шигырьгә дә чыктылар ясин.
Томан эчендәге киләчәктә
үз яныңнан урын калдыр син...

# КҮЗ ЯШЕ

Үз җаныма төбәлдем бу кичтә,
Җаным гүя алтын мәгарә...
Ямансу җыр булып тәпкеләнә
Бер күз яше төште тәгәрәп.

Тирән итеп сулыш алырга да
Җөрьәт итми торган бер мәлем...
Яңгыраганда җирдә Сәйдәш моңы
Үз җаныма менә текәлдем.

Анда Сәйдәш моңсу көлемсери,
Сибелә көй әкрен, тын гына.
Сибелә язмыш... Җирдә яшәүләре
Читенерәк икән моңлыга.
Сибелә көй, ярсып-ярсып ала,
Монда күкрәү, яшен яшьнәве!
Читенерәк икән шашкын җанга
Җир йөзендә янып яшәве.

Сибелеп кала язмыш. Ә көй килә –
Вакыт үзе биргән бәһане,
Ә көй бездә! Бәгырьләргә сеңгән
Сәйдәш моңы,
Сәйдәш аһәңе.
...Шушы кичтә күзем карасыннан
Сытылып чыккан сыңар күз яше!
Шул аһәңне син сыйдырсаң иде,
Син сыйдырсаң иде Сәйдәшне.

# ОЗАТМАГЫЗ

*(Пенсиядәге актер монологы)*

Тормыш сәхнә икән.
Без уйнадык.
Без яшәдек – тарих үзе белә.
Давылларны теләп алдың, йөрәк,
Инде хәзер тыныч үлем телә.

Тезебезгә картлык башын салган,
Сыенганнар еллар хәлсез тәнгә,
Ул гайрәтле яшьлек кайтмас инде –
Бәргәләнмә, күңел, бәргәләнмә.

Җемелдиләр анда башка утлар,
Башка йөзләр чорны табындыра.
Аңлыйбыз да. Ләкин шушы сәхнә
Һаман тарта безне, сагындыра.

Йөрәк аша үтте күпме язмыш –
Хан да булдык, кол да булдык монда.
Кирәк түгел мәрсияләр.
Китик
Гап-гади бер кеше булып кына.
Зарланмыйбыз – барысын да алдык –
Булды төшү, булды күтәрелү...
Менә хәзер – бәлки, бәхеттер ул
Вакытында шулай китә белү?
Озатмагыз! –
Көннәр шундый салкын,
Юлга буран кар көртләре өйгән.
...Җылы җанны сезгә калдырырга
Хәлдән килсә икән...
Килсә икән.

# ДӘВАМ

Бәрәннәрнең борыннары кытыкланды
болыннарда...
Көяз үлән кыяклары буйлап
чык тамчысы тәгәрәде
күккә тияр-тимәс.

Ап-ак чәчле әбекәй
кайдадыр еракта таң белән
ак күлмәген элде киртәгә.
Иртәгәсен кем белә?

Килде, күрде, көлде.
Бу – җил.
Әле көч тә һәм гайрәт тә калган.
Талканы да коры – ябышты,
чалкан барып төште күлмәк
җиргә.

Ята, әйтерсең лә намазлык ул,
әз генә моңсу да, әз генә талчыккан.
Ята күтәреп өстендәге
күгәрчен канатларын,
хат-хәбәрне, аш чүмечен.
Әле тагын бик күп, бик күп әйбер анда:
каләм ватыклары, сынган пычак,
корымланган казан, керфек тибрәнүе,
бишек җырлары һәм бер кочак сәлам.
Ә бәрәннәр?
Бәрәннәргә нәрсә!
Өстәлде күлмәккә тояк эзләре.
Чаптылар күзләрне терелтеп,
өметләндереп өметсезләрне.

Уйна курайда! Кубызыңны тарт!
Алып чык гармун, көмеш теллесен.

Бөдрә бәрәннәр
күктә,
җирдә,
суда.
Һәрбер бөдрә – сорау билгесе.
Чаба алар, чаба авыллар аша,
карталарсыз, компасларсыз чаба
еракларга, еракларга –
язга таба,
яшел үләннәргә таба.

## АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВКӘ

Акрын гына карлар төшә өскә,
Офыккача тоташ япан кыр...
Учак шәүләләре сикерешә,
Бер кыз көлеп куя кайдадыр.

Ә аксакал карлар хозурында,
Алмаштырып булмый холыкны.
Азатлыкны тою мөмкинмени,
Татымасаң әгәр коллыкны?

Янәшәдә мәш киләләр ишләр,
Кем ул мылтык төзи киеккә?
Балта таушы... Тигезлиләр тагын –
Үскән кемдер бер баш биеккә.

Татар имән сыман беркатлы ул:
Тамырларга балта тигәндә,
Горурланып аваз бирә кәүсә:
– Сабы безнеке,– дип,– имәннән!

Акрын гына карлар төшә өскә,
Офыккача тоташ япан кыр.
Монда Тукай ауган, монда Гаяз
Буран ярып алга баргандыр.

Шагыйрьләрне болгар бабайлар ук
Хөрмәт иткән, кулга нан биргән,
«Аның урыны Тәңре янында»,– дип,
Муенына элмәк кидергән.

Офыккача тоташ аклык бүген,
Ирексездән җаннарга йога.
Аксакалның эзләренә карыйм,
Һәм кабатлыйм: «Йәгез, бер дога...»

Тып-тын кала тирә-юнем шулчак,
Күздән тамган яшем ник ачы?
Иренемдә юкса ясин түгел,
Исән үтәсе юл догасы.

*1997*

## МӘҺДИ ӨНЕ

Иссен ул җил, чү, димәгез,
көннәр дә булсын явымлы,–
Гөберчәк басуларына
алып китсен сыктавымны.

Анда әле элеккечә
колыннар уйнап җылына...
Үксүләрем яусын иде
кипшенеп яткан болынга.

Күке һаман гомер саный,
үзәкне өзә лә өне.
Урманнар йотсын үзенә
күңелләрдәге әрнүне.

Кеше китә, җыры кала –
иясен җуйган җырлар да
сагыну булып сибелсен
төлке уйнаган орларга.

Иссен ул җил, кубарылсын
кемнәрнеңниләр кылганы,–
шул җил белән йөзен каплар
даланың көмеш кылганы.

Алып китсен үкенечне
еракка.
Дала ул – табиб.
Безнең язмышлар сыярлык
бүтәнчә җир кайдан табыйк?

Уйнасын анда, кузгатыр
борынгы учак көлен дә...
Мәһдиләрнең өне булып
сеңәр гасыр төпкеленә.

## СЫКТАУ

*Кадерле Фаил Шәфигуллин истәлегенә*

Егылган диңгезче җиргә йөзтүбән,
Бик озак яткан йолдызлар каршында.
Тәрәзләр елаган...
Ә соңыннан кешеләр
Чәчәк ыргытканнар аның баш очына.

Аһ, алсу алманың җиргә егылуы...
Аһ, шул бер мизгел – җиргә егылганчы...
Диңгездән диңгезгә яңгыр эзе сыман
Сузыла, савыла алсу камчы.

Һәм диңгез үзе дә йөгерә ярга...
«Хуш!» димәкче буладыр, бәлки, улына.
Әй, сез!

Эзләмәгез Нух көймәсен.
Диңгез – ерак.
Килеп җитә алмас дулкыны.
Әмма ул кавышыр чал дулкын белән,
Һәм күк белән дә, әлбәттә, кавышыр...
(Исән чакта ул диңгезне һәм күк йөзен
Зәңгәр диеп уйлый иде, ялгышып.)
Ә хәзер диңгез йөгерә, йөгерә ярга,
Без тиң түгел, безгә – моңаясы...
Ята
    йөзтүбән
        диңгезче
Диңгездән еракта!
Чәлпәрәмә килгән күзлек пыяласы.

## ЭДУАРД МОСТАФИН РУХЫНА

Синең белән беркем хушлашмады.
Баш очында Ринат* үзенең
соңга калган сөю сүзен – дәригъ! –
әйтә алмый калды...

Өзелде
көзге күктә ялгыз казның каңы,
таңгы торналарның чылбыры.
Безнең гомер, кыска тоелса да,
озын, сузынкы бер
    кол җыры.
Бәлки, шушы көннәр ваклыгыннан,
зыгылардан туеп чак кына,
киткәнсеңдер төннәр кочагына,

* Шагыйрь югалган чакта Татарстан Язучылар берлегенең рәисе булып эшләгән Ринат Мөхәммәдиев.

шигъриятнең аулак чатына.
Сиңа анда ирек. Мәрсиядән
көләсеңдер... бу шул – сүз генә...
Әүлия дип саналганнар күптән
басты Азатлыкның күзенә.

Үлемеңне юа алмадык без,
хәмерле күз яше агызып.
Элекке мент Харис хәзрәтнең
ялыктыргыч озын вәгазен
ишетмәде зират каеннары –
ап-ак шәмнәр сары кынында.
Онытылган иске каберләргә
яфраклары тамды тын гына.
Җилләргә соң әллә кушылдыңмы,
әллә болытларга сарылдың?
Кабер ташың да юк... Күпме кеше
ташлы мәшәкатьтән арынды.
Тәрәзәгә каплангандыр анаң...
Ә тышта төн. Һәм җил. Җил әрсез.
Беркем какмас инде бу капканы:
югалды, дип, улың хәбәрсез.
Дөнья һаман шул ук.
Болытлар да
сыра күбегедәй күпергән.
Дус-дошманың тирән үткер аша
үтеп бара черек күпердән.
Гайбәт сүзләр йөрми синең хакта,
эзләсәң дә, бер сүз табылмый.
Белмим, кемне кемнәр сагынадыр,
Аккош күле сине сагынмый.
Нигә сине искә төшерик соң,–
син ач иден, дускай, без бит тук.
Татар сүзен күккә чөябез без,
ә карасаң аска – беркем юк.
Синең белән беркем хушлашмады,

син үзең дә кирәк тапмадың.
Чабып үтте бары баш очыннан
ярсу ахырзаман атлары.

Монда әле беркем уянмаган,
офыкларның күзе эренле.
Күк йөзеннән кургаш шәүлә узды.
Беркем искәрмәде.
...эреде.

## ФӘННУР САФИН

Яңагымны тырный бу Яңа ел никтер!
Чыршыларны буа һәрбер өйдә ютәл.
Яңа йолдыз туа сискәндереп мине.
Пыялага кемдер чәчәк ясап үтә...

Түшәмемдә үшән шәүләләрне шәйләп,
Күз яшьләрем йотып озак яттым чалкан.
«Сөенсеннәр!» диеп, җырлар чыгарганмын,
Ә иң мөһим сүзем әйтелмичә калган.

Хәмер көткән касә сыман зыңлый тәрәз!
Килмәс төннәремнең әче тәме телдә...
Офык белән офык кавышырга тели,–
Ялгыз көймә кебек мин чайкалам җилдә.

Яңа елда калам... Инде хушыгыз сез!
Аерылу сездән булмас монда читен...
Яшәешкә таба, ап-ак әләм төсле,
Ләхетемнән сузлып чыгар сыек төтен.

# БОЗВАТКЫЧ

*Марсель Сәлимҗанов истәлегенә*

Яз сулышын ачып яр өстенә,
үтеп китте яннан бозваткыч...
Кемгә куанычтыр, кемгә – сагыш...
Үтте инде...
Калдык озатып.

Арчылды су. Калкындылар эздә
такта кисәкләре, чүп-чар да
кул чукларын селкеп кинәнде бер –
канат алган сыман очарга.

Офыкларда бозлар гөрелтесе...
Таныш аваз... Елак кыш иде:
бозваткычның корыч янбашына
минем борт та килеп ышкылды.

Көләч чаткылары күктә хәзер,
сүнгән көле ява чәчемә.
Кораб җаны китә!
Коткарыгыз...
Китә сандугачлар яшендә.

Бозлар гөрелтесе...
Безнең язмыш
шушы тамашага бәрабәр:
Галиябану мәңге сыктар монда,
фәрештәне капшар Әлмәндәр.

Ташу көтте күпме кеше ярда –
үтеп китте яннан бозваткыч.
Һәм буталды елның фасыллары:
бетмәс-төкәнмәс яз...
озак кыш...

# УЛ ТӨН

*М.Әгъләмгә*

Сөйләштек без, өй сүз белән тулды!
Тәрәзәдә сүзләр, сүзләр чөйдә...
Төтен сеңгән стеналар хәтта
Әверелде бугай көрәшчегә.

Хәтерлим дә гаҗәпләнәм: ул төн
Ялкын үзе эчтән дөрләп чыккан!
Курыкмый икән ләкин начар кешеләр
Кесә эчендәге йодрыктан.

Файдалырак түгел микән безгә
Җир йөзендә, шушы кара таңда,
Ике аякта туры басып калу –
Мескен бөеклеккә караганда?

«Төн, әлбәттә» диген,– «төн» дисәләр,
«Көн» дисәләр,– «әйе, көн шул» диген...
Канундыр бу, бәлки; хәтта сулыш
Күчерә ала нәни ком бөртеген.

Сөйләштек без ул бүлмәдә йөз ел!
Көннәр соры, төннәре дә соры...
Сүзләрдә дә шул төс, шул бертөрле,
Нинди халәт соң бу, җир йоткыры...

Их, бу гомер... гомер... челтери бит,
Күпме язык өстә, бармы савап?
Хәлне сорый дөнья, ләкин безнең
«Таң ата да кич була» –
шул бер үк җавап.

# РӨСТӘМ МИНГАЛИМГӘ БЕР МИШӘРНЕҢ МОНОЛОГЫ

Куцат кыцкыра бит, әбзәй, куцат.
Алтын куцат, алтын – югары.
Беркем күрми кебек, без беләбез
Күзләрендә аның моң барын.

Иелгәнсең...
Сөенгәнсең шуңа –
Мәгънәле ул безнең бу будун*.
Мин дә менә бүген керле идем,
Синең елмаюда коендым.

Куцат кыцкыра бит, әбзәй, куцат.
Кемнеңдер, дим, бәлки, үз таңы.
Шул цагында, бутап бу таңнарны,
Канат җилпи мишәр ...**

Алтын куцат канат җәя күктә.
Ә син, әбзәй, калкын тагын бер...
Әгәр куцат күкәй салса уцка –
Бел, бу Казан – торган ягыңдыр.

Бу калага инде аптырама –
Чебеш белән тулган һәр цаты.
Шигырь барда кикрик шиңмәс безнең, –
Һәр мишәрнең бар үз куцаты.

---

* Будун – халык, токым.
** Бу урында сүз танылмый.

* * *

*Зөлфәткә*

«Кара кошлар – көтү белән!»
Аккош кына һаман ялгыз...
Син дә, шагыйрь, таң суында
сагышларны, гамьне агыз.

Алсу суда бәргәләнә,
түшкәендә ничә яра?
Үзе нәни, күләгәсе
генә гел зурая бара.

Баш очында алтын бөркет
аска томырыла әрсез:
алсу суда зуп-зур аккош
канат кага күләгәсез.

* * *

*Марсель Галигә*

Ык өстеннән күләгәләр шуа,
Төнне йоткан уйчан әрәмә
Кайсы кошның тавышын соң укшый? –
Хәләл дә ул безгә, хәрәм дә...

Кылыч болгап җайдагатлар үтә,
Тояк тавышлары – дөп тә дөп...
Актарылып керә нинди заман? –
Ай каядыр китә кителеп.

Яулары да шул ук, аулары да...
Без битараф инде... Кем уяу?
Кайсы канатлыны ымсындырып
Чакыра шулай өскә Чатыр тау...
Тонык кына күкрәү ишетелә.
Килер еллар безне бер аклар,
Шыпырт яла сыман яр астына
Егылалар кәрлә куаклар.

Күкрәү килә. Эчендәге кинә
Яшен ташы булып бер чыксын,
Кузгатсын ул гомер көзләрендә
Сүнгән өметләрнең җырчысын.

Бар да узар. Таллар гына һаман
Ык ярына ятып оерлар.
Без әйтергә теләгән сүз кебек
Суырылып чыгар суырлар.

* * *

*Газинур Моратка*

Зыңлап тора һава бу далада,
Сызгырып ла керә җырыма.
Кылганнарга, мыштым песи сыман,
Күләгәләр килеп орына.

Бер офыктан бер офыкка таба
Чабып йөрим. Авам. Биртеләм...
Кысылам да янә киңәям мин
Үзем генә белгән серемнән.

Чит-ят күзгә көлке тоеламдыр.
Чаң теледәй кемне чакырам?
Гасырлардан килгән хәбәр кебек
Бүре чыга иске чатырдан.

Дәвер дә юк монда, чорлар да юк –
Берни үзгәрмәгән бу якта.
Җәя тартам. Мәрәй шул ук – иске.
Ә ук кими бара садакта.

Бер офыктан бер офыкка таба
Чабып йөрим. Аткан укларны
Кире җыяр өчен авам җиргә,
Ә алар юк. Табам юк-барны.

Сибелделәр черек көннәр кебек.
Әрәм, дидем. Алар асылда
Офыкларга кереп югалганнар
Газәлләрнең кабыргасында.

Ә далада тагын ук сызгыра,
(Исән әле, исән чуралык.)
Күздән җуела,
Дастан атларының
Калын ялларына чорналып.

Көлсә көлсен мәнсез чит-ят күзләр.
Көлсә көлсен. Әмма сизмәсен –
Эңгер төшә. Барсы үксиячәк,
Шул җайдакта танып үзләрен.

Сынган булыр җәя, садак бушар.
Дала калыр бары, җыр калыр...
Ат сагынган ялгыз җайдакларга
Күләгәләр килеп уралыр.

* * *

*Зиннур Хөсниярга*

Чапты атлар. Бераз чалуладык,
Кайчан гына очкын очырган чак
Мәңге кайтмас булып артта калды,
Очак инде безгә һәрбер кочак.

Үтте, үтте яшьлек. Күпме ирен
Туң бөре күк ачылмады. Ә без
Арыш басуына килеп чыктык,
Зәңгәр урманнарны күзәтәбез.

Дөнья кайчак хакны ялган итә,
Алдашу да чыгар, бәлки, чынга?
Бик тиздән бит кошлар канат җилпер,
Пәрәвезләр очар баш очында.

Япанчасын урап чаба һәркем,
Әллә еллар шундый, әллә юллар?
Һәммәбезнең юкса буран ерып
Япа-ялгыз офык эзлисе бар.
Мәңгелек яр яулык болгый кебек,
Китә микән, кайта микән бәндә?
Без белербез моны барлык өмет
Шигырь юлы кебек өзелгәндә.

Беребез дә Таһир булалмадык!
Һәм, әлбәттә, булалмадык Мәҗнүн.
Яратабыз, диеп лаф орсак та,
Һәр сүзебез торган бугай бик юнь.

Бу дөньяны ни коткарыр икән?
Матурлыктыр, бәлки? Мәхәббәт, наз?
Каракош күк нәфрәт канат җәя.
Безне инде берни коткаралмас.

Ә шулай да бу гөнаһлы җирдә
Бәйләп тора әле шома җепләр.
Дошман күрерлек тә нечкәдер ул?
Мин алдасам, Тәңре үзе җөпләр.

* * *

*Ләбибкә*

Без сабыйлар иленнән бит, дустым!
Иртә киткән ишләр өчен дә
Йончу атлар төсле ауныйк әле
Җиләк ускән карлар өстендә.

Бусагадан үтә алмый бүтән
Үчле кол да, явыз түрә дә...
Алда томан, юанабыз һәр төн
Узганнарга кылып күрәзә.

Кортеслардан качып күккә ашкан
Ацтек кебек без дә чарасыз,–
Җан иңмәгән шүрәлеләр булып
Түгелә карга төннең карасы.

Илебез инде күптән телгә күчкән,
Әкиятләргә күчкән безнең җир.
Офык чиген атлап үткән һәркем
Безнең өчен мескен мөһаҗир.

Без сабыйлар иленнән бит, дустым! –
Ап-ак болытларга тиенеп,
Яшьле керфек кебек янәшәдә
Еллар канат җилпи,– күк биек!

Ак карларда җиләк тамчысыдай
Безнең гомер... яз да яз, сабый, –
Бу чуалган куллар хушлашуның
Эндәшүе сыман гасаби.

## БИТЛЕК

Аны кешеләр яратмыйлар иде:
Сәер уйлар иде зур башында...
Бәргәләнде, үзенә урын табалмады
Бу дөньяда, кеше арасында.

Әллә нинди сәер бер зат иде –
Яшерә алмады бездән уен-хисен...
Аның исеме... истә түгел хәзер,
Аның исеме... Исәр иде төсле.

Бармак төртеп көлдек без аңардан,
Сиздермәде, шундый горур иде.
...Тик беркөнне – Яңа елда бугай –
Ул түзмәде – битлек алып киде.

Этнекеме, әллә маймылныкы,
Мөһим түгел, хәер, андамы эш?
Пышылдаулар китте безнең арабызда:
Кара, ул да кешегә охшаган ич!

Күпме туташ гашыйк булды аңа,
Ә бит элек алмадылар санга...
Һәм ул көлде мыскыл белән бездән,
Һәм битлеген
Салмады беркайчан да.

# БӘХӘС

Килеп керде тиз-тиз генә атлап,
Исәнләште,
Әйтте: «Йә, ни дисең? –
Искә төшердем дә яшәвемне,
Килдем сиңа бәхәсләшер өчен».
Һәм тиз генә килеп утырды да
сәгатен салып куйды
китап киштәсенә,
Йөзен салып куйды
Һәм тотынды...
Онытылды вакыт.
Иң мөһиме – Вакыт онытылды.

Ә югыйсә һаман тәкрарлыйм бит,
Төн артыннан көн килә, дим, һәрчак.
Каршы төшә: чыпчык дигән кош, ди,
Бервакытта да бөркет булмаячак.

...Һәм берзаман аңга килсәм, бер кеше юк,
Иртәнге биш, кием утыра алда...
Шуның белән күпме гомер бәхәсләшәм, имеш.
Ә мин...
Ә мин тәмам чишенеп беткәнмен бит,
Калганмын ич шыр ялангач килеш.

## ТУЛАЙ ТОРАК

Танышымның үз фатиры.
Рәхәт –
Газы да бар, су да, ванна да.
Кышын җылы, җәен җиләс була,
Һәм борчымый икән кандала.

Ишегендә аның өч-дүрт йозак,
Охшап калган фатир кальгага.
– Күршеләрең кемнәр? – диеп сорыйм.
– Белмим,– ди ул,– шөкер Аллага.

Гаҗәпләнәм. Мин бит асылым белән
Бүтән бер зат. Ерак-ерактан –
Башка планетадан. Йөз ел инде
Баш чыкмады тулай тoрактан.

Утлар сүнми төнге бергә кадәр.
Уйламый да беркем тынарга.
Күнегелде йөз ун децибеллы
«Пинк Флойд»ларны тыңларга.

Мин якламыйм тулай торакларны.
Үземнең дә менә яшь арта...
Зәйдуллин, мә фатир, дисә бирәү,
Мин, әлбәттә, һич тә баш тартмам!

Бер тартмага кереп бикләнермен.
Өч-дүрт йозак булыр ишектә.
Сөйләшермен килгән кеше белән
Күзне куеп кына тишеккә.

Ә тишектән дөнья күренми ул!
Ишетелми бер сүз дөньяга.
Анда башка төрле сәгать йөри –
Колак салам бүген мин аңа.

Ачып җибәр тынчу тартмаларны!
Югыйсә бит, урап-урап та,
Кайта алмас беркем икенче кат
Җиребезгә – Тулай торакка...

## ИСЕМСЕЗ КЕШЕ

Аның исемен хәзер бер кеше дә белми.
Кулны тыгып актарсаң да,
Юк беркемнең хәтерендә,
Шулай яши ул карт, дәгъвасы юк...

...Ә иртәгә менә ул исемсез килеш
Тыйнак кына иңәр каберенә.

Карт-корыдан сорыйм: «Ул ни атлы?» – димен.
Чордашлары аның, алар инде белә.
Ник белмәскә, соң, әлбәттә, энекәш!
Хәерниса түти малае ул, диләр.

Егетләрдән сорыйм: «Кем ул, ни атлы?» – дим,
Карт турында миңа, бәлки, алар сөйләр?
Нишләп сөйләмәскә? Соң, әлбәттә инде,
Чибәр Хәдичәнең этисе ул, диләр.

Тере кешенең исемен онытканбыз.
Архивлардан эзләп буладыр да, беләм.
Кем эзләсен ләкин?
Беркем кызыксынмый,
Кем йөресен, юләр, буш мәшәкать белән...

## ОЛТАН

Шома яллы толпар сыртыннан
Гаярь җайдак кинәт егылып калды,
Чит якларга китсәң, сак йөр, диеп,
Картлар әйтә иде шул, аксакаллы...

Югалмассың искә алсаң шуны –
Төннәр аны вәгазь итеп укыр...
Урманнары чукрак ят якларның,
Һәм, тәгаен, кырлары да сукыр.

– Читтә солтан булганчы син, егет,
Үзеңдә бул олтан,– диде йөрәк.
Атсыз җайдак җаваплады көлеп:

– Китче, мәкаль, сиңа нәрсә кирәк:
Чит-ят җирдә олтан булу читен,
Туган җирдә мең кат читенерәк.

## ПОРТРЕТ

*Үзгәртеп кору «каһарманнары»на*

Трибунага кабат менгән бу зат,
Ятлаган да сата сафсата.
Безне хәзер үзгәрергә чакыра,–
Узганыбыз булган чын хата.
Тизләнергә чакыра. Кайчан гына
Тезләнергә кушкан иде бит!
Кычкыр, җырым, зинһар өчен, кычкыр:
Юлда торма, вакыт җитте.
Кит...
Утыз җидедә ул, җәза сорап,
Донос язган Туфан өстеннән.

Бүген әнә анонимка яза...
Ысул бер үк, алым искергән.
Теге чакта мәчет манарасын
Кискән, типкән аен бер читкә.
Бүген... әгәр Алла булса?
Шуңа
Җомга саен йөри мәчеткә.
Асылы да йөз гасырлык аның.
Өмете зур килер елларга,
Берия күк эри, Түрә күрсә,
Скуратов сыман елмая.
Фәхеш җанга иш бар нүеш саен,
Юллый җайлап имеш-мимешне,
Бармак бөгеп саный мыштым гына
Кемгә күпме срок тиешне!
Чыраен куй чыра яктысына –
Чорым, чурла! Таны син аны.
Ул кадерләп киштәсендә саклый
Тушонка һәм Евтушенконы.
– Төзибез! – дип, һаман күкрәк кага,
Алкыш көтә... Ләкин ап-ачык:
Киләчәктә аннан сарай түгел,
Калмас хәтта мескен алачык.
Импотентлык өчен патент алып,
Җанын тагын күпме асырар?
Киләчәкне тудырырга кирәк,
Тудырырга...
Алда – гасырлар.

# ХАЛӘТ

*Габделнур Сәлимгә*

Көннәр бер-беренә шундый охшаган!
Холыклары белән шундый охшаган.
Игезәкләр дә көнләшер иде,
Үләргә җитеп көнләшер иде.

Көннәр бер-беренә шундый охшаган.
Чәршәмбене җомга, дисәң әгәр,
Кемгә файда аннан, кемгә зыян?
Көннәр бер-беренә шундый охшаган.

Итек олтанында чебен үләксәсе
Минем халәтемә шундый охшаган.
Минем йөрәгемә өстәл астындагы
Һәр бушаган шешә шундый охшаган.

Шуның белән бәхетле мин бүген,
Шуның белән бәхетсез мин бүген.

Көннәр бер-беренә шундый охшаган!
Ә кешеләр миңа бер дә охшамаган,
Мин үзем дә кешеләргә охшамаган...
Шуның белән бик бәхетле алар,
Шуның белән бик бәхетсез алар...

# ИСТАНБУЛ БАЗАРЫ

Капалы чаршы...
Базар бу –
алтын балдаклар дөрли.
Бакыдан әрсез азәри
сине эчкә өстери.

Истанбул.
Юллар кисешә.
Күршедә генә әрмән
бәйләнеп ята кемгәдер:
– Нәрдән сән? – ди.– Нәрәдән?*

Капчыклы марҗалар үтә...
Данлыклы урыс маты
монда да, яңакка сугып,
мине мәрттән уятты.

Ябышмый төрк каны да –
тирәдә алтын, алтын.
Яңа Бабил... Пычрак базар...
Йөрим... Нәрсә югалттым?

Гогольне хәтерләдем мин.
Искә төште сүзе дә:
«Моңсу, моңсу, әфәнделәр, яшәве җир йөзендә».

* Кайдан син? Кайдан?

# ЭЧТЕМ

*Р.Акъегеткә*

Мин,
бәлки, исеректер дә –
йотлыга-йотлыга күкне
эчтем бу төн.
Гаеплисез?
Сезнең ябышкак сүзләргә
төкерәм мин.
Күкне эчтем!
Сулкылдады тамырларда дөнья сагышы,
үзгәрде уй, гамь дә...

Томырырга теләдем буш гөмбәзне
караңгы һәм төпсез галәмгә.
Чәлпәрәмә!
...Ә бүтәннәр килсә?
Минем кебек,
кешеләрдән качып, күләгәгә,
бу куаклар арасына
эчәргә дип килсә берәү?!
Калсын!
Сез беләсез аның кайдалыгын,
башны чалкан ташлап
өскә карый алучылар –
Туганнарым!
Тамырлардан
йолдызлар ага безнең.

## ЯРАЛГЫ

Мин исерек бүген.
Ничәнче кат
Аңны югалтканчы исердем.
Гасырларны искә төшердем дә
Суырылып чыкты эч серем...

Җирнең тарту көче артты тагын.
Биегәйде күгем.
Төбендә
Сыңар йолдыз – соңгы тулгактыр бу –
Бер нарасый сыман тибенә.

Туктап калды вакыт күзләремдә,
Күз яшенә чыланды Вакыт!
Бу дөньяда берни табып булмый,
Һәм табигый – булмый югалтып.
Безнең кемдер сызып куйган юл бар,
Чит-ят сукмакларга каерма! –
Гавам миннән йөз чөерде мәллә?
Әллә минме? – юк бер аерма...

Кап-кара кар коршаулаган кырдан
Нәрсә эзлим соң мин? Сере ни?
Артка карыйм – ара шундый ерак.
Һәм алда да берни күренми.

Аңламаслар инде мине бүтән,
Аек акыл – тәнгә мөкиббән.
Туар өчен юкка чыга кеше, –
Кемдер безне юкка өркеткән.

Шома җиңсәдән мин шуып үттем,
Җуйдым тетрәп ике араны...
Дөм караңгы дөнья карынында
Тыпырчындым! – Мин бер яралгы.

Тонык тавыш тынгы бирми һаман,
Таныш та ул, таныш түгел дә...
Бик якында кемдер елый бугай,
Кемдер көлә, кемдер сүгенә.

Күк чайпалып китә шәраб кебек,
Җанга шәрех шул бит – бердәнбер.
Бөек мәгънә эзли юкса шагыйрь,
Күздән яше тама, тәннән – кер.

Мин исерек бүген.
Ничәнче кат
Бөтен рухым җилләр иркендә.
Галәм диңгезендә берьялгызым...
Дулкын өсләрендә – Җир-көймә.

## *Балта осталары*

*(Пермь дәфтәреннән)*

### ТАЙГА МОННАН БАШЛАНА ИКӘН БИТ...

Илаһи як.
Шигырь кирәк, дисез...
Кирәк тә бит...
Бу мәһабәт наратларга карап
Калдым әле телсез.

Бу якларның кырыс табигате сәер икән.
Шигырь кирәк, дисез...
Аптырадым, гаҗәпләнгән булам,–
Яза алмыйм, димен, көпә-көндез.

Шаулашасыз, язалмасаң үзең,
Канунына, давай, безне өйрәт!
...Һәммәбездә шул Такташлар каны,
Вакыт-вакыт уты ала көйрәп...

Елмаям да кәгазь-каләм эзлим,
Шушы урман, һәм сез, һәм бу сазлык
Акрын гына моңга әйләнгәндә
Шигырь язмау язык бит ул, язык.
Язып булмый ләкин, безме соң бу?
Төш түгелме?
Могҗизаи бу көз!
Язып туялмаслык дөньялыкта
Калдым менә телсез.

# ИШЕК ЯСЫЙ ГАЛИ-БАБА

1

Гали-баба ишек ясый.
Вакыт ага –
Ә ул сизми (сизеп нишләсен соң?) –
Ишек ясый, үзенең фәлсәфәсе:
«Шундый гомер! Ике ягында да
Дәү ишекләр аның
(Гали дә сыйсын, җаный да сыйсын).
Берсен уздың икән, икенчесен
Гомер буе үзең ясыйсың».

2

Агач юна Гали-баба, ишек ясый,
Эше тыгыз. Дәшми. Миңа читен –
Сөйләшәсе килә.
Шул хәтерне кузгатмакчы булам,
Күтәрмәкче булам пәрдә читен.
Сораштырам: «Элек ничек иде?»
Хәйләкәр карт, борылып миңа таба:
– Мин, брат,– ди.– «Мең дә бер кичә»дән
Бу дөньяга сикереп төшкән «баба»,
Дөньялыкны белеп бетермим,– ди. –
Так что син китап укы кайтып.
Ә мин менә эшлим әле берсәк.
Арып беткән идем эшсез ятып...»

3

Очып кала көннәр чиксезлеккә...
Йомычкалар оча,
Балта чаба –
Ишек ясый «Мең дә бер кичә»дән

Дөньялыкка сикереп төшкән «баба».
Тирли, авыр. Сүгенеп ала үзе,
Ни дисәң дә әкият түгел инде.
...Чакыртасы иде
Бер мизгелдә
Алтын сарай төзеп биргән җенне.
Көлеп куя аннан карап миңа:
– Давай, канәт, бул,– ди,– миңа вәзир.
«Ач ишекне. Сим-Сим» диясе юк,
Ишекләрне үзем ясыйм хәзер,
Күгән суккач, ачарбыз да каерып,
Кузгалырбыз хәзинәгә таба...

...Шаяртамы, әллә чын сөйлиме,
Моңсуланып китә Гали-баба,
Шундый карт ул безнең Гали-баба,
Киләчәккә бара кар-саз ерып,
Ясап бетергәч тә үз ишеген
Сүзсез генә ачар каерып...

## ТӨШ

Өзгәләнгән аваз изелеп чыкты авызыннан!
Зыңлап куйды караваты –
Сикереп торды картлач төнге өчтә,
Керле одеялын селтәп атты.
Һәм елмайган булды мине күргәч,
Күр, янәсе, абзаң нинди көчле!
Маңгаенда...
Мәңгелек төбендә янган йолдыз төсле
Җемелдәде салкын тир тамчысы.
Тәрәзәне ачып куйдым. Бүлмәгә урман өстендә биегән яңгырның исе бәреп керде. Урман кисүче абзый көрсенеп караватка ауды.

Зыңлап куйды тимер караваты –
Менә кемдә галиҗәнап ул көч!
Пышылдады агай калтыранып:
«Коточкыч төш керде, коточкыч төш.
Беренче кат мондый курку минем.
Ахры, кәбәм, акылымнан язам,–
Кара урман килде өскә шаулап,
Сытып китә иде уянмасам.
Күп кистем мин ул урманны, дөрес!
Урладым да – гөнаһлымын – дөрес.
...Хет хәзер үк керле җаның белән
Җиргә егылып укынырга кереш...
А! Төн минем дустым иде ул чак,
Төнге сәфәрләрне үлеп сөйдем,
Истә әле, таныш каравылчы
Урман пираты, дип сүккән иде.
Сытарга дип килгән танк кебек,
Кара урман шаулап килде өскә.
Бөек дәһшәт! Граната белән
Каршы барып булмый мондый көчкә.
...Таң сызыла. Балта тотып хәзер
Ничек барыйм аның каршысына?
Әйт ике сүз, нинди дарулар бар?
Нинди дару урман каргышына?»

## ШАУЛЫЙ УРМАН — ЯҢГЫР КИЛӘ, АХРЫ

Кырыс яклар, көчең җитсә ярат!
Кулга балта тотып басып торам,
Үсеп чыккан каралтыга карап.

Кулга балта тотып басып торам,
Шаулый урман, уйлар калган тынып...
Юнылган бүрәнәләр ята,
Шәрә кызлар кебек кыенсынып.

Чорлар үтә. Нәсел? Яңа буын!
Кемнәр белә тарихчылар сүзен?
Торган саен буйлар озыная,
Һәм киңәя офыклары күзнең...

Тайгаларда өйләр салып ята
Дала улларының варислары!
...Ә шулай да сагындыра кайчак
Туган якның җиле, арышлары...
Сагындыра-а...

## АТ АБЗАРЫНДА

Томырыла атым.
Күз алдында, бәлки,
Атилладыр аның,
Чыңгыз хандыр.
*Яшьлектәге шигырьдән. 1980*

Ат кешнәгән тавыш ишетелде,
күңелемдә ерак чорлар көлде,
уклар очты, җәя тартылды да,
тастымалны бунчук итте колга.
Аргамакта килде җилдерәсем,
күкрәгемә тутырып дала исен.

Тик кайда соң гаярь җайдак шаны?
Абзардагы йончу алашаны
карап торам менә бик ерактан,
бераз өркеп шушы мәхлук аттан.

Аркан ыргытырга!
Йөгән, ияр...
Кем соң шундый кыюлыкка ия?

Тартылырлар көмеш өзәңгеләр,
күңел яралары төзәлерләр.
Ыргылырга!

Ният анысы чибәр...
Ә монда – йә кушаяклап тибәр,
тешләргә дә мөмкин, һич булмаса,
тау кадәрле зур бер ат лабаса!

Болай гына йончу күренәдер,
төшенәсе иде серенә бер –
хәтерендә, бәлки, борынгы чор,
даладагы чатыр, сузынкы җыр?

Хыялланып аягүрә торса,
һәм җайдакны кинәт җиргә орса?

Җәяү киттем шулай мин – кыюсыз,
«мерседес»та узып китте кырдан –
әллә Атилла булды, әллә Чыңгыз...

# МАКСАТСЫЗЛЫК

Туңган алмагач ботагын
алмалы итәсем килә! –
Зәмһәрир февраль салкыны
миннән ятып көлә.

Кышкы урам, беркем дә юк,
ә мин менә
алмалар алмаска дип барам
иске авыл кибетенә.
Янәшәмнән өшеп бара
алмалар турында бер җыр.

...Бүген алма саталардыр, бәлки?
Бәлки, сатмыйлардыр...
Саталардыр, бәлки.
Бәлки, сатмыйлардыр...

Уза мине бер-ике карт,
танымыйлар гына бары,
алар бик ерак гасырдан:
мәчеткә таба юллары.

Ә мин башка! Мин ашыгам
иске авыл кибетенә,–
алма алмаска өлгереп
булса ярар иде менә...

## ТАПТЫЙ ЯЗДЫ...

Ачы, ачы кирәк! –
Күңелемнең йөкле чаклары.

Җилеп килгән язмыш машинасы,
Сизмичә дә калдым, таптады.
Качып котылып буламы соң аннан?
Язмышыңнан...
Булмый, ди Коръән.
...Ә мин «чур» кычкырам.
Юләр, димә –
Белеп торам,
Әмма кычкырам.
Изеп китте. Мин терелдем кабат.
Һәм боердым үземә: юлга чык!
Нихәл, диләр.
Ә мин:
Менә язмыш
Таптый язды, димен, чукынчык...

*Красин урамы, 1983*

## ӘРЛӘН

Шулкадәр дә акыллы ул,
Шулкадәр дә мөлаем.
Карыйбыз да аптырыйбыз –
Дөньяның белә җаен!

Кушаматы ник әрләндер –
Гаҗәп!

Шулкадәр дә акыллы ич,
Шулкадәр дә шәп!

# БӨҖӘК

Дөнья буйлап китте кеше.
Юлы – ерак йолдызларга таба.
Йолдызлар турында уйлар өчен
Туган җаннар бар дөньяда.
Ул ашыкты.
Белми иде
Бар икәнен җирдә гайбәт, коткы.
Туктап аска карарга да
Вакыты юк иде –
Ул ашыкты.

Кешегә төс түгел мондый тизлек,
Җирдә бүтән исәп, җирдә...
Нәни генә бөҗәк
Аягын тешләде аның,
Мәҗбүр итте бөгелергә...

Нәни генә бөҗәк.
Рәхмәт аңа...
Бәлки.

*Красин урамы, 1983*

* * *

*Газинурга*

Урам чаты.
Ханым чәчәк сата.
Прилавкага гөлләр куйган тезеп.
Тарта безне алар, яратабыз! Менә ханым
Яратамы икән
Ул гөлләрне үзе?
Кыш уртасы. Шул ук урам чаты.
Без басканбыз ханым урынына,
Һәм гөлләр дә ярыйсы ук үзгә –
Исемнәре Шигырь... Сөябезме аны,
Лаекмы без, дустым, шигыребезгә?

## АҺ-ЗАР

*(Яхъя Акъәнгиннән)*

Тауның артында бер елга ага,
Тавышы ишетелми, тик мин сизәм:
Омтыла ул ярсып аска таба
Заманалар салган иске эздән –
Анда аны көтеп ята үзән.

Шәфәкъ монда алсу, кичләр зәңгәр,
Күңелемдә минем – сүнгән таулар.
Курайларын җуйган көтүчеләр
Моңсу сукмаклардан төшсә әгәр,
Көтүләргә кем иминлек теләр?

Ялгыз бер кош мәңге бәргәләнер
Бакчасыз һәм гөлсез урамнарда...
Канатлары – хыял белән хәтер.
Мәгез йөрәгемне! Ул талчыккан, арган,
Котылырмын, бәлки, бу аһ-зардан.

* * *

...Көзне күзләп барам әле.
Яңгыр үтеп китте яңа.
Хәзер минә юеш җиргә
Бурап-бурап яфрак ява.

Ә яңгыры койды гына!
Йөздә бозлы тамчылары.
Табалмадым ышык урын –
Рәхәтләнеп камчылады.

Көзге яңгыр, бозлы яңгыр...
Чажлап торды кызган тәнем.
Юды... Авыр... Җуелдылар
Гүя минем үткәннәрем.

Хәзер минә яфрак ява,
Яфрак күмә минем эзне...
Өшеп, туңып алга барам –
Юллар авыр, юллар изге.

Киләчәкне эзләп барам!
Шушы изге, көзге юлдан.
Көз артыннан язмы, кышмы?
...Онытылган,
онытылган.

# КҮПЕР

*(Поэма)*

## 1

Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? –
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.
*Г. Тукай*

Таш күпердә – бәйрәм!
Ике авыл
Өерелеп чыккан бу көнне,
Бер мин генә ничек читтә калыйм,
Дәшми калыйм әйтер сүземне?
Таш күпердә – халык. Бәйрәм ләса! –
Булгач булсын инде дип әнә
Гали-баба «Әпипә»гә баса,
Һәм такмаклый: «Кай, кай, Ивана!»
Язгы тантана бу. Өләшәләр
Бер-берсенә чиккән кульяулык.
Бөтерелә күпер уртасында
Чуаш кызы. Ымлый елмаеп –
Егет булсаң, ташла[1], янәсе, кем...
Булмый... Әмма биһуш мин синнән:
Яңа сикереп төшкәнсеңдер кебек
Бәширинең хикәясеннән[2].
Алкышлаулар нигә? – Барча халык
Тел шартлата: «Вәт бу теттерә!»
Гали-баба әнә сиңа диеп
Йөгерә-йөгерә чәчәк китерә...

---

[1] Т а ш л а (чуаш.) – бие.
[2] Зариф Бәширинең «Чуаш кызы Әнисә» повестена ишарә.

## 2

Урыслар, татарлар, чуашлар – бертигез.
Алар кешеләр.

*И.Яковлев,*
*чуаш мәгърифәтчесе*

...Китереп бәрә бозлар!
Түзми күпер.
Җыерыла да кабат ычкына.
Багорлар да, колгалар да хәтта
Коткаралмый аны һич кенә...
Сәүдәгәрнең үз кайгысы: тагын
Тоткарлана тауар... Сүгенә.
Күпер булып үзе сузылыр иде,
Буе гына кыскарак менә.
Нишләсә дә – үз кодрәте, ди-ди
Мулла абзый тора – канәгать.
Сәүдә белән алыш-биреше юк,
Аңа рәхәт...– Җәмәгать,– ди,–
Кайгырасы түгел,
Болай да бик әйбәт, иншалла...–
Һәм кузгала... Вакыты юк аның:
Яшь абыстай көтә мунчада.

*

Каз тәне чыкканчы коен!
Кем озаграк суда
Тора ала – иң зур бүләк –
Чи «каз боты» да шуңа.
Сибелә көмеш тамчылар,
Чәчри кояшкача.
Берәү куа, берәү кача –
Мәш килә бала-чага.
Сары балчык – сабын монда.
Үзенә күрә юыну –
Нәп-нәзек муеннарыннан
Тама елга дуены.

Буленмәгән. Беркем әйтми:
«Бу су – безнең ярныкы!»
...Бер якта – чуаш авылы,
Бер якта – татарныкы.
Өйләре эре нараттан,
Тәрәзәдә – гөлләре,–
Төшләренә дә кермәгән
Моннан йөз ел элгәре.

*

Ике авыл... Карсак йортлар –
Түбәләре иске салам.
Ике авыл осталары
Елга аша күпер сала.
Ашыкмый чуаш агае,
Балтасының сабы сынган...
Күпер сук, имеш, бай күршең
Тарантасларда узсынга.
Ашыкмый татар остасы,
Уйлары шул ук, күрәсең:
«Чукынып китсен! Чуаш белән
Юк кыз алып, кыз бирәсем».
Ә күпер кирәк! Тиз, диләр
Сәүдәгәрләр, поп, дәүләт.
«Кыймылдагыз!» Булмый һич тә
Өстәмә түләү даулап.
Даулап кара –
Шундый итеп
Бирерләр берне... Янәсе,
Һаман шул ук әле бездә
«Мә» сүзенең мәгънәсе.

Ачуың ал да агачтан,
Эшлә, туган, башны орып...
Сузыла күпер – сиздермичә
Күңелләрне тоташтырып.

*

Кай арада җил кузгалган:
Кузгалак-кузгалак карлар
Бөтерелә, оча, уйный –
Җилферди кышның туны.
– Җил исә, абзый, дөньяда!
– Иссә соң, исмәгәе...
– Йөзеңне синең кисәдер...
– Киссә соң, кисмәгәе.
– Кышын читендер йөрүе,
Кайларга юл тотышың?
– Кайтып киләм аргы яктан,
Ычтапан дустан кунактан.

Кесәсенә сугып ала...
– Әйдә, тотасыңмы бераз?
Булмый һич янда асырап.
– Гаепләмә, җитми кулым.
Безнең ара – бер гасырлап.

...Күпергә керәбез. Шәп күпер!
Пышылдый оста: «Туктыйк,
Без моны, туганкаем,
Ычтапан белән суктык.
Бернинди ташу алалмас!»
Ни әйтим?
– Афәрин! – дим.

Кайтып барабыз бергә:
Зәйнетдин оста. Мин. Төн.
Чаналы ат уза безне.
Чанада мөсафир.
Кем?

Йомычка-йомычка карлар
Бәрелеп кала йөзгә.

Үз авылыбызга кайтабыз
Ялгыз... кар ерып тездән.
– Җил исә, абзый, дөньяда!
– Иссә соң, исмәгәе...
– Йөзеңне синең кисәдер?
– Киссә соң, кисмәгәе...

*

Чуаш кызы бии. Мин дә аңа
Якынлашам. Бии белмим дә...
Чуаш кызы миңа каш сикертә,
Кулны салам аның биленә.

Карыйм, янда берәү пәйда була:
Кулыңны ал, тутар*, фәлән, ди...
Мин нидер дип авыз ачкан идем,–
Җир чайкалды, күкләр әйләнде.

Мәхәббәтнең тәме иренемдә!
Әллә нинди куе, тозлы тәм...
Карыйм: алда чуаш малайлары,
Артта инде татар тезелгән.

Кара-каршы килдек. Йодырыксыз
Сөю капкасын кем ачала?
Чуаш бердәм халык, һәркем белә,
Качканда да бергә качалар...

Тик... арага очып төшә шулчак
Ап-ак яулык... гүя күгәрчен...
И гүзәлем! Шушы солых өчен
Мәхәббәтем белән түләрмен!

* Чуашлар татарны шулай атый.

## 3

И.Н.Ульянов Чурачыкка[1] берничә мәртәбә килә, мәгариф эше белән кызыксына.

*Документлардан*

Чурачыкның кыр капкасы ачык.
Унлап кеше... Кунак көтәләр.
Озаклады никтер. Көлә-көлә
Җилләр исә, чыга үтәли.

Каршыларга күптән әзер алар –
Мичкәләрдә сыра күперә.
Нигә озаклады? Тып-тын калып
Текәлгәннәр яңа күпергә.
«Әнә килә, әнә!» – Ишетелә
Бер ыштансыз куштан сөрәне.
Зур сакалын рәтли Хүәдер дәдә,
Алга чыга –
Үзен байга саный, күрәсең.

Ә кунакның йөзе көләч болай...
Тик шунысы – аты үшән бик.
«Рәхим итегез!» – Поп абзый да хәтта
Билен бөккән була көчәнеп.

Ипи-тоз күтәргән староста,
Киң елмаю чыккан йөзенә.
Пышын-пышын артта: «Зур нәчәлник,
Шәһре Сембернең бу үзеннән!»
Сораштыра кунак. Җавапларны
Куя дәфтәренә теркәп тә...
– Ә мәктәп юк...

---

[1] Чурачык – чуаш авылы. Революциягә кадәр Сембер губернасына кергән.

Поп тамагын кыра:
– Мәктәп... ы-һы... Мәктәп – чиркәүдә.
Кунак җитди: «Керик берәр өйгә?»
Һәм бер йортка төртеп күрсәтә.
Поп үзенә дәшә, Хуәдер дә
Үзенә әйди, тарта терсәктән.

– Хәерче йорт, ник керергә анда? –
Иярәләр эленке-салынкы.
Салам түбә... Тач алачык инде.
Аңлашыла: Ычтапанныкы!
Идәне җир. Өч-дүрт бала шунда.
– Хәлләр ничек?
– Хәлә-әр... Хәл әйбәт.
Түрдән узыгыз, әфәнделәр. Менә
Тормыш җирдә безнең, бигайбә.

...Балалары елый. Салкын, шыксыз.
«Һәр көнне без шундый мәхшәрдә,–
Кулын җәя хуҗа.– Белмим инде,
Алга таба ничек яшәргә?»
Попның вәгазь әзер: «Канәгать бул!
Бигрәк күпне таләп итәсең».

...Ул арада нуештәге бозау
Чәйни башлый ряса итәген.

*

Күзе чепи балаларга карап
Йөрәк әрни, үзәк өзелә.
Укытырга кирәк сабыйларны.
Якты кирәк алар күзенә.
Кырыслана мөсафирның йөзе:
– Төшенмәүче монда сирәктер –
Офык яктыруын күрер өчен
Чуашларга мәктәп кирәген.

Ычтапан да терелә.– Піччә[1],– диеп,
Кулына аның барып ябыша:
– Без... Зәйнетдин оста белән!
Эшләр идек, валлаһ, ярышып...
Ташламагыз, зинһар, ярдәмнән Сез,
Чуашларга кирәк таяныч.
Бар бәлабез наданлыктан безнең,
Илья Николаевич!

4

Гомумән, ул (И.Н.Ульянов)
Сембер губернасындагы чуаш
мәктәпләре өчен күп эшләде.
*И.Яковлев*

Менә тагын җил кузгалды.
Кузгалак-кузгалак карлар
Бөтерелә, оча, уйный –
Җилферди кышның туны.

...Чикмәнле чуашларга
Илтә аны юлы.
Эх, күчсә инде һәркемгә
Җанындагы җылы...
Гасыр ахыры гына бу,
Караңгы төн, кысан, тар.
Унҗиденче елга кадәр
Шактый юл үтәсе бар.
...Ач-ялангач халыкларга
Илтә аны юлы.
Эх, күчсә иде һәркемгә
Җанындагы җылы...
Кем әйтә: башка халыклар
Акыл ягыннан түбән?
Бирегез кулларга китап,

[1] Піччә (чуаш.) – олы кешеләргә хөрмәт белән эндәшү.

Һәм баш өстенә түбә!
...Гади кешеләргә илтә
Ульяновның юлы.
Эх, житсә иде һәркемгә
Жанындагы жылы...
Аракы белән томалап
Күзәнәкләрен минең,
Томана тамгасы сугып,
Алып өнен,
Бетереп булмый халыкны!
Тырышулары әрәмгә.
Уяна ул – тәхетләрне
Китерә чәлпәрәмә.
Махы бирмәс Зәйнетдиннәр,
Ычтапаннар бу көрәштә,
Ирек өчен изге яуда
Изелгәннәр – янәшә.

*

Ул ышана – үтәр еллар,
Илдәге һәр халык – һәр! –
Тик урысча гына елар,
Урысча гына көләр.

Тик әлегә үз кадерен
Үзе белми бу токым.
Инжилне төртергә кирәк –
Кычкырып: укы, укы!

Киребеткәннәр, однако,
Чукын, дигәндә генә,
Ашыга чуаш агае
«Изге имәнлегенә».

Татары инде басурман,
Ул бары Алла колы...

Санга сукмый хәтта бөек
Ильминский акылын.

Шуңа да мәктәп салырга!
Бүрәнә, кирпеч, измә...
Һәрберебез урыс булса,
Беркем беркемне измәс...

Э-эх, күчсә иде шуларга
Җанындагы бу җылы...
Ул үткән эздән җил исә,
Кар белән каплый юлны.

Ул белми әле: малае,
Кузгатып шушы җилне,
Зәһәр зилзилә куптарып,
Болгатып ташлар илне.

*

Бәпкәләре торгызылган,
Уйган инде тәрәз дә,
Киң итеп, кояшка таба –
Менә безнең дәрәҗә!

Ашыгалар. Өмә белән.
Монда барсы үз әле.
Кычкыралар: «Бер, ике, өч!»
Һәм кемнәрдер: «Вз-зяли!»
Э-эх, авыр бүрәнәләр! –
Аргы якка чыгасы...
Атлар түзә. Кешеләр дә...
Бары күпер чыдасын!
Нык торсын – ике ярга да.
Батырып тырнакларын,
Күрсәтә дөнья, күрсәтә
Безгә төрле якларын.

Э-эх, авыр бүрәнәләр!
Күпер генә чыдасын,–
Дилбегә белән өстерәп,
Аргы якка чыгасы.
Ташып тора Зәйнетдиннәр,
Хүәдерләр күтәрә.
Тырышалар «шәп итәбез»
Дигән сүзне үтәргә.

Зур булсын ул, булсын биек,
Ике авыл балалары,
Белем эстисе диеп,
Эшлиләр. Шундый замана –
Күп әле эшләнәсе.
Офыкларда алсулана
Яңа гасыр шәүләсе.

## Ахыргы сүз

Таш күпердә бәйрәм дәвам итә.
Шундый көндә вакыт әрәмме? –
Килдем менә бии белмәсәм дә,
Карап тордым язгы бәйрәмне...
Тоташтырды күпер ике ярны.
Ярлар бер-берсенә тартылды –
Менә-менә кушылырлар кебек...
Ләкин төрле шау-шу аркылы
Сулар челтерәвен ишеттем мин,
Тавышында аның моң-аһәң.
Нинди моң ул? Белмәс идем, бәлки,
Бу күпергә әгәр килмәсәм...
Субайлары таштан. Ышанычлы –
Әле тагын мең ел торырлык.
Туктый калсаң – күперең булсын икән
Гасырларны тоташтырырлык.

*1985*



# III БҮЛЕК

*Икенче көнне, мин уянганда, көтүче егет юк иде инде. Атлар тау итәге буйлап таралган, чыбыркы күтәреп аларны бер урынгарак җыя-җыя көн уртасы җитте. Чишмә янына менеп учакка ут өстәгәндә, мин бик арыган-талчыккан идем. Нигәдер миңа моңсу булып китте. Теге егеттән калган курайны алып иренемә терәдем. Дөнья сәер авазлар белән тулды. Атлар, утлаудан туктап, башларын миңа таба суздылар. Шунда мин тау итәгеннән менеп баручы бер кызны күрдем. Ул, минем янга туктап, курай уйнавымны тыңлап тора башлады.*

*Аның зәп-зәңгәр карашыннан кыенсынып китеп, кураемны читкә куйдым. Кыз, иңбашыма орынып ук, янәшәмә чүгәләде.*

*– Оста уйныйсың...*

*– Беренче тапкыр курайны тотам әле,– дидем мин, үзем дә гаҗәпләнеп.*

*– Сиңа ашарга китердем,– диде ул. Тырысыннан бер телем икмәк, әрекмән яфрагына төргән куй итен чыгарды.*

*Без икәү казан астык, анда куй ите быгырдады, корымлы чәйнектә хуш исле чәй пеште.*

*– Китмә,– дидем мин.– Монда миңа берүземә генә күңелсез.*

*– Исемем – Таңсылу,– дип җавап бирде ул.*

*– Китмә...*

*Ул елмайды:*

*– Ялгызга һәркайда сахра,– диде.*

*Аста, калкулык итәгендә, Япанчы аргамагы кешнәде, чемкара яллары офыкка таралды.*

*Кызның иреннәреннән җир җиләге тәме килә иде.*

*– Без беркайчан аерылышмабыз!*

*Ул челтерәп көлде.*

*Күктә йолдызлар сикереште, ниһаять, ул, хәлсез юрган сыман, безнең өскә сыланды.*

*Төшемә тагын Хозыр Ильяс керде. Ул инде берни дә эндәшми, таягын гына җиргә бәреп-бәреп куя иде.*

*Таң алдыннан мин уянып киттем. Таңсылуның чәченнән сыйпадым, алсуланып торган яңакларына учымны тидердем. Ул уянмады.*

*Кояш күтәрелгәндә, мин бу калкулыктан еракта идем инде. Кайдадыр артта дөпелдәп атлар чабып узды, чыбыркы шартлаган тавыш ишетелде.*

*Мин елмаеп куйдым. Мәгарәгә кадәр юл ерак иде әле.*

## ЕЛЛАР АША

Туган якның төннәре дә якты!
Бу – син яккан учак балкышы,
Еллар аша шул төннәргә төшә,
Мине эзлидер күк ялгышып.

Ә мин җуйдым, җуйдым сурәтеңне,
Беркемгә юк кинә-битәрем...
Сагынуым! Сусаган җыр сыман
Сусыл йолдызларга күтәрел...

О, ул сүзләр, хатлар, затлы антлар –
Хата гына. Нишлим, хаталы...
Безнең мәхәббәтнең юрганы – күк,
Ә туган җир булган ятагы.

Ятлар – якын хәзер, якыннар – чит,
Читәне юк бакча, әйтерсең,
Минем аша үтә бөтен җилләр,
Саегая бара хәтерем.

Туган якның төннәре дә якты,
Безнең якта шундый төн инде...
Еллар аша орынды ул миңа,
Актарды да салды күңелне.

* * *

Бернинди аваз да килми, ишетелми
Кичәге шаян челтерәү – чишмә көлми.

Иеләм, янә күзәтәм: ул нинди соң
Кизләү күзенә гизләнгән сихерле моң...

Өстәге гөмбәз дә сыйган – айлы гөмбәз.
Коелмас йолдыз тузаны, миңа тимәс.

Көтәм ич һаман сәмави аваз өстән.
Галәми сагыштан мәллә мин күшеккән?

Төннәрдә кеше күшегә, өши, туңа,
Кайчаннан бездә ихтыяҗ яратуга?

Шифалы, имеш, сагыштан арытканда
Йөземне куям тузанлы әрекмәнгә.

* * *

Үлән ерып йөгердек без икәү.
Чикерткәләр канат кактылар.
Җиләс һава эзләп аудык җиргә,–
үлән арасында якты бар.

Ак каеннар сыман яктырган көн!
Җирдә август... Зәңгәр чатырда
мөлдерәмә бу табигать үзе
безне кавышырга чакыра.

Гөл таҗлары ачылалар сусап,
күзләр бер-берсенә ымсына...
Якты сагыш, шыпырт куанычлар –
төнгә тоташачак тылсымда.

## ШӘҺРИ БОЛГАР

Салкын ташка учны тидердем дә
Зыңлап куйды кара манара...
Күзен кысып җиргә төбәлгән ул,
Урын эзли гүя аварга.

Шәһри Болгар – татар милләтенең
Җан җиредер...
Шул хис бу якта.
Үрчем орлыкларын чәчеп илгә
Манарасы торган һәр чакта.

Бер кыз белән үрмәләдем өскә,
Астыртын хис миңа күчмәсме?
Тик диварлар шома, баскыч текә –
Сынды кызның туфли үкчәсе.

Кулын сузып миңа авышты ул,
Бер мизгелгә бары... Бер ара...
Күк гөмбәзе баш түбәмә тамды,
Йолдызларга очты манара.

И табындык зирәк бабайларга, –
Без тезләнгән ташлар кап-кайнар!
Безнең дәртле сөю сүрәләрен
Тәңре тыңлар, Тәңре абайлар.

Диварлары шома, баскыч текә, –
Җитәкләшеп төштек.
Чорларны
Ияртек без... Алар кайнарланып
Муеннарга килеп чорналды.

Без китәрбез акрын гына моннан,
Кан уйнатып килер тагын яз...
Күмелер дә киткән сукмагыбыз,
Беркем, беркем безне сагынмас.

Ләкин килер кемдер бер кыз белән,
Өстә аны алыр кочакка...
Мең ел элек торган манаралар
Күккә алгысыныр шул чакта.

## КҮРГӘЗМӘ

Хәрәкәттә туктап калган сылу:
Мизгел булып үтәр гасырлар,
Мөлдерәтеп күзен тукымада,
Рәссамыннан бер көн җан сорар.

Тими микән сөт тәненә аның
Ул төннәрнең шыксыз салкыны?
Һәрбер тыннан, һәрбер ишарәдән
Күләгәләр куя кымшанып.

Татар кызын – шул мәңгелек ярны –
Яратып ул судан, утлардан,
Кайсы яудан йолып алган икән,
Кайсы золымнардан коткарган?

Бүтән телдә сокланалар аңа,
Үзгә күзләр бирә бәясен.
Татар кызы кан тамырын түгел,
Телебезне хәзер бәйләсен.

Туктап калган әнә хәрәкәттә.
Мизгел булып үтәр гасырлар.
Мөлдерәтеп күзен рәссамына,
Кайсы телдә сылу җан сорар?

Чәчеп ташлар безне Ахырзаман,
Йә җил белән килеп, йә силдә...
Урманчының җаны иңәр кызга,
Дәвам кирәк булгач нәселгә.

# НӘНИ БЕР СЕР

Җылы бүлмәдә салкын ылыстан
Бөркелә кышкы урман һавасы.
Сискәнә дә җан – җил булып исә,
Ап-ак кар булып килә явасы.

Күздән югала дуслар, танышлар,
Эзләрендә тик карлар тузаны...
Курантлар чыңын көтәм мин ялгыз,
Сизмим – сезнең күк! – гомер узганны.

Кемдер озата, кемдер каршылый...
Сынык күңелгә бармы дәвасы?
Җылы бүлмәдә салкын ылыстан
Бөркелә кышкы урман һавасы.

Ел саен безнең шул ук өметләр:
Килергә тиеш миңа дигәне...
Киткәннәргә мин күптән битараф,
Искәрмим инде юкса килгәнне.

Дөньяның ләкин нәни сере бар,
Минем өчен дә кемдер тырышкан:
Бөркелә кышкы урман һавасы
Җылы бүлмәдә салкын ылыстан.

## ТЫҢЛЫЙСЫҢМЫ?..

Тыңлыйсыңмы, яңгыр ява тышта,
Гүли-гүли җилләр исәләр?
Син нишләрсең, ятлар килсә әгәр,
Яратмый ул сине, дисәләр?

Тыңлыйсыңмы, йолдыз тәлгәшләре
Җилләр искән саен коела?
Сизәсеңме, диңгез дулкыннары
Йөрәгемә килеп сыена?

Тыңлыйсыңмы? – Мондый язмышларны
Беркемгә дә бүтән теләмә...
Синең генә бары күзләреңдә
Болытлардан төшкән күләгә.

Тыңлыйсыңмы? – Безгә кадәре дә
Бу гөнаһлы җиргә килгәннәр.
Хыялларны алып үзләренә,
Офыкларга ага җилкәннәр.

* * *

Яна йөрәк, шаша җаным,
Таша дәрман, таша дәртем,
Каян эзлим?
Ник табылмый
Җан ачкычы-мәхәббәтем.
Җаным бикле килеш кала,
Эчтән ярсыйм,
Эчтән янам.
Тынгы бирми миңа һаман
Элеккедән калган ярам.

# САУБУЛЛАШУ

Җәйләр үтеп бара, дисең,
Ул шул табигать эше.
Хәтердә калыр бу җәйнең
Берничә күренеше:

Тын суга ышкылып үткән
Ишкәкләр чупылдавы...
Көймәдәге балыкчыга
Баш игән тупыллары.

Моңайта... Нигә моңайта?
Шундый көн бу югыйсә –
Күкләр аяз, сулар тыныч,
Әкрен генә җил исә.

Җәйләр үтеп бара, дисең,
Гомерләр үтә әле!
Берничек булмый озайтып
Илаһи мизгелләрне.

Яр комында синең эзләр...
Нинди хозур, и Мәүлам!
Истә калыр... Мәҗбүр итәр
Суда чагылган шәүләң.

* * *

Сәфәр китәм еракларга, –
Күтәрдем җилкәннәрне.
Алга дәшеп яна йөрәк,
Ә үзе никтер әрни.

Сәфәр китәм еракларга,–
Саф күңел, ап-ак җилкән.
Тик нигәдер әрни йөрәк –
Аерылышу авыр икән.

Каян эзлим сине, дисең,
Сагынган чакларымда?
Кемнәр кулын бирер, дисең,
Абынган чакларымда?

Сәламнәр җибәреп сиңа,
Юксынып җырларымда,
Чәчәкләр сибеп барырмын
Мин үткән юлларыма.

Учак ягармын төннәрен,
Утым биектә янар,
Шул җирләрдән эзлә мине –
Эзләрем булыр кайнар!

* * *

Битараф идем дөньяга,
Тыныч иде җаным;
Йөрәгем дә болай типми,
Кызмый иде каным.

Күп йөри алмадым әмма
Гамьсез күзләп айны:
Шомырт чәчәк аткан кичне
Килде миңа «кайгы».

Сөю тотты да тынлыкны
Урлап китте тәмам.
Хуш, тыныч яр! Саумы, диңгез!
Дөрлим, дулкынланам.

Давыл белән кочаклашып
Алга йөзә көймәм.
Күңел ярга тарта, үзем
Тагын эчкә керәм...

* * *

Җир белән күк тоташкан,
Шашына, дулый Идел,
Ә мин тыныч.
Тәкрарлыйм:
Нигә мин дәрья түгел?
Нигә мин дәрья түгел?

Табигать оеп ята,
Илаһи тыныч Идел.
Ә мин ярсыйм.
Тәкрарлыйм:
Нигә мин дәрья түгел,
Нигә мин дәрья түгел?

* * *

«Нигә моңаясың?» – дисең.
Йөрәк дөрли, күзем сүнгән...
Сары умырзая исе
Аңкып тора чәчләреңнән.

Хыялымда – гарасатлар,
Алга дәшә давыл кошын.
Ә мин сиңа иелгәнмен –
Чәчәк исе татлы да соң!

Аулак. Өйдә тик икәү без.
Баштан сыйпый җылы кулың.
Җәй исеннән исереп ятам –
Ә урамда буран дулый.

* * *

Чәчәктән чәчәккә очып йөрде ул көн бал корты. Галәм буйлап күләгәләр йөгерә, күләгәләр йөгерә. Бал корты, нурларга тотынып, иң ерак чәчәккә юнәлде. Үзенә алырга барамы, үзен бирергәме – беркем төшенмәде.

Хәер, түгелмени барыбер?.. Кавышу сагышының шаһитлары булырбызмы киләчәктә?

Күләгәләр йөгерә галәм буйлап.

## ҮКЕНҮ ХИСЕ

Сүрән генә үрли төтен
бәрәңге басуыннан,–
нечкә билле кызый гүя
сарыла йөрәгемә...
Сәер бер маза кузгала
күңелем ызанында:
кирәкмәсне күп яздым, ник
сүз тапмыйм кирәгенә?

* * *

Кил, сөеклем, ташлан кочагыма,–
Үрсәләнеп минем җан яна!
Син ут өстә аңа, мин бит бары
Янар өчен килдем дөньяга.

Мин авармын бер көн яна-яна,
Бу дөньядан алган ярадан.
Һәм анда да дөрләр өчен, җаным
Тәмуг сорар кебек Алладан.

# БЕР ӨМЕТ

Авылыма мин бик сирәк кайтам,
Урамнары хәзер тар аның.
Карап узам сезнең уйчан йортка,
Тәрәзәңдә ут юк – караңгы.

Чыр-чу килеп әтәй-әнәй чыга,
Әби килеп җитә...
Мин кайттым!
Ни таптым мин туган яктан китеп?
Беләм ләкин: нидер югалттым.

...Иртән басу капкасына кадәр
Миңа күрше эте тагыла,
Һәм кагыла кояш нуры йөзгә,–
Ул ягымлы бүген тагын да...

Сезнең уйчан йортка карап узам,
Йоклыйсыңдыр. Китәм күрешми.
Атлап узар идем бусагаңны,
Шәһәр кешесенә килешми.

Күңелеңдә синең мин түгелме,
Түгелгәндә төнлә яшьләрең?
Мин бит басу капкасында гына...
Эндәшерсең, бәлки, дәшәрсең?

* * *

Йомылдылар йолдызларым –
Кичкә каршы килде буран,
Горур гына авылыма
Күз сирпеде югарыдан.

Урам буйлап кайтып киләм,
Җил сызгыра, оча кары...
Күңелләргә керде буран –
Хәтерләрне, әй, актарды.

Төне буе сызды бәгырь,
Йоклый алмый бәргәләндем,
Үтте гүя минем аша
Бар газабы бу галәмнең.

...Иртә белән тынды менә.
Шатлыгымның бармы чиге?
Башын салып йөрәгемә
Эреп ята кар бөртеге.

## БЕР СҮЗ

Янәшәңдә берәү йөри.
Җитәр!.. Йөрмәсен,–
Синең куе бөдрәләрең
Шәфәкъ дөрләве...

Йөрмәсен! Бүген мин аңар
Бер сүз әйтермен,–
Дөньяның иң мәҗнүне дә
Җыяр чатырын...

# МАНЗАРА

*Фәридәгә*

Ут көлтәсе шуып узды судан,
Ни эзләде һәм ни югалткан?
Ромашкалар исен китерде җил –
Кемдер үзенең сөюен юраткан.

Төнге Идел.
Һәркемнең үз уе.
Һәркем үз җанының яраны...
Ярдан ярга әсир су чайкала –
Кеше күңеле кебек караңгы.

Чишендем дә суга кердем ишсез.
Ярда калды дуслар өстәле.
Исенә төшәрменме берәрсенең,
Учагыма чыбык өстәрме?

Болыт ишелә дөнья өсләренә,
Өзелеп киткән гүя ычкыры*.
Яр башында, сыңар куаклыкта,
Бер сандугач куйды кычкырып.

Төнге Идел.
Сулышына кадәр
Табигый ул, монда юк ялган.
Ут көлтәсе генә гасаби тик.
Кемне эзли?
Кем соң югалган?

---

* Ычкыр – бау.

## ЮКӘЛӘР

Хуш исле юкәләр арасында сине
Эзләдем, өзелеп эзләдем.
Коелды тамчылар күз яшьләре булып –
Ерак йолдыздай кабынды күзләрем.

Хуш исле юкәләр арасында тагын
Адаштым, мәңгегә адаштым.
Киек Каз Юлымы сиңа таба илтә,
Кайсы йолдыздан сирпелә карашың?

Хуш исле юкәләр арасында инде
Калырмын шикелле, калырмын...
Таңнарда ялгызым мәңгелеккә таба,
Ерак йолдызга таба юл алырмын.

* * *

Нигә аңа тартыласың, диләр...
Бик гадәти кыз югыйсә:
Бүтән кызларныкы кебек
Ике колагы бар, ике күзе...

Мин үзем дә күптән түгел белдем
Башкаларга охшамаганын:
Колаклары икәү генә икән,
Күзләре дә икәү икән аның...

## САХРАЛАРДА, СУДА

Сөмсез саран сахраларда, синсез
Сары сусыл сачәкләр сула...
Сагышландым, сыгылдым, сындым...
Сулкылдады, сыкрады сулар.

Саташкандыр сәер сәмави –
Сискәндереп селекте сүсен.
Сахраларга сибелде сәйлән,
Суалчандай сөйрәлде сүзем.

Суырылдым – сыенйым сана,
Сабыр савытларым сусыз ла...
Сөрән салма, сүрән сагыздай
Сансыз сәях сиңа сузылса.

Салларгамы салыйм санымны? –
Сусаганга суык сулар сый...
Сулышымда серле, сихерле
Сак-Сок сагышлары сулкылдый.

Сөрем сарган сөрсегән сурәт
Сахраларда, суда... Синдерме?..
Сулышымны сөрттем сакланып.
Сәламемне силләр сүндерде.

## ИКЕ КЫЗЫЙ...

Йөгерделәр тәңгә таба...
Әйтерсең лә ике җәнлек.
Туңган карама төбендә
Калды егет икеләнеп.

Аһ, кызыйлар, сылулар сез.
Икегез дә бер тиң!
Кайсыгызга сүз кушсаң да,
Ялгышырга мөмкин.

## КАПКА ТӨБЕНДӘ

– Мин сине яратам бугай,
Кайчан күрешербез тагын?
– Җиргә кызыл кар яуганда
Безгә килерсең, аппагым.
Ә хәзер бар, керим инде...
Әни битәрлидер анда.
Кызыл карлар явар җиргә
Абага чәчәк атканда,
Шул чакта син кил, аппагым.
– Мин сине җибәрмим, иркәм!
– ?!
...Иренгә ирен кушылды,
Тезләр беректе тезләргә,
Сиздермичә, сиздермичә
Кызыл кар төшә күзләргә.
Кып-кызыл кар, кып-кызыл кар.

Ә якында тып-тын гына,
Яман күздән яшеренеп,
Чәчәк ата абагалар,
абагалар...

# СҮЗЕМ

Йөрәгеңә бәрелеп, читкә очты,
Беркемне дә хәзер булмый тиргәп.
        Җиргә
Бүген кар сибәли, туташ.
Кар сибәли җиргә...

Беркайчан да Мәҗнүн булмадым мин!
Ут элдереп булмый сулышымнан.
Тырыштым мин сине яратырга...
Артыграк, ахры, тырышылган.
Үз сүземне хәзер эзләп йөрим.
Өн саласы килә буылып-буылып.
                                        Ә сүз
Кар бөртеге булып
                        бөтереләдер җилдә
Йә
Ятадыр җирдә,
                    иске акча булып.
...Җаным рәсемен ясыйм тәрәзәңә...
Тик көлмә син, бул син мәрхәмәтле.
Тының җитмәс барыбер...
Ә дөньяда
Ертык кесәле тун йөри...
            Таңга хәтле...

## КЫЗ УРЛАУ

Аһ, бу кышкы юллар... Кышкы юллар!
Гомер уза, диеп пошынулар.
Кышкы юлда атлар пошкырыша,
Күзләремә таба төн шуыша.

Ачы итеп сызгыралар кырда,–
Юлбасармы мине көтеп тора?
Чакырамы әллә ат карагы? –
Караңгының иң куерган чагы.

Офыкларда утлар сикерешә,
Бии-бии кемнәр соң көлешә?
Карга әверелгән ябалаклар
Коелып кала... Алга чаба атлар.

Ачы итеп сызгыралар кырда...
Атларымны кирәк сугарырга.–
Кое янындагы син ялгыз кыз! –
Миңа көмеш чиләкләреңне суз.

Аунап калсын алар кар өстендә,
Толпарларым кушылсыннар төнгә.
Йолдызларга кадәр сибелсен кар.
Аһ, бу кышкы юллар... Кышкы юллар!

## ЧАГАН

Юл чатында берьялгызы
Басып тора чаган.
Җем-җем иткән карга карап
Тирән уйга калган.

Сыгылмаган давылларда –
Гайрәтле ул, көчле,
Басып тора, көрәшергә
Чыккан батыр төсле.

Тик нигәдер башын игән
Шундый серле мәлдә.
Сөеклесе очрашуга
Килмәгән
мәллә?..

## МӘҖҮСИ ДОГАСЫ

Ташка күкләрнең сулышы ашкан.
Кодрәтле җилләр, һава, яңгыр.
Кыяга менүчеләр!
Өстә исүче җилләрнең телегезгә тидереп карадыгызмы тузанын?
Диңгезләр безне яратып көлде.
Кодрәтле җилләр, һава, яңгыр!
Тамырларын ташка батырган җан иясе – куак.
Хәтеренә аның һаман үзән килә. Үзәндә калган туганы, озынбиек туганы. Кайсы югарырак? Кемнең кайда туган җире?
Түбәндә калган туган җир. Күңеле аның анда. Ә туган җир уйда. Уй исә адашып йөри йолдызлар арасында.

# КӨЗГЕ УРМАНДА ТӨНЛӘ...

Күз яшең түкмәсәнә! –
йотты урман яшенне,
яшерде бүксәсенә.

Шулаерак яшибез:
йолдызлар бара йөзеп...
ә күк йөзе яшенсез.

Авышты гөмбәз менә,
кайсы йолдыз тавышы
үзәкне өзә генә?

Үзәкне өзә ярда
адашкан йолдыз тавышы...

Бүселә урман, яга –
яфракларга ут каба,
ут каба бүксәсенә.

Күз яшең түкмәсәнә...

* * *

А, чибәрлек!
Ләззәт,
нечкә бил,
тән.
Бернәрсә дә кирәк түгел бүтән.
Бер елмаеп бакса чибәр кызый,
Иманны да таптап була икән.
Нәселеңнән генә баш тарт бары,
Ачылырга тора кочаклары.
Аның телен, денен кабул ит тә
Чит туфракта кабыз учакларны.

...Ни уйлый бу, дигән сыман әнә
Күзләремә текәп карый Заман,
Бу ирнең дә йомшак бәгыренә
Үрмәләмәсме, дип, кара ялган.
Юк!
Онытылырга ирек бирми әле,
Офыкларда һаман дөрли әле
Мәхәббәткә денен алмаштырган
Шәех Сананнарның
йөрәге.

# ӘРӘМӘЛЕК

Алгысынам, сандугачлар
Сайрый башласа әгәр.
Төнге җилләргә кушылып
Сайрыйлар таңга кадәр.

Көмеш сулы инешләрнең
Челтерәве күк әнә
Тар күкрәктән киң дөньяга
Юл эзли... Чәбәләнә...

Тик көндез ник ишетелми?
Челтерәсен иде бер.
Өнсез-тынсыз әрәмәлек.
Әрәмгә үткән гомер.
Дәшми генә көтәләрме
Әллә соң бүләк-фәлән...
Юк!
Аларны Алла күптән
Моң белән бүләкләгән!
Әрәмәлек өнсез-тынсыз.
Өзелгән төнге яме.
Моң бетә ул, башка төшсә
Әгәр җим эзләү гаме.

* * *

Кара каргалар яз алып килә,
Сөю килә язлар белән бергә.

Җирдә язлар! Сәҗдә кылам аңа,
Баш идерә сөю, тезләндерә.

Каргаларның шаулы төркемнәре
Канат җилпи зәңгәр күгебездә.
Тернәкләнә буран күмгән күңел,
Кояш күргән күзләр инде үзгә.

Кара диңгез шаулый зәңгәр күктә,
Шашкын дулкыннарда сине күрәм.
Җирдә торган саен бу язларны
Кабат өйрән икән...
кабат өйрән.

Сөю килә, ахры, миңа шулай,
Кошлар белән бергә, язлар булып.
Мин дә кеше нәселеннән, Тәңрем!
Күк йөзендә бүген кара болыт.

# АЛМАГАЧ

Күк йөзендә язгы кояш!
...Шундый күңелле көндә
Яшь тамчылары җемелди
Алмагач кәүсәсендә.

Ташлап киткән аны хуҗа,
Ташлаган, игелексез.
Бәхет монда гына түгел,
Янәсе, җирләр чиксез.

Кышкы кардан ачылган җир
Чәчүне сорап ята!
Алмагач көтә хуҗасын,
Ак чәчкә ата-ата.

...Үтте көннәр. Өмет – шул ук.
Көткәннәр һәрчак түзем:
Ботакларда аңа дигән
Алмалар пеште көзен.

...Ул әйләнеп кайтты кире,
Тик шундый салкын көнне –
Алмагачның яфрагы да
Коелган иде инде.

## ЧИЯЛӘР

Тузан сарган асфальтка
Чәчелде чияләре.
Шундый ашыккан чакта!
Шундый ашыккан чакта.

Асфальтта чия, чия...
Мәхәббәт күгендә янган
Моңсу йолдызлар гүя.

Чияләр эре, эре...
Чияләр көтеп ятадыр
Өйдә авыру ире.

Чияләр кирәктер дә...
Ә алар өметләр кебек
Сибелеп ята җирдә.
Изелеп ята җирдә.

«Түз инде, түз, түз, җаным!»
Чәчелгән чияләрне
Бөртекләп җыя ханым.

# ТУЙЛАР

Туйлар гөрли туган авылымда,
Шәраб исе аңкый, бал исе.
Агыла көй җиргә тальяннардан –
Җырлыйсы ла килә, биисе!

Кияү белән яшь кәләшне алып
Алга ыргылалар тулпарлар.
Җиз кыңгырау моңы яңрап кала,
Сибелеп кала биткә җылы кар...

Идән генә түзеп торсын бары –
Ишетелә бию тавышы!
Шатлык белән сугарылган дөнья,
Тик нигәдер бераз сагышлы.

Кешеләрдә затлы кием балкый,
Ә атларда көмеш йөгәннәр!
Исем китеп торам: хәтта картлар
Сакалларын кырып җибәргән!

Кияү белән яшь кәләшне алып
Аргамаклар юлга ыргыла.
Җиз кыңгырау моңы яңрап кала,
Көләч яшьлек кала кул болгап...

Бу юлларда йомарлансын йөрәк,
Ләззәт биреп тәнгә – сызласын!
Җаннар гына сыкрап сыгылмасын,
Сөю генә читләп узмасын.

Туйлар гөрли, туган авылымда
Шәраб исе аңкый, бал исе.
Агыла көй җиргә тальяннардан –
Җырлыйсы ла килә, биисе!

* * *

*Л-га*

Барча шигыремне сиңа багышлыйм бүген,
Синсез алар ятим.
Нигә, димен – һәм кирәкми җавап.
...Бетте...
...Без хушлаштык инде...
Ләкин
Яткан сәгатьтә бүтәннәр
Җылы куенында –
Муенында минем ирен эзләре
Сулкылдап уятыр сине...
Сулкылдап уятыр сине кайбер төннәрдә,
Моңаерсың сыенып салкын мендәргә...
Искә төшәр яратмаган, яраткан,
Һәм шигырем,
тышауларын ташлап,
йөгерә башлар синең тарафка...
Башка чорда, башка чатырларда,
Бәлки, булыр кадер?
Каде-ер...
Шигыремнең күлмәге сиңа
Мәҗнүн кульяулыгын хәтерләтер.

* * *

Җиргә караңгылык иңде кабат,–
Йолдыз булып кабын, бәгырем! –
Тетрәнсен күк!..
Ярсу ташкын булып
Актарылган чагы шагыйрьнең.

Тыныч кына карап буламы соң
Төннең җанга сагыш өюен?!
Юкка чыга, эреп бетә әнә
Ятлар кочагында сөюем.

Бу төн миңа сагыш алып килде,
Алып килде менә яңа җыр.
Газапланам, ә ул ят кочакта
Ләззәтләнеп эреп ятадыр.

...Көн дә үтте. Моңсу гына хәзер
Күзләргә төн бага, ниһаять.
Берәүләргә кайнар сөю килә,
Берәүләргә килә хыянәт.

## САБЫР

Нигә әрем тәме сүзләремдә?
Ә күзләрем нигә төссез бүген?
Абындым мин. Тагын алдадылар –
Тартып алдым тәннән дошман угын.

Күнегеп шул булмый җиңелүгә,
Җиңел кичереп булмый, авырта бит!
Мөмкин кеше хәтта җиңеләергә...

Тик ашыкма, сабыр,
сабыр, табиб,
Өлгерерсез көчләп җиңеләйтергә.
Мин яралы бүген.
Күңел үчтә!
...Хәер, нинди үч ди. Үч юк. Бары
Ук ярасыннан кан ага әчкә...

* * *

Җемелдәп китте төш
Юеш мендәрдә...
Минме ул – төшемдә елап җибәргән?
Мин яшерәм, яшерәм,
Мин яшерәм, кешедәшем –
Сокландырмый кырыс ирнең
Илереп елавы,
ул күз яше.
Тик синнән, иркәм, моны сер итеп
Саклап булмастыр, беләм.
Томалап буламыни күңелне
Алебастр белән.
Еладым, еладым... үкседем
Ялварып, ярдәмгә дәшеп.
Йоклаганда да еламагач,
Кайчан чыксын
ул күз яше?

## САУ БУЛ!

Өстәде язлар дәртле ялкынын,
Кошларга карап өскә талпындым.
Сәламнәр юллыйм алсу болыттан:
Мин сине, ярым, мәңге онытмам!

Зәңгәр күзләрдән сирпелә ләйсән,
Гафу ит мине, кабат килмәсәм.
Кемнәр юраган гомер юлларын? –
Йөзеңә тидер чишмә суларын.

Чишмәләр инде миннән еракта,
«Сау бул!» димәдем аерылган чакта...
Сау бул син, сау бул, син – мәңгелек яр!
Арада юллар, арада еллар.

Кояшка таба кошлар талпына,
Орынам мин дә соңгы ялкынга...
Моңсу төн тама ике канаттан,
Мин сине, ярым, мәңге яратам.

* * *

«Яратамы, яратмыймы?» – Дөнья
шул сорауга эленгән дә калган.
Икеләнә, җавап эзли әрнеп...–
кеше – ялган, дөнья үзе ялган.

Күзгә карап мыскыл белән көлә
мәңге ерак, мәңге якын да яр...
Шуның өчен тагын кан түгелер,
күпме кеше күпме җанны кыяр.

«Яратаммы, яратмыйммы?» – Ә юк,
Нидер буар төсле йөрәгемне,–
Ромашкалар калган сирәгәеп.

Инандырмак булам икән кемне?
Яратамы, яратмыймы, диеп,
Күз яшьләре йолкый керфегемне.

* * *

Мин камышка сине охшаттым.
Күзләреңә күңелем бушаттым.
Кил, шикләнмә инде, шикләнмә:
Ошаттым мин сине, ошаттым.

Тәнең назланырга кыймады.
Күңелем күзләреңә сыймады.
Яңгырларның кояшлысы да
Кыйнады ла мине, кыйнады.

Куш йолдызлар белән пошындым.
Ә син чишмәләргә кушылдың.
Мәхәббәтнең язы синдер шул...
Мин, ахрысы, аның кышымын.

Камышларга сине охшатмыйм.
Күңелемне кемгә бушатыйм?
Сагыш, сагыш, сагыш асылда...
Сагыш, сагыш –
анасын сатыйм!

* * *

Мин сине яратмадым.
Мин сине сагынмадым.
Башларымны да югалтып,
Мин сиңа табынганмын.

Исә, исә, исә җилләр,
Сәлам дә юк, хәбәр дә.
Җилдән җитез килер идем,
Кул изәсәң әгәр дә.

Кара, кара, кара төннәр!
Бер тутырып карачы,–
Йолдыз булып янар иде
Күзләремнең карасы.

Яна, яна, яна йолдыз! –
Зилзиләләр янаса,
Йөрәкләргә күчәр нуры,
Кучми калмас лабаса.

Мин сине яратмадым.
Мин сине сагынмадым.
Сагышларымны ябынып,
Мин сиңа табынамын.

# СОНЕТЛАР

## 1

Юксыну диган чүлдә мин гүя.
Дымсу күзләре шундый сусаткан –
Соңара күрмим, ашыгып барам
Аның күз яше аккан сукмактан.

Күз яше кипкән. Дөнья бит шундый:
Ярлар ишелә, яра төзәлә...
Мин беләм ләкин, бу сукмак тиздән
Чыгар Ярату дигән үзәнгә.

Һәм йөрәк табар, табар кадерен –
Соңгы сулышта дымсу күзләрдә
Чак кына чагылыр чатнаган ирен.

Беркем дә чыкмас мине эзләргә...
Күз карасында булыр каберем
Карсак яңгырлы кара көзләрдә.

## 2

Дерелдәде бүген иреннәрем,–
Гүя соңгы яфрак каенда,
Сафрак дөнья эзләп, тетри-тетри,
Йолдызларга бакты, аена.

Аһ, тоясы килә кояшларны!
Кош оясы кебек үрелеп,
Күзем чокырларын күккә төбим –
Нинди сурәт анда күренер?

Чиксезлеккә орынасы килә,
Гомернең бар шундый яклары –
Нидер көтә күңел өстән. Белә:

Берни булмас. Шундый чак бары –
Төн бүген дә кош оясын менә
Күк гөмбәзе белән каплады.

### 3

Их, ярлар кала... Алар ярларда
Тал-тирәк төсле яшь түгәрләрме?
Күтәреләм ич күгәлләр белән,
Түбәнәяләр йорт түбәләре.

Ә ярлар кала... Алар ярларда
Тал-тирәк төсле чыгармы каршы?
Төшәрмен ич мин кире бу җиргә,
Кадерле аның һәрбер карышы.

Күп тә кирәкми икән кешегә...
Иртәгә монда кем балык сөзәр?
Кай сылу керер кемнең төшенә?

Һәм күрми узар яңа илгизәр:
Иң соңгы юлда безнең ишегә
Тал-тирәк кенә моңсу кул изәр...

### 4

Борчылма син, борчылма, бераз
Караңгыда ялгызым калдыр.
Нидер миңа әйтергә теләп,
Түбәбезгә түгелә яңгыр.

Киреләнер дә тынар шикелле,
Синең белән янәшә булсак.

Әле менә шыбырдый акрын –
Адымнары сабыйныкы: сак...

Яңгыр рәссам, ә түбә киндер:
Сөйгәненә ашыга кемдер,
Ишетелә сулышы әнә!

Танымадым тамчы да аны.
Шигыремә йомарлыйм җанны –
Үрсәләнә ул, үрсәләнә...

## СИНЕ КӨТКӘНДӘ, ТАНЫШ ТҮГЕЛ КЕШЕ...

### 1.Газап

Йөри идем кичен тын урамда,
беркайчан да язылмаячак шигырь уйлап –
күзем төште зур бер йортның тәрәзенә...
аулак бүлмә...
арлы-бирле кем ул бәргәләнә бүлмә буйлап
берьялгызы...
Иелгән һәм бик карт кебек күренә,
яшь тә кебек, хәер, нигә аның яше?
Шунысы хак: ул кемнедер көтә бу кич,
өстәлендә ике чәшке...
Кемдер аңа тиздән килергә тиеш –
ишек ачылуны көтә, чәшкеләр – бушануны,
ут сүнәргә тели,
туктап калган вакыт бөкерәйгән килеш.
Кемдер аңа тиздән килергә тиеш.
Комачаулама син аңа, самолет гөрелтесе.
Игътибарын алалмассың, йортын дер селкетеп...
...Арлы-бирле бүлмә буйлап йөрим берүзем мин,
беркайчан да килмәячәк кунак көтеп.

## 2. Бәхет

Тиздән берәү, килеп акрын гына,
ишекне шакырга тиеш.
Бер-беребезгә сиздермибез, тик беләбез –
кемдер килеп
ишекне шакырга тиеш!
...Әй бу бәхет пайтәхете!

Без дә икәү түгел, берәү генә,
мин синдә эреп югалганмын, имеш.
...Ишек тоткасына кунды сорауларым:
мәҗбүриме аның бу сәфәре?
Һәм ишекне шакырга тиешме
Ул? Ул –
миңа бер тамчы да охшамаган кеше.

Бер-беребезгә сиздермичә генә
сискәнергә әзерләнәбез...
Шундый халәт тә кирәктер ул кайчак...
Мин тәгаен беләм, һәм, әлбәттә, ул да белә –
беркем дә килеп йөрмәс тә, бәлки,
ләкин тиздән кемдер, килеп әкрен генә,
ишекне шакыячак...

# ЯҢА ЕЛДА БУЙДАК БАШЫНА КИЛГӘН УЙЛАР

Яңа елның кергәненә алты минут...
Мин берүзем чыктым урамыма.
Ялгызлыкка сусап түгел, юк-юк!
Тәмәке тартырга гына...

Өйдә бәйрәм. Исерек тостлар. Бушлык.
Мәнсезлекнең биек ноктасында
Ыгы-зыгы килә галәм,
Һәм мин шунда
Сүнгән планетадай.

Яңа елның яңа кары төшә,
Каралмаган, нәкъ былтыргы төсле,
Әз генә дә үзгәрмәгән дөнья,
Былтыргыча бөтенесе, бөтенесе.

Бер мин генә монда – тын урамда.
Күк йөзендә көлә ялгызак ай.
Ә кешелек бер хис белән мәшгуль,
Һәм ул хисне
«Шатлык» диеп атаганнар бугай.

Тукта, дөнья! Көлүеңме әллә?
Сул ягымда нидер куйды әрнеп...
...Узып китте сары шәлле кара шәүлә,
Янәшәмнән бүрек кадәр эт ияртеп.

Тәрәзләрдә утлар тонык-тонык,
Оныт, җаным, бар уйларны оныт.
Кабынырсың, бәлки, бер караштан?
Яңа елга кергәнемә сигез минут.

## ТИМӘ

Ишелеп төшкән җиргә болыт,
Дөнья күзен яшергән...
Миңа читен. Мин бит... мин бит...
Коела учка яшеннәр.
Мин бит күзләргә төбәлеп
Шатланырга өйрәнгән!
Ә монда шомлы, караңгы,
Һәм җил бии тирәмдә.
...Сез мине аңламыйсыздыр...
Минем үземнең күгем.
Дөнья иренә кычкырган
Хатынга охшый бүген.
Холыксыз. Күзен томалап
Ишелеп төшкән чәче.
Кычкыра кызмача иргә:
«Күземә күренмәче!»
Иргә кыен. Дәшми тора.
Кая мескенгә кадер?
Аның да, бәлки, елга бер
Тугарыласы киләдер...
Күңелендә тырнак эзе.
Маңгаеннан тир тама.
Ханым!
Зинһар өчен, ханым,
Сабыр ит, тимә аңа.

# ГАЙБӘТЧЕЛӘРГӘ

Колагыгыз суырып ала мине,
Кире чыгам авызыгыз аша.
Күнегә алмый моңа кайберәүләр,
Кайберәүләр... яраклаша.

Шаккатасың хыял куәтенә:
Шундый үзгәртәсез – дегет ялмый.
Ничек кеше танысын ди мине,
Мин үземне үзем таный алмыйм.

Яшәвемә төшенәм. Күңел ачык.
Күз алдында телләр ята тәтәп.
Гомер үтә кешеләргә табынып,
Кешеләрне сагынып гомер үтә...

Сөлге белән булмый ич томалап,
Сөйләгез соң әйдә, бигайбә!
Сездә ничек, белмим.
Ә шигырьдә
Рифмалашмый «гайбәт» белән
«әйбәт».

# ТУЙ

Күпергән ак болыт җилферди күктә
Авызын җәеп кояш елмая күктә
Бөтенесен дә күрәбез һәм сөенәбез
Ләкин күрмибез дә һәм сөенәбез.

Ап-ак туй күлмәге җилферди җилдә
Авызын җәеп язмыш елмая җирдә
Бөтенесен дә күрәбез һәм сөенәбез
Ләкин күрмибез дә һәм сөенәбез

Кияү белән кәләш өчәү төшәләр сурәткә
Без кешеләр шул – күрәбез
уйлыйбыз
һәм сөйлибез

* * *

Булмәмә ул керде тын гына...
Мәхәббәтнең серле зынҗырлары
Көлке иде, ят иде рухыма.

...Иртә белән ул китте
Хәлсезләнеп, талып.
Мендәремдә хушбуй исе калды.
Муеныма
Чәч бөртеге калды уралып.

# ХӘРЧӘҮНӘ

Өйрәндек без күңел ачарга...
Шәраб, кызлар һәм музыка.
Бииләр.
Мин дә яшәгәнмен –
Яшәү мәгънәсе турында
Уйланганмын, юләр.

Коелсын бар уем минем: музыка!
Ул безнең кыйбла бүген, бу йорт безнең хаҗ!
Челентано – рәсүлебез.
Музыка!
Илһам Шакировка хәтта
Юк монда ихтыяҗ.

Күңелле бер шау-шу, кызлар көлүе.
Кайнап тора касәләрдә эчемлек.
Макташабыз, дуслар!
Ачыны эчсәк тә без,
Никтер ныграк яратабыз
Төчене.

Музыка!
Нинди ымсыну бу хәрәкәттә?
Ни эзлиләр бу күңелләр, бу тәннәр?
Һәм ни уйлап, мине алгысытып,
Стенага каен рәсеме
Төшергәннәр?
Бииләр,
Чәкештерәләр.
Мин дә эчәм исереп, авыртынып...
Кайтып китәсе калган авылга
Күптән.
Ташлап бавырны... безгә
Бәгыре дә җиткән.

* * *

Итәгеңнең җиле иренемә кунды.
Кем куа?
Тротуар йөгерә безгә таба.
Ут каба олтанга.
Вакыт
Утка табынырга.
Кызыл будка –
Кызыл ялкын!
Салкын кара көпшә...
Тукта,
кирәк түгел,
Зинһар,
«а-ш-ы-г-ы-ч
ярдәм»
машинасын
чакыр.

## ҖАЙДАГАТ

Бу төндә без икәү – җайдагат! –
Телгәли күк йөзен камчылар.
Без арып егылгач, бүтәннәр
Сөңгене күтәреп яу чыгар.

Түшәмнәр түшәлә юлларга –
Тагын кем безнең күк очалган?
Тик сынды сөңгебез, сөрәнләп
Егылдым упкынга мин чалкан.

Табигый бу яуның ахыры, –
Белгәннәр бер елар, бер көләр.
Йә, дисең, ничек соң?
Ни диим? –
Татарлар елмаеп үлделәр!

## ТӘШВИШ

Өстәлгә бер алма куйгансың,–
офыкка ташланган кояш шикелле
чарасыз елмайды.
Бусагадан кашагага кадәр
ашыгып шәрә нур түгелде.

Көндезге гамь, ыгы-зыгы тәмам.
Күңелләр дә, борыннар да йомшады.
Сискәндереп әмма идәндәге
күлмәгеңме кыштырдады?
Әллә
алма эчендәге корт кымшанды.

* * *

Мин янам,
        шатланам,
                газапланам,
гаҗәп түгел – дөнья бу!
Карап тора миңа күзләр –
йөзләрендә тук елмаю.

Мин сөям,
        җыр язам,
                хәсрәтләнәм,
шуңа күрә дөнья бу...
Нинди тезләр, нинди эзләр! –
Ә йөзләрдә – тук елмаю.
Бу дөньяга теләп килдем.
Бу – теләп алган яну.
Тик җирәнсәм кемнәрдәндер,
кичерегез.–
Йөзләрендә тук елмаю.

# ҮТЕНЕЧ

1

Мин бит сине эзләдем, ди...
Таптым... Кулны изәдем, ди...
Сизмәдем мин, сизмәдем.

Сүрелделәр күзләрем, ди...
Сүрәнләнде йөзләрем, ди...
Сизмәдем мин, сизмәдем.

Йорт тирәндә эзләрем, ди...
Бусагаңда тезләндем, ди...
Сизмәдем мин, сизмәдем...

2

Ул төнне йолдыз атылган,
Дөнья бер мәлгә яктырган.
Сизмәдем мин, сизмәдем.

Сатканнар, кемдер сатылган,
Атканнар, кемдер атылган...
Сизмәдем мин, сизмәдем.

3

Һәркемнең үз гаме җирдә,
Миңа ник аны белергә? –
Кызганмыйм ич, кызганмыйм!

Бу безнең кыска гомердә,
Бәлки, бары тик шигырьдә,
Мин дә берьялгызланыйм...

4

Ишетми һәм күрми генә,
Бикләнеп үз җәсәдемә,
Сызланыйм мин, сызланыйм?

# ӘЯ

Синнән китәм инде, күрешмәбез бүтән,
Кырны айкап алган аҗагандай үтәм.
Агымсуга сусап таллар сыгылганда,
Корбанына төбәп бөркет егылганда,

Әя!

Китәм инде синнән, күрешмәбез янә,
Күзме элпәләнә, кырмы төтенләнә?
Аратаны ватып үгез үкергәндә,
Су өстендә сыңар балык сикергәндә,

Әя!

Инде китәм синнән, күрешмәбез башка,
Мин табармын ышык кабат кузгалмаска.
Аяк асларында чия изелгәндә,
Чишмәләрнең тыны кинәт өзелгәндә,

Әя!

Инде китәм синнән, күрешмәбез тагын,
Сүнгән учак кала, туздырылган табын.
Тожым очкан чакта камылларга тиеп,
Канат салындырып, башны түбән иеп,

Әя!

* * *

...Төн караңгысы иңгән аулак бүлмә, төн ага
чәчем арасыннан! Өстәлдәге кибеп беткән
чәчәк хуш исен җуймаган әле, җуймаган –
нәрсәнедер хәтерләтә һаман...
...Түрдә мәхәббәт сүрәсе язылган шәмаил...
Ә шулай да мин берүзем түгел монда –
тәрәзәдән ыжгырып җил керә (син утырып киткән
кара поезд сыман куркыныч ул). Һәм тимер
юл кебек озын гомер янәшәдә.
Төн ага чәчем арасыннан!
...түрдә хушлашу сүрәсе язылган шәмаил...

* * *

Мин томанга төренгәндә,
Арттан и йөгерер,–
«Ташлама!» дип пышылдашып, –
Шәраб, кызлар, шигырь.

Мин томанга төренгәндә,
Тәндә нидер сызлар...
Искә төшәр ирексездән
Шигырь, шәраб, кызлар.

Мин томанга төренгәндә,
Кемдер калыр әрләп...
Гомер әрәм түгел – әрәм
Кызлар, шигырь, шәраб.

## БУ ДӨНЬЯДА

Үрелде кошчык куакка, өметләнеп,
Читкә тайпылды яфрак, үптермәде.
Эндәшмәде кошчык, бу дөньяда –
кин дөньяда
Аңа дигән иреннәр дә күптер әле.

Җиң сызганып, тиң эзләдек без дә...
Ул хыяллар, ул нәзакәт җырлардагы!
Килгән идек бу дөньяга –
кин дөньяга –
Үләннәрнең йөткерүен тыңларгамы...

* * *

### (Зөфаф киче)

Дарумы бу? Әллә агумы соң?
Дөнья нәрсә сузды, йа Раббы?
Манарамның тамырына төште
Яшәешнең ачы шәрабы.

Тагын бер кат аска егылдым мин,
Шул ук мәгарә бу... Караңгы.
Манарамның очына ук менде
Яшәешнең татлы шәрабы.

* * *

Изрәп йоклый төз чыршылар,
Каеннарда алтынсу төс –
Көзме соң бу? Көз.
Һәм тагын көз килгән –
Көз чагыла миләшләрнең
Җемелдәвеннән.
Дөрестән дә көзме соң бу?
Көзме?
Нарасый өзгән алмада
Яна ике теш эзе.
Безме соң бу, безме?..

# ХАН ЧАТЫРЫ

Авыл өе. Нарат исе.
Ә ул чоланда иде,
керфекләре сәмави бер
нурга чыланган иде.

Чәчләре ишелде laslап
мендәргә, мендәр ап-ак!
Китче, кит, дип, кайнар сулап
нинди кыланган иде.

Чалбарымда адаштым мин:
хан чатыры гүяки,
мине шуннан азат итеп
ул бер куанган иде.

Дымга ымсынган гөл тажы –
сүземне ачтым менә,
тик ул пәри кызы сыман
күздән югалган иде.

Тәрәзәдән карадым мин –
тыштагы буш далада
офыкка таба йөгергән
ап-ак кылганнар иде.

Йөрәк тибешедәй аксап
дөньяга чыктым, белдем:
бу сагыш инде онтылган
ерак еллардан иде.

* * *

Назлы сүзләрне тыңларга
Күңелең уянган булыр,
Буш өметләр кебек ләкин
Иренем янган булыр.

Серле төшләреңне өзеп
Кинәт кысылса учың,
Язмыш аңа котмәгәндә
Йөзеген салган булыр.

Йөгерәсең килер синең
Офыкта яланаяк,
Үзәннәрдә яшел үлән
Ләмгә буялган булыр.

Итәкләреңне күтәреп
Суларга төшсәң әгәр,
Яр өстендә ак яулыгың
Онытылып калган булыр.

Күзеңдәге ишарәне
Йөземә бөрке әле, –
Мин барыбер торалмамын,
Тезләрем талган булыр.

Күз карашларымны эзләп
Хөҗрәмә килсәң дә син,
Табалмассың, инде аны
Көн сөртеп алган булыр.

Тик иреннәрем селкенер
Хушлашу сүрәсеннән...
Соңра ни генә әйтсәм дә,
Сүзләрем ялган булыр.

# IV БҮЛЕК



*Кичкә таба давыл чыкты, күктә яшен уйнады, яңгыр камчылары шашынып җирне кыйнады. Якын-тирәдә бер ышыкланыр төш тә булмаганга, мин, яшеннәргә уралып, абына-сөртенә гел алга бардым.*

*Үземнең инде кем булуымны, кайда баруымны, нишләп бу җирләрдә йөрүемне дә аңламаслык хәлгә килгән идем, тәмам эштән чыгып җиргә авам дигәндә, бер таш диварга килеп төртелдем. Сыдырылган, кан саркып торган кулларым белән шул салкын диварга тотынып, капшана-капшана ишек эзли башладым. Ниһаять, ниндидер аждаһа итеп коелган тимер тоткага килеп орындым.*

*Тимергә тимер бәрелгән тавышны ишеткәч, өстә кемнәрдер шыбырдашып йөгерә башлады.*

*– Мин – бичара юлчы...– дип ыңгыраштым.*

*Капкадан ниндидер тимер киемле кешеләр чыгып, мине эчкә өстерәп керттеләр.*

*Җылы өйдә аңыма килдем.*

*– Баллап, кайнаган сөт эчерегез,– диде бер калын, тупас тавыш.*

*– Тыңлыйм, морзам,– дип, кемдер аңа җавап бирде.*

*Бер атнадан мин аякка бастым. Монда ниндидер сәер, кырыс кешеләр кала диварларын ныгытып яталар иде. Мине таш ташырга куйдылар.*

*Без көне буе диварга таш өябез, ә иртән ул нәкъ элеккеге биеклектә була... Шулай да миңа монда ошады. Ташчылар аз сөйләшә, сорау биреп интектерүче юк, җилкәгә таш салып, үз эчеңә бикләнеп йөрисең дә йөрисең... Дөресен әйткәндә, каядыр барып мәгарә эзлисе дә килми башлады. Мин ул мәгарә турында оныттым да, ахрысы... Көн артыннан көн уза, һәм гаҗәп – син аны сизмисең дә. Бу каланы Вакыт бөтенләй читләтеп уза иде бугай.*

*Беркөнне мин нәрсәгәдер абынып егылдым, иңемдәге авыр таш тәгәрәп китте. Әллә дәрманым беткән, әллә болай тиз генә торасы итмәдем – озак кына яткач, урам ташының уемтыгында җыелып торган суга күзем төште. Калада көзге бөтенләй юк, шуңа минем үз кыяфәтемне күптән күргәнем юк иде. Мин суга*

*карадым, ә аннан миңа чал сакаллы, җиту чәчле бер карт карап тора! Һәм ул карт – мин идем, ахрысы.*

*Урам уртасында язмышым ташы аунап калды, мин, чайкала-чайкала атлап, кала капкасына таба киттем. Сәер хәл – беркем дә туктатмады! Гүя мин юк, мине беркем күрми, алар барысы да үз мәшәкате белән мәшгуль. Таш ташыйлар, диварны ныгыталар... Мин шул чакта гына зәгыйфь күзләрем белән шәйләп алдым: бу каланы дошман инде күптән алган икән ич – Зур Манарада алар байрагы җилферди! Ул бик өстә, дивар ныгытучылар аны күрми, аларның каерылып күккә карарга вакытлары юк...*

## БЕЗНЕҢ ИЛДӘ

Безнең илдә, ахры, җил дә, су да бүтән,
Таң башкача ата – ятлар танырлар.
Гүя очын дошман эзләп тапмасын дип,
Чәбәләнеп беткән безнең тамырлар.

Безнең илдә, ахры, җил дә, су да бүтән:
Челтерәгән көмеш чишмә суларын
Мин бер читтә, тыйнак җикән–камыш булып,
Итәк җилен сулаган күк суладым!

Безнең илдә, ахры, җил дә, су да бүтән,
Офыгында көннәр, төннәр бутала.
Йолдызларга карап кемдер чукынганда,
Сарылабыз янә алабутага.

Безнең илдә, ахры, җил дә, су да үзгә,
Йөрәкләргә сагыш сызган ызанын:
И язмыш-кыз! Сөрмә итеп тарттың мәллә
Татарстан юлларының тузанын?

Безнең илдә, ахры, җил дә, су да үзгә,
Үләннәргә тияр-тимәс үтәбез...
Өлгермибез язны каршы алырга да,
Урыс кышын вәгъдә итеп көтә көз.

# КАРУРМАН

Без адаштык бугай карурманда,
Урманның да насыйп безгә карасы.
Кайсы кошның авазына иярик соң,
Татар иле?! –
Идел-Урал арасы.

Чәнечкеле чыбыкларны араладык –
Кайсы якка таба юллар ярасы?
Без бит, ахры, кыйблабызны югалтканбыз,
Татар иле?! –
Идел-Урал арасы.

Батырларның каберләрен карлар күмә,
Алар артта онытылып каласы...
Сине кемнәр йөрәгендә алып чыгар,
Татар иле?! –
Идел-Урал арасы.

Туган телен кем теләнеп сорап йөри?
Маңгайларда безнең кемнәр яласы?
Кыршау булып кыса җанны чик сызыгы,
Татар иле...–
Идел-Урал арасы.

Әй кара да гына урман, караңгы төн!
Затлы атлар кайдан эзләп табасы?
Сүнеп ята йонлач йолдызлар астында
Татар иле –
Идел-Урал арасы.

Карурманда адашкан бу улларыңа
Синең белән кая кадәр барасы?
...Йөзебезне туфрагыңа яшерербез,
Татар иле –
Йөрәгемнең ярасы.

# ТҮРКЛӘР

Да, скифы мы.
*А.Блок*

Төрkләр без! –
Кысан бу дөньяга
Тудырган да безне Ашина,
Җилдергәнбез җитез тулпарларда
Җилләр, зилзиләләр каршына.

Төркләр без! –
Күзебез дә хәтта
Ук төзәргә диеп уелган.
Офыкларда югалабыз, чыгып
Тормыш дигән затсыз уеннан.

Төркләр без! –
Дөм караңгы төндә
Дала бүресенең юлдашы.
Таш диварлар кыса хәзер җанны,
Ерагая Күлтәгин ташы.

Төркләр без! –
Хәтер корбаннары.
Күзне йомып тып-тын тор гына,
Йөз меңнәрчә кылыч күтәрелә,
Һәм төмәннәр яуга ыргыла.

Төркләр без! –
Аларның да әле
Иң чыдамы икән ләбаса! –
Татар атын авыр аркан белән
Өстерибез гасырлар аша.

Төркләр без! –
Кеше арбасында...
Кулдан төште күптән дилбегә.
Сиздермичә әрнеп күз ташлыйбыз
Дөнья дигән атның биленә.

Төркләр без! –
Урман җәяүлесе
Адымнарын тыеп атласын! –
Арган җайдак камчы сабы белән
Кага яңа гасыр капкасын.

## ЛАШМАНЧЫЛАР

Ай-һай Себер таулары,
өзелә камыт баулары;
Камыт бавын бәйли-бәйли
сызыла йөрәк майлары.

*Лашманчылар бәете*

Бии балта имәннәрнең тәнендә,
Әллә агач, әллә бәгырь киселә...
Беләкләрдә куәт ташый, тик менә –
Карурман зур – алда гомер, түз генә.

Бу ыругта каян мондый рух, диеп
Гаҗәпләнә җәллад коллар көченә.
...Ава имән, ава ирләр ачынып,
Агачлар да, бәгырьләр дә киселә.

Кара урман, юллар ябык – кайту юк,
Богау түгел, камыт бавы өзелә.
...Лашманчының ал канына манчылган
Мәгърур кораб йөзеп йөри диңгездә.

Буран дулый карурманда шашынып,
Бүре улый, бүре шундый якында.
Ялгыз учак... ут суыра җаннарны,
Һәм кар төшә каберләргә сак кына.

# СЕЗНЕКЕМЕ?

Нәрсә җитми? Ник сулкылдый күңел?
Үкчәсенә баса-баса моңның,
Берьялгызым менә төннәр буе
Урамында йөрим авылымның.
Үткән давылларны төштә күреп,
Өянкеләр йоклый – дөнья тынган.
Йөрәгемне өтә кайнар сулыш,
Бәреп чыгып туфрак арасыннан.

Йөрәгемне өтә кайнар аваз –
Кем пышылдый миңа?
Кемнең өне?
Астан килә, астан ургый сорау:
«Безнең дәваммы син, безнекеме?»

Бабаларым!
Шул ук җегәр миндә,
Шул ук иман яши йөрәгемдә!
...Ә кемнәрдер әнә таптап үтә
Сезнең сөякләрне гамьсез генә...

Мин дә туңам – сез өшисез икән,
Сезгә эссе икән – мин дә янам!
«...Саумысез!» – дип дәшәм туган телдә,
Туган телдә – димәк, сезнең дәвам.

Иманым нык, шул ук сезнең иман!
Таңнарыма чыгам, кичеп төнне.
...Нигә һаман тыныч түгел күңел:
Сезнең дәваммы мин, сезнекеме?

* * *

Карап торам бүген Казаныма
Сөембикә манарасыннан...
Үткәннәрем белән мин үзем дә
Легендага кереп барам сыман.

Дастаннарны барлый-барлый менә
Легендага кереп барам сыман!
Хыялларым кебек ап-ак җилкән
Сәлам юллый Вакыт дәрьясыннан.

Ә Казанда яз патшалык итә,
Җиңә алмас кебек аны берни...
Ямь-яшел ут чолгап алган җирне,
Яшел ялкын ярсып күккә үрли.

Язгы шатлык күңелемдә минем!
Язгы шатлык тамырымда ага!
Чәчәк исен алып килә җилләр,–
Илаһилык иңә манарага.

...Карап торам.
Казан, Кояш һәм Яз.
Яшел ялкын ярсып уйный илдә,
Минем бүген шушы манарадан:
– Бәхет! – диеп кычкырасым килә.

Әмма җилләр гайрәтләнә һаман,–
Өзгәләрләр кебек шушы өнне.
Еракларда ялгыз моңсу җилкән
Офыкларга сеңеп бара инде.

# БИСМИЛЛА

> КамАЗ белән бары намаз гына
> Рифмалашмый калган заманда...
>
> *С. Хәким*
>
> Чаллыда яңа мәчет манарасын күтәрү тантанасы булды.
>
> *Газеталардан*

Мөфти хәзрәт белән утырабыз.
Дин әһеле оста гәп сата.
Без икебез ике якта, дөрес...
Өстәл генә уртак максатта.

Динне әфьюн диеп тукыдылар
Бала чакта минем башка да...
Күңелеңдә синең – партия, дип,
Һәм урын юк аннан башкага.

Тел турында сөйли мөфти хәзрәт,
Ә үзе бит туган Казанда.
Иман белән хәтта Иван исеме
Рифмалаша язган заманда.

Бу илдәге барлык-барлык телләр
Кушылырга тиеш булса да,
Мөмкин түгел рухы исәннәрне
Куып керт үкысан кысага.

– Бисмилла! – дип сүзен башлый хәзрәт...
Әллә нинди якын, изге сүз...
Кылыч кебек чиста сакланган ул,
Чиста калмасак та үзебез.

Нинди генә зилзиләләр узмый,
Нинди генә җилләр исми лә...
Манаралар киселә... Исән кала,–
Колакларда чыңлый бисмилла.

– Бисмилла! – дим мин дә. Кемдер яңа
Зилзиләләр белән янаса,–
Динне әфьюн диючеләр бүген
Әфьюнне дин иткән ләбаса!

Ә без? Ә без? Без – имансыз түгел,
Ул – күз яшьтә, аккан каннарда...
Алар җирдә ятмый! – Сөңге булып
Кабат калкып чыга манара.

## ПИРАМИДА

Ханнар дәвер сөргән Казанда!
Аргамакка менеп атланган,
Кайчагында яуга кузгалган,
Кайчагында илне яклаган.

Ханнар дәвер сөргән Казанда.
Сарай кырындагы биш төрбә...
Эзе Олуг Мөхәммәдләрне,
Татар данын искә төшерә.

Ханнар дәвер сөргән Казанда.
Ә төрбәләр булган бары биш.
Ташлары да калмаган инде,
Кая дога кылыйм мин – дәрвиш?

Ханнар дәвер сөргән Казанда.
Хәзер бүтән җырлар, бүтән аһ...
Яңа пирамида төбендә
Күрәм: хәер көтә бер әрвах.

# ЧАҢ

Чаң суга Казан өстендә,
Нинди хәбәр анда?
Ни бар? –
Чүгеп китә ыңгырашып
Зәңгәр эңгер сеңгән дивар.

Чаң суга җанга шом өстәп,
Чакырамы, озатамы?
Әллә бәгырьгә батырган
Иске хисне кузгатамы?

Күзгә керә тутык аваз:
Даң да доң килә, даң да доң...
...Телне тешләп ята идең,
Көн килде, чаң, син ярадың.

Чаң суга яңгыр астында.
Яңгырый һаман – сагынган...
Даң да доң иңри ул – иске...
Яңалар тарта бавыннан.

Чәчрәп китә юеш яшен,
Чаң суга өстә, күр аны!
Дәшә кара болытларны
Куерган тәре урманы.

Чиркәнеп чиркәү каршында
Туктадым.
Тагын сукты чаң! –
Ыңгырашып чүгеп куй бер
Син дә, әгәр татар булсаң...

## ХӘТЕР

Мин үземә-үзем яра сыман!
Гасырларны учка кыстым ярсып!
Кан саркыды бармак арасыннан.
Сибелеп япты ап-ак сөякләрем.

Үтте чорлар. Бу җирләргә килгән
Акыллылар мөһер сукты:
Затлы!
Җелегемне суырды
Сабын заводлары.

Яңгыр яуды...
Акты толым-толым...
Сабын булып юдым
Дошманымның
Минем канга буялган кулын.

Онытылды.
Онытылдык!
Бер уйласаң,
Кемгә кирәк хәзер ямьсез чынлык?
Гасырларны учка кыстым бүген –
Мизгел калды, тынды тыпырчынып.

# УТЛЫ КӨПЧӘК

*(Триптих)*

1

## Күлтәгин ташы

Түрк кара камыг будун анча тимис
Иллиг будун әртим
Илим әмти каны
кәмгә илиг казганурмән
каганлыг будун әртим
каганым каны
нә каганка ишиг күчиг бирүрмән
*Орхон буенда Күлтәгин истәлегенә*
*куелган зур таш. VIII гасыр*

Ягъни:

Түрк халкы болай диде:
Илле халык идем,
Илем инде кайда?
Кем иле өчен казганырмын?
Каганлы халык идем,
Каганым кайда?
Нә каганга эшем-көчем бирермен?

Мин – Күлтәгин ташы!
Ашыгыгыз, ашык...
Түрк халкы бүген
Җирдә артык кашык.
Бер ягымда – Мәгърип,
Бер ягымда – Мәшрикъ.
Алган яраларны
Килмешәктән яшерик.
Тубыктан ук индем,
Иңбашымда – Тәңре...
И минем таш күңел! –
Әрне, әрне, әрне...

Килде алар менә –
Яңа җиһангирләр –
Иксез-чиксез илгә
Сыялмаган ирләр.
Маңгайларда йолдыз,
Кулда автоматлар.
Үткәннәргә төбәп
Атып ята ятлар!

Агач башларында
Алар йөгергәндә,
Чорлар тарттырдыгыз
Олуг тегермәндә.
Бер ягымда – Мәгърип,
Бер ягымда – Мәшрикъ.
Язмышнымы каргыйк?
Заманнымы әрлик?

Автоматлар ата,
Ата тугарылып,
Кыйпылчыклар оча,
Тәннән кубарылып.
Үткәннәргә ату
Илбасарга кулай –
Киләчәкне безнең
Үтерә ул шулай.

И син, шагыйрь җаны! –
Фәхишәдәй чишен...
Мин – Күлтәгин ташы –
Солдатларга мишень.
Капла канат белән,
Фәрештәкәй, ая!
Илле иде халкым,
Кайда ул ил, кая?..

Тояк эзен күмгән
Җилләр шундый чая.
Ханлы иде халкым,
Кайда ханнар, кая?..
Бер ягымда – Мәгърип,
Бер ягымда – Мәшрикъ.
Кол булганчы Җирдә,
Комнар булып яшик.

Мин – Күлтәгин ташы!
Мине куйган будун,
Син кайда соң булдың?
Буыннарны җуйдың.
Иңдем тубыктан ук –
Иңдә мәҗрух Тәңре...

Төннәр буе иңри –
Җуелгандыр кадере...
Мин – Күлтәгин ташы...
Мине куйган халык
Алып кебек йоклый,
Чабатасын салып.

Чапты, чапты атлар.
Тартты Мәгърип, тартты.
Тояк эзе саен
Калкулыклар артты.
Малмы алга куды,
Алга куды данмы?
Әллә дан да, мал да
Канга буялганмы?

Мин үзәктә торам,
Мин – таш кына бары.
И бу ике якның
Якалашулары...

Ә офыклар һаман
Аллы-гөлле, аллы...
Туган төякләрдә
Ташлар гына калды.

Мин – Күлтәгин ташы!
Кайда, кайда илем?
Каганнарның сезгә
Сүзен алып килдем.
Беркем дә юк илдә,
Алда – автоматлар.
Васыятьләргә төбәп
Ата, ата ятлар.

Нигә ятлар булсын? –
Кем охшата ятка? –
Атиллалар* үткән
Юлдан кире кайта
Шул ук кавем. Эзен
Күз яшьләре юа.
Малмы артка куа,
Данмы артка куа?

Шул ук заттан юкса,
Сукса юк итәрлек...
Тик исемнәр бүтән,
Тик җисемнәр бүтән...
Кем каганы өчен
Җәзалана алар? –
Кем казаны өчен
Казганалар алар?

Тыныч йокла, Билгә*!
Син – Алып Ир Тоңа*!
Күкрәп үтте яшьлек,
Җете төс тиз уңа.

Мин – Күлтәгин ташы!
Истәмиләр* – истә!
Сөңге йөрткән халык –
Дары исе иснә.

Кыйпылчыклар оча
Кубарылып миннән.
Беркайчан да бүтән
Каршыгызга килмәм.
Иңәм, яраларны
Үзем белән яшереп...
Бер ягымда – Мәгърип,
Бер ягымда – Мәшрикъ.

2

## Кабан

Кабан суы хәмер булып,
Куктән пилмән яусайде...
*Урам җыры*

Хастаханә кирәк миңа бүген! –
Бөеремә ташмы бөялгән? –
Җыерылам да әрнү-газаплардан,
Ярларыма килеп сөялә м.
Дүрт гасырдан артык сер саклыйм мин...
Ләм каплаган алтын әрҗәдә
Бәргәләнә әҗәл. Әрсезләргә
Вәгъдә итә байлык-дәрәҗә.

Хан ташлаган асылташлар минем
Бәгыремдә мәллә,
ник әрни?

*Борынгы төркиләрнең каганнары, хәрби җитәкчеләре.

Аh, ташыйсы килә дөнья буйлап,
Ләкин ярлар, ярлар җибәрми.

Мин Казанның йөзек кашы идем –
Сылу кызлар миңа табынды.
Кич җитүгә минем өсләремдә
Берәм-берәм айлар кабынды.
Күпме мәхәббәтнең шаhиты мин!
Мәхәббәтнең шаhы Таhир да
Татымаган сагыш яши аста –
Сандык булып калкыр ахырда...

Бүген менә көчли мине ярлар,
Карышырга юк бер чара да...
Карынымда, сезне юк итәргә,
Яңа илбасарлар ярала.
Ә сез – йолкыш! Махмыр йокысында,
Кузгаталмас оран, әмер дә...
Төшегездә күктән пилмән ява,
Әверелә суым хәмергә.

Күпме җаннар, маллар озатылды.
Кем санаган алар күләмен?
Коллык өчен хәзер күлне түлә! –
Мин әҗәлем белән түләрмен.
Тешләремне кысып кысылдым мин –
Казналыктан саркый кызыл кан.
Төшегез, төш төпкә...
Сез генәме
Казан казнасына кызыккан.

Тамырымнан агу ага минем.
Өстә томан... Хәтер саега...
Тик тирәкләр генә кул болгыйлар
Сөембикә киткән каекка.
Юк, килмәгез, килмә минем янга! –
Авызы исле гүзәл гүя мин,

Тартылсам да үзем,
ярларымның
Тартылуын миңа теләмим.
Бу Казанның йөзек кашы идем –
Горурлыгы идем, мин – Кабан!
Үткәннәрдә күзем. Ләкин кем соң
Киләчәген анда табалган?

Асыл ирләр бау ишәләр комнан.
Асарлар да мине күкләргә,
Сулкылдармын бер риваять булып...
Көлке тоелыр ул да күпләргә.

3

## Дәүләт музее

Пожар микән, таң микән?
*Х.Туфан*

Яна, яна бина,
Ут яктысы
Айкап алды күңел-мәгарәне...
Үләннәрне сытып, утлы көпчәк
Гомер үзәненнән тәгәрәде.
Җиңелүнең бәхет икәненә
Инандырган иде хөкемдарлар,
Гөлт итте дә кабынды бу ялкын –
Юл читендә – дарлар, дарлар, дарлар...

Подвалларда иске кульязмалар,
Көя тигән чуклы киемнәргә...
Сынык сөңге ята, ярык калкан –
Безнең тарих шулдыр – сөен әйдә!
Яна, яна бина.
Ут яктысы
Өстенрәк ул имеш-мимешләрдән –

Кул сузымы гына күренәләр
Казан бүрке,
Алтын-көмеш, мәрҗән...
Дәү чиркәүнең нигезендә калган
Кабер ташы кебек кысылам да
Казаныма карыйм...
Күләгәләр
Әле төссез, әле кызыл анда.

Яна, яна бина...
Ялкын теле
Өтә йолдыз таккан кительләрне.
Ялмап кына ала!
Сүндерергә
Җитмәс хәтта суы Иделләрнең...

Канашевич пожарлары истә,
Истә – Ильминский тибәргәне...
Герострат дип беркем сүгә алмас
Утка каршы утлар җибәргәнне.
Әрсезләнеп түргә үрелә ут,
Татар музееның түренә үк...
Әби падишаның күт җылысын
Хәтерләгән затлы карета көк...
Яна, яна бина. Ут яктысы
Айкап алды күңел-мәгарәне...
Чүп-чарларны өтеп, утлы көпчәк
Казан үзәгеннән тәгәрәде.

# ӘХМӘД ИБНЕ ФАДЛАН

Идел-йортта таң аткан,
Кәрван килгән Багдадтан.
Әхмәд ибне Фадлан
Төшкән акбүз аттан.

Бисмилла, әй, бисмилла!
Догаларыңны юлла.
Әхмәд ибне Фадлан! –
Илем белән шатлан.

Чатырында ялгызы,
Күргән аны хан кызы.
Әхмәд ибне Фадлан! –
Мәхәббәттән саклан.

Кара кыйгач кашлары,–
Әйләнгәндер башлары:
Әхмәд ибне Фадлан
Аңа караш аткан.

Тик кем белгән ханнарны,
Үзенә тиң санармы? –
Әхмәд ибне Фадлан
Сагышланып яткан.

Ай калыккан Болгарда,
Кәрван чыккан юлларга.
Әхмәд ибне Фадлан...–
Күздән яше аккан.

# XVIII ГАСЫР. ПЕТЕРБУРГ ЗИНДАНЫНДА ЯТКАН ТЕЛСЕЗ БАТЫРШАНЫҢ* СОҢГЫ ДОГАСЫ

Алла!
Ничек болай булды соң әле бу?
Зәгыйфь идемени безнең оран?
Ялгыштыкмы? Аһ, бу газап...
Юатмасмы диеп,
Ничә төннәр җыр чакырам,
җыр чакырам.

Алла!
Йолкып алды дошман телебезне,
Дога укып булмый хәзер мәкам белән.
Ярый әле пар күзләрем исән-имин –
Яшәешнең асылын күрә беләм.

Алла!
Телем җирдә ауный, авызда кан,
Яңгыр юа даладагы кайнар эзне,
Батып барган кояш яна бәбәгемдә,
Ә саташкан кулым һаман кылыч эзли.

Алла!
Һай сусадым, бик җырлыйсым килә,
Елый-елый бер кычкырып җырлар идем
туган телдә.
Үзем үлгәч, әгәр исән булса,
Җырым очып кайтыр иде туган илгә.
Әгәр илем исән булса...

---

* Батырша – XVIII гасырда илбасарларга каршы күтәрелгән татар-башкортларның җитәкчесе (1756 ел).

# КАЛӘМ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Бу мәдхия сиңа, сиңа, Каләм! –
Алачыктан, мескен чатырдан,
Батыршаның сүзен оран итеп,
Безне азатлыкка чакырган.

Бу мәдхия сиңа, сиңа, Каләм! –
Иң караңгы карсак төндә дә
Тукай кулында син бу милләтне
Кабат уянырга өндәгән.

Бу мәдхия сиңа, сиңа, Каләм! –
Каләм генә үзең нибары...
Тоткын Туфан килеп тотынуга,
Чүгеп куйган төрмә дивары.

Аерганнар синнән шагыйрьләрне.
Каерганнар кулны... –
Язмасын!
«Халык дошманы»на әверелеп,
Көткән алар үлем җәзасын.

Бу мәдхия сиңа, сиңа, Каләм! –
Хәтерлимсең, Шамил Усманның
Соңгы тапкыр җан ачысы белән
Учларына сине кысканын?

Нахак белән якалашыр ир-ат!
Телен өзәр, сукмәс тик илне...
«Революция ашый үз улларын»,–
Диеп үлгән Дантон шикелле.

Мыскыл белән көлгән мескен палач,
Бу – сыналган төре җәзаның:
«Мин – шпион, дип кул куй, падла!
Тәмамланыр шунда газабың».

Илле елдан соң да шомланып, мин
Ул көннәргә бүген төбәләм.
Ишетелә Усмановның тавышы:
Кул куярмын!
Тизрәк бир каләм...

Көлемсерәп палач каләм сузган,
Ниһаять, дип, хана батырга.
Каләм – корал.
Алып аны, Шамил
Үз күзенә үзе батырган.

Кичер, Каләм. Син гаепле түгел,
Китәр иде синнән башка да.
Ләкин «бөркет соңгы чиктә үзе
Кыясыннан түбән ташлана».

Сиңа орыну – бөек җаваплылык!
Килдең безгә кара чорлардан.
Соңлап күрдек: син бит Усмановның
Күзе карасына чыланган.

Ә тавышлар һаман тынмый әле:
«Сталинга! Ибтәш Сталин...»
Сискәнеп мин куям бу исемнән,
Идәнгә үк иңә өстәлем.

Каралттылар якты тарихны, дип,
Кемнәр анда бүген үртәлә?
Сөйләп калсын, имеш, тиктормаслар,
Күрсәтербез әле иртәгә...

Бу мәдхия сиңа, сиңа, Каләм! –
Башлагансың юлны, дәвамла.
Нәфрәт белән килә мәхәббәт тә.
Шамил рухы килә гавамга.

Гаепләрбез. Гаепләүләр алда...
Белеп торсын әмма үртәлгән –
Иң зур гаепләү ул бу тарихта
Күз карасы белән теркәлгән.

## ҖӘЛИЛ КОЯШЫ

Кузгалалар эшафотка таба.
Бу – гомернең соңгы «әкбәре».
Сукты сәгать! Һәммәсенең бүген
Легендага күчкән мәлләре.

Палач каршы ала. Элеккечә
Тишек капчык түгел башында.
Юк, башкарып булмый кара эшне
Беркайчан да кояш астында,–
Караңгыга, төрмә төбенәрәк
Ымлый һаман. Көннең яктысы
Бәбәкләрен кисә. Тоткарланса
Исен җуяр адәм актыгы.
«Кеше башы әкияттәге кебек,
Кискән саен кабат үсә лә...»–
Фәлсәфәсе әзер, кереп түнгәч
Фәлән кадәр марка кесәгә.

Кояш кына менә ярсыта бик...
Дивар ышыгына сыенып,
Ул аны да өзеп алыр иде!
Тик
    кояшның
        юк шул
            муены...

# ШАГЫЙРЬЛӘРНЕҢ КАБЕРЛӘРЕН ЭЗЛИМ

Кичерегез, борчып йөрсәм әгәр,–
Шагыйрьләрнең каберләрен эзлим!
Мин туктaлдым әле бу зиратка...
Нәни генә учак тергездем мин.

Тынгысыз җан монда тартты мине –
Каеннары изге, туфрак изге.
Һәйкәлләр дә кирәк түгел хәтта,
Һәрбер кабер өстендә җыр – үзе.

Ә каеннар моңсу – гүя астан
Ап-ак сагыш үзе бәреп чыккан.
Шул моңсулык иңнәремә баса –
Тән талчыккан менә, җан талчыккан.

Җавап көтеп синнән, туган туфрак,
Басып торам чорлар каршысында,
Шагыйрьләрнең каберләрен эзлим,–
Кол Галиләр кайда ята монда?

Орынасым килә каберенә –
Кай тирәдә икән Мөхәммәдъяр?
Соңгы сүзен ишетәсе иде,–
Дөрләп янган безгә дигән хатлар.

Басып торам шушы изге җирдә,
Бер моңсулык иңнәремә баса...
Уйланасы уйлар бик күп әле –
Киләчәккә карап зират аша.

# КОЙРЫКЛЫ ЙОЛДЫЗ

*Поэма*

*(Поэманы башлар алдыннан берничә хатирә)*

*Туфан яшел кара белән яза иде. Туфан турында да яшел кара белән язарга кирәк. Күрәсең, яшел төс аңа һәрвакыт яшьлеген искә төшереп торгандыр, яшәешнең серле гаменә төшенергә ярдәм иткәндер.*

*Яшеллек – яшьлек – яшәеш...*

*Мин дә каләмемне яшел карага манам. Каләмемнән яшел бөреләр чәчри... Алар миңа шагыйрьнең һәрчак яшь, татар күңелендә һәрчак исән икәнен искәртеп тора төсле...*

*Туфанны беренче тапкыр мин театрда күрдем. Ул минем белән күреште дә, башын кырынайтып, күзләрен әз генә кыса төшеп, йөземә карады.*

*Тәнем буйлап меңнәрчә гөрләвекләр йөгереп узгандай булды.*

*Айлар буе янып, үз кыюсызлыгыннан интегеп йөргән мәҗнүн, сөйгәненә тәүге хисләрен белдергәндә, шулай дулкынланадыр...*

*Шагыйрь дә, шигырен язып бетергәч, шулай дулкынлана.*

*Ул кичне мин мәңгелеккә орындым.*

*Туфан кара кәчтүннән, ак күлмәктән иде. Кулында таяк. Шагыйрь таягы. Кайчандыр ул таякны Рәдиф Гаташ шигырьгә дә әйләндергән иде.*

*Ә бәлки, аңа кадәр үк шигырь булгандыр ул?*

*Шулайдыр.*

*Туфан кулы орынган һәрнәрсә – шигырь.*

*Минем җаным буйлап меңнәрчә гөрләвекләр йөгереп үтте.*

*Ул кичне мин дә шигырьгә әверелдем.*

*Туфан хастаханәдә ятканда, без, студентлар, аның хәлен белергә бардык. Янына кертмиләр иде, шулай да, бик үтенеп сорагач, беребезгә керергә рөхсәт иттеләр.*

*Берничә сүз алышканнан соң, икебез дә тынып калдык.*

*Сырхау кеше янында утырганда ничектер үзеңне уңайсыз хис итәсең, гүя таза-сау булуыңнан ояласың шикелле...*

*Туфан, минем боргалануымны тоеп, телгә килде:*

*– Ничек керә алдың соң? – диде.*

*Мин берничә җөмлә белән аңлатып бирдем. Һәм, изге теләкләремне янә кабатлап, китәргә дип кузгалдым.*

*– Сине озата чыгам,– диде ул.*

*Мин җаным-тәнем белән каршы төштем. Йә өзлегеп китәр, Алла сакласын! Әмма ул минем сүзләремә игътибар да итмәде. Коридорда мин аңа тагын кулларымны суздым, әмма ул хушлашырга ашыкмады. «Сине озата төшәм,– диде,– син бит чыгар юлны әлегә белмисең». (Аның палатасы икенче катта иде.) Мин гаҗәпләндем, ләкин олы кешегә каршы килергә базмадым.*

*– Егетләрне күрәсем килә,– диде Туфан.*

*Бары шуннан соң, бөтенебезгә дә рәхмәт әйтеп, тын гына өскә менеп китте.*

*Ап-ак Туфанның өскә менеп баруы һаман да күз алдымда...*

*Туфанның өендә булганым бар иде. Газинур белән Ләбиб бередә беренче кат... Шагыйрь безне өстәл тирәсенә әйләде. Мөнҗия апа куе итеп чәй ясады. Туфан алдында әстерхан чикләвекләре. Кан басымы югары булганга, шуларны ашый икән. Чикләвек өстенә имән бармагын куя да йодрыгы белән шуңа суга...*

*Без сөйләшеп утырабыз. Дөресрәге, ул сөйли. Шигырь турында, Такташ турында, Кутуй турында...*

*Туфан яшьлегенә китте...*

*Без өч яшь егетнең йөзенә егерменче еллар һавасы килеп бәрелде.*

*– Шигырь укыгыз әле, егетләр,– диде шагыйрь бераздан соң.*

*Безнең аңардан фикер ишетәсебез килә иде – укыдык. Әмма Туфан яхшы, дип тә, начар, дип тә бер сүз әйтмәде. Мөгаен, шигырьләр аңа ошамагандыр. Дәшми генә чикләвек вата башлады. Мин, чикләвек буш булып чыга күрмәсен тагын дип, эчтән генә теләк теләдем. Шөкер, бусы да төшле иде.*

*Шагыйрьләрдә нигәдер кан басымы югары була.*

*Туфанга сиксән яшь тулган көннәр...*

*Университетта аның кичәсен оештырдылар. Шагыйрьне алып*

*килергә машина биргәннәр иде. Бер укытучы белән Туфанның өенә киттек. Без барып җиткәндә, ул инде өс киемнәрен кигән, кузгалырга тора иде. Минем кыенсынып кына исәнләшүемә каршы: «Әс-сәлам, Чуаштан!» – диеп, елмаеп сәлам бирде.*

*Барганда, гел университет турында сорашты.*

*Аны урамга ук чыгып каршы алдылар.*

*Зал шыгрым тулы, урыннар җитми – халык аягүрә.*

*Ахырдан Туфан үзе торып басты...*

*Залда – яшьләр.*

*Яшьләр алдында чал чәчле карт. Ул дулкынлана.*

*Менә шагыйрь кулын өскә күтәрде.*

*– Мин әле озак яшәрмен... Мин әле сезнең оныкларыгызның да башларыннан сыйпап үтәрмен...*

*Туфан киткәндә, бер төркем кызлар «Казан кичләре»н җырлап калдылар.*

*Иннә лиләйһи вә иннә иләйһи раҗигун.*

Минем, артык авыр сәгатьләрдә,
нигә бер ярты гасырга соңрак
тумадым икән, дигән чаклар булды.

*Х.Туфан көндәлегеннән*

## Кереш

Июнь.
Казан.
Хастаханә.
Шагыйрь.
Тукта, Вакыт, тукта аз гына –
Калтыранып, сыкрап язып куйыйм
Шигърриятнең елъязмасына
81нең шушы эссе җәен.

Аерыла
хыял
җәсәдтән...

Шигырьләрдә тибә
хәзер
йөрәк.
Кешене
шигырьләре
яшәтә.
Хушлашабыз.
Туфан мәңгелеккә
Дәвам итә үзенең сәфәрен.
Ята...
пәйгамбәрдәй.
Ят ул
данга
Яңгырама! Мескен «афәрин»...

Югалтырга өйрәнгән без.
Яшәгәндер
Элгәре дә бөек кешеләр...
Хәзер тарихыбыз барын
Кайберәүләр
Бик авырлык белән төшенә.
Онытырга өйрәнгән без, дәригъ!
Җир упкан, җил алган, су йоткан.
Минем мием хәтта элеккеге
Зиратларның эзен оныткан.

Июнь.
Казан.
Шагыйрь.
Хастаханә.
Кеше халкы тормый өзелеп.
Алып калмакчыбыз гүя җанга,
Оялып кына, бераз изгелек.

Керәләр дә хәл сорыйлар.
Гадәт.

Ни дисен ул?
– Ярый, түзәрлек...

Исегездә калсын:
Ап-ак шагыйрь!
Ак йөзендә – космик гүзәллек.

Керәләр дә хәл сорыйлар.
Шуннан
Хәбәрләре китә түгелеп.
Чиксезлеккә сәфәр чыккан чакта,
Гайбәтне дә хәтта
Гафу итеп була, билгеле...
Һәм төкәнә сүзләр.
Үзгәреш юк.
Барысы тынып кала берара.
Рәхмәт әйтә шагыйрь.
Рәхмәтедер
Чәчәк алып килгән елларга.

Мин кузгалдым.
Дөресрәге, Хәтер
Киенде дә китте миемнән.
Дөнья киң ул!
Юк иртәгә, бүген.
Кешеләр бар! – шуңа сөенәм.
Үзем монда – үзәк паркта йөрим.
Такташка баш ию – исәбем.
Нинди тавыш?
Өч-дүрт кеше.
Диләр:
– Эстрадада Мәхмүт Хөсәен!

## 1

Исле гөлләр исен хәтерләтеп
Искә төшкән Кармәт гөләбе!
Кичер мине, канәт, сезнең хакта
Ярты сүз дә язган юк әле...

*Х.Туфан*

Ничектер туган авылга бер кайткан арада яңадан тупыллар утыртып китсәк, начар булмас иде. Бергә кайтырга насыйп булсын.

*Сөрген. Зөфәр абыйсына язган хаттан. 31.1.1956*

Тарих мең дә тугыз йөз дә
Сиксән беренче ел бу –
Июнь аеның сигезе.
Чәчәкләрнең таҗларында, –
Тузанлы таҗларында –
Бал кортларының эзе.

Кармәтнең дә, Уралның да
Күгендә бер үк Җидегән,
Бер үк йолдызлар яна,
Бәлки, тагын бер малайның
Менә бу төн күңелендә
Шигъри чишмә уяна.

Сахрага чыгып киткән ул,
Сак кына дәшә төнгә...
Күбәләкләр очып уйный
Аның янәшәсендә.

Борынгы татар җирләре!
Аксубай олысының да
Басуларында урлар.
Ул да эзләгәндер, шиксез,
Таяныр җир, таяныр җыр,
Тик эзләве авыр ла...
Имән ышыгында үскән

Кадерлем син, и гөләп,
Аңлыйсыңмыни безне?
Синең тарих, синең гомер
Исәпләнә мизгелләп.
Сине сөрә алмый илдән
Һичбер нинди каһәр дә...

Кеше соңгы көннәрен
Каршылый таш шәһәрдә.
Гөл исе аңа, гөл исе!
Коллыкта үскән
гладиолусларны
Килми аның иснисе.

Иркен сахрада тирбәлгән
Ирекле гөлләр исе!
Әкрен искән дала җиле!
Шыпырт искән урман җиле!
Килегез әле, килегез,
Белегез аның хәлен?

Ул сезнең дә шагыйрегез.
Булдыгыз рәхимлерәк.
Әгәр эш дәгъвага китсә
(Еш кына шулай да була),
Зурырак аңа хакыгыз...
Ул сезнең үз шагыйрегез.

Әкрен искән дала җиле!
Шыпырт искән урман җиле!
Килегез әле, килегез,
Белегез аның хәлен!

Аһ, һаваның тымызыгы,
Кояшның симезлеге...
Күк, кыйбатмы күкрәвең?

Казанда таш стеналар,
Көннәрнең салмаклыгы.
Кыса шагыйрь күкрәген.

Ул туфан теле. Рөхсәт
Итмәсә дә саулыгы.
Дөнья белә: түгел ул
Тымызык күл балыгы.

Тупылларга яңгыр кирәк,
Күңелләргә яңгыр кирәк, –
Ис, җил-җиләс, бәр, яшен!
Нинди көн икәнен илдә
Беркайчан онытмый шагыйрь,
Онытса да үз яшен.

Йолдызлар дерелди күктә,
Йолдызлар төрле-төрле.
Тарих мең дә тугыз йөз дә
Сиксән беренче ел бу,
Гайса туганнан бирле.

## 2

Судить итәргә материал тапмагач, «Ант» өчен гаепләп, «Ант»та юлбашчыларны үтерергә чакырган фикерне әйтергә теләгән»,– дип яла тагып, эшне трибуналга бирделәр. Анда, комедиягә охшаган суд ясап, атарга хөкем иттеләр. Бер ай чамасы смертниклар камерасында яттым.

*Төрмә. Хатыны Луизага язган хаттан. 1942*

Кеше туа, юлга чыга аннан...
Ләүхел мәхфүзендә сызганны
Чынга ашыра, имеш. Коелганчы
Киек Каз Юлының тузаны
Чәчләренә,
Һаман бара кеше.
Такыраеп беткән сукмак та...

Ничә кием чабатасы тузган,
Күпме йөрәк тузган бу якта.

Кемдер барып җиткәндер дә, бәлки,
Барып җитмәгәне күбрәк.
Калкып чыгамыни курган булып
Чабатадан төшкән туфрак?!

Ничә гасыр кулда зынҗыр булган?
Күзен төбәп офык ягына,
Күз яшьләрен йотып алга барган,
Ышанганга киләчәгенә.

Ничек исән калган бу ышаныч?
Гаҗәпләнсәң гаҗәпләнерлек –
Чорлар аша килеп җиткән безгә,
Үлмәс дастаннарга әверелеп.

Җыры юкның гомере юк аның,
Киләчәк юк! ансыз халыкка...
...Безгә кадәр алып килгән җырны
Иңнәренә салып Алыплар.

3

Таптаган каткан киездә
Гарепне Батый тезе:
Ничәмә миллион метиста
Әле дә яши төсе...

Җиде йөз еллык фактның
Гайбәтен сата-сата,
Кызлары тагын татарның
Килгәнен көтеп ята.

*Х.Туфан*

Кылычка кылыч бәреләә,
Күзләрдә төтенле гарь...
Кылычка – кылыч.
Юл озын

Кеше бугазына кадәр.
Чыңлый кылыч.
Ачыла
      үлем кочагы.
Кочаклый.

Качып булмый.
Ә юл озын –
Кеше бугазына чаклы.
Егыла батыр.
Йоклар.
      Арган.
            Йөзе ак.
                  Садә.
Кылыч,
   уклар.
Юл кыска! –
Кеше бугазына кадәр.

Төн каплый йөзгә пәрдәсен.
Көн үткән – дәһшәтле, яулы.
Ашыгалар.
Кем китерсен
Иякне бәйләргә яулык?
Кем укысын баш очына
Килеп соңгы доганы?
Череп таркалыр. Җир белән
Кушылыр тәне, каны.
«Кан белән юылган дан
Олуг та ул, саф та, ак та»... –
Шуңа ышана җиһангир
Дошманын җиңгән аймакта.

Сугыш кырын карап йөри.
Шәп алышканнар төнә!
Менә туктый – ялгыз, горур –

Иелә батыр өстенә.
Әмерен бирә аннары
Күмүчегә каерылып:
«Үзен генә күм батырны,
Кабере торсын аерылып.
Аерылып! Баш очына
Куярсың язып таш та!»

Дәшми тора. Аннан өсти:
«Итеген салдыр башта...
Безгә бик ерак барасы,
Безнең көч белми чикне.
Итекләр кирәк!»

Юл озын –
Кеше бугазына тикле.

...Юл чатында ялгыз кабер –
Кем күмелгән, кем кабере?
Туктамыш хан яранымы?
Аксак Тимер яугиреме?

Кәлтә шуыша янәшәдән,
Янда чикерткә көлә.
Кылганнар нидер пышылдый
Таныш булмаган телдә.

Җил исә тагын,
Себерә
Үле телләрнең эзен.
Бииһая зур үрмәкүч
Күчерә пәрәвезен.

## 4

Дурт йөз еллык иске гадәт
Тешне кысып, җылап димли:
– Чыда, чыда,
Тагын чыда!

*Х.Туфан*

Бер малай йөгерә урамнан.
Урам буйлап,
кичкырын.
Чәче көл кебек малайның,
Күзләре зәңгәр-соры.
Тавышы – яшел.
Сискәндереп
Тәрәзләргә бәрелә:
«Поп килә! Поп килә!»

Җемелдәсен тәреләр!

Агай-эне кымшана
Каршыларга кунакны:
Яшерелгән иконалар
Почмакларга кунаклый.
Авыл гөжли корт иледәй.
Әй-дә...
Гомум тантана!
Төссез елмаеп, өстәлгә
Менеп утыра «анкала».
Менә ничек! Көтәләр
Батюшканы атлыгып.
Менә ничек!
Аңлый ул
Подданныйлар шатлыгын –
Җәһәннәмгә олаксын
Христианнан гайресе.
Өскә, аска сикерә
Муендагы тәресе.
Әйдә, әйдә!
Бие, бие!

Биегән кеше бай була.
Төшеп бии Галәви,
Төшеп бии Хәйбулла.
Тырышалар «раб божий»лар,
Ышаналар, кәнишне!
Поп канәгать.
Күрми ул
Яңактан аккан яшьне.

...Әй, сез, юнан бөекләре!
Көнбатыш даһилары!
Шәрекънең хәкимнәре!
Сезгә таныш
Халык зары, аһлары.

Ә монда
Бер малай йөгерә урамнан, –
Сезнең хыялга да хәтта
Коточкыч ят драма.

...Текәлә поп мужикка
Һәм бала-чагасына.
Нишләп брак теркәлмәгән
Чиркәү кенәгәсенә?
Тагын беткәннәр азып.
Басурманга бала табу
Чиркәү каршында язык!

Языктан арынырга
Гыйбадәткә чакыра.

Күзләрен мөлдерәтеп
Зөлхиҗиннәр карап тора,
Гөлзизиннәр карап тора, –
Зинадан туган балалар!

А, надан, вәхши кавем, –
Димәк ки, аз кыйналган?!
Алда әле күрәсе,

Туймасагыз кыйнаштан,
Уйнаштан туган нәсел.
.......................................
Тукта...
Тавыш...
Яңгырама
Караңгы ерак чордан.
Мин кабер янында, булмый
Качып пычрак яңгырдан.
Тукта!
Попмы, министрмы,
Әллә галимме син,
Тик тор!
Күтәрелер Гөлзизиннәр,
Илгә Туфан тудырыр.

Бер малай йөгерә урамнан,
Кешеләргә – калебе.
Чәчләре көл кебек аның.
Хәер,
Йөзе дә... көл кебек.

5

Здесь покоиться тъело
Николая Ивановича
Ильминскаго,
великаго просвътителя инородцевъ
учением Христовымъ.

*Кабердәге таш тәредән*

Ни генә юк анда – тарихыбызда:
Нахак та бар анда, хак та бар,
Халкым юлларына киртә итеп
Кадакланган канлы такталар...

*Х.Туфан*

Бу кайсы чор?
Бу кем – мәһабәт, чандыр.
Ә-ә, сезмени...

Галиҗәнап
Ильминский әфәнде.

Сез күптән «оҗмахтадыр да»,
Онытылмый Сезнең эш.
Исемегезне рәхмәт белән
Искә алырга тиеш
Без –
«Туземец» балалары.
Иисус кабул кылса...
Кичерегез, зинһар өчен,
Әгәр борчыган булсам.

«Яхшы индеец – үле индеец» –
Бәлки, бердәнбер хак юл?
Шәбен шәп тә, тик кызганыч –
Рәсәй өчен батмый шул.
Империя зур. Балтикадан
Татар
    бугазына
        кадәр.
Кем эшләр, кем илне саклар,
Һәммәсен суйсак әгәр?
Баш иям, Ильминский!
Тәгълиматың саллы.
Хуп!

Бер ел юынмаган поп
Чиркәү ишеген ача...
Мунчалы кара халыкны
Тиздән ул агартачак.

Басурманның күңеленә
Салырга гына орлык –
Тишеп чыгар тәре булып
Империягә тугрылык!

Россия зур.
...Мәгърифәткә юл озын бик,
Михнәтле –
Мәрьям-ана сурәтеннән
Татар
    бугазына
        хәтле.

6

Әти, бүтән авылларга мич чыгарырга барган чакларында,– офыкларның аргы якларындагы киң дөнья белән таныша башласын диптер инде,– мине дә үзе белән алып китә торган иде. Шундый «читтә» йөрүләрдән мин арып түгел, ә баеп, әллә никадәр яңа җыр отып, табышмаклар, мәкальләр, яңа сүзләр отып кайта идем.

*Туфан истәлекләреннән. 1970*

Кара таңнан кем бу?
Малае бар.
Кулда таяк, күктә ай агы...
Басу капкасына җиткәндәрәк
Хәсби очрый,
    җиңел аягы!

– Фәхри әзи, кая юл тотышың? –
Хәсби шулай хәлне белешә.
Гәпләшергә икесе дә нипруч,
Ни дисәң дә таныш-белешләр.

– Дөнья күрү зыян итмәс, димен,
Төпчекне дә алдым бу юлы...

...Малай инде йокысын дәвам итә,
Әтисенең ботына сыенып.

– Өйрәнер шунда мич чыгарырга,
Тәрәз куярга.

Хуш иттек, Хәсби.
– Рас! – диде Хәсби.– Һөнәрле үлмәс,
Һөнәрсез кеше көн күрмәс, ди.

Фәхри абзый оста – мич чыгара,
Тәрәз куя, сәгать төзәтә.
Улы булыша,
кәлә,
елый,
уйлый,
Өлкән кешеләрне күзәтеп.

Мич чыгара, тәрәз куя абзый,
Хөрмәтле дә эше, олы да.
Ләкин салкын.
Салкын!
Илдә салкын –
Бернинди мич алмый җылыта.

Фәхри абзый!
Мич чыгару шәп тә,
Улың аны барыбер онытыр.
Килер вакыт – ул меңнәрчә өйне
Үз йөрәге белән җылытыр.

Тәрәз кую шәп тә.
Тик ул алыр
Кулына каләм, ап-ак кәгазьне...
Һәм зурайтыр
Аңа кадәр Тукай
Күңелләргә уйган тәрәзне.

## 7

Тибәрсә дә, этәрсә дә читкә,
Тарих, бабаларың искә ал:
Китмә, күчмә, бер карыш та чикмә,
Үз Тукаең барган юлда кал.

Ни күрсәң дә,
Берәм-берәм түгел,
Бергә күтәр, бергә чыда син,
Еласаң да әгәр берәр чорда,
Алты миллион, бергә ела син!

*Х.Туфан*

Аяк бөкләп утырганнар киез өстенә
Шәкертләр.
Көтәләр.
Бер хәл бармы? –
Күпме вакыт үткән дәрес башлануга,
Мөгаллим юк.
Бүген бик соңарды.
Йөзә мендәр баш өстендә, болыт сыман.
Шау-гөр килә торак...
Шәкертләргә кызык.
Алар өчен әле
Бу гадәти иртә.
Һәм дәресләр
«Туган тел»не җырлап башланачак.

Кинәт кенә ачыла ишек.
Бу – мөгаллим.
Бетә ыгы-зыгы.
Баш өстендә ачы көлемсерәп
Бөтерелә каз мамыгы.
Мөгаллимнең тавышы тоныкланган.
Тартышып куя уй нидер сизенеп...
– Балалар...
Тукай вафат...
Уку булмый – бүген матәм көне.

Матәм көне...
Җырлыйлар «Туган тел»не.
Бу – хушлашу Тукай белән.
Бу – кавышу Тукай белән.

Җырлыйлар...
Күп калмаган – язылачак әле иңнәр.
Ыргытылыр өскә
Рухны басып торган олы мендәр,
Кимсетүче көчкә
Әйтер алар үз сүзләрен
Телләшеп.
Явар җиргә нәфрәт булып
Чорлар буе ашкан күз яше.
Җырлыйлар, җырлыйлар бөгелеп,
Әкрен генә, әкрен генә...
Җитәр вакыт, тураерлар –
Шундый итеп сугарлар
Царизмның колак төбенә –
«Туган тел» булып яңгырар кайтавазы.

8

Галлей кометасының Кояш тирәсенә килеп чыгуын күреп китәсем килә. Галлей кометасы, чиксез фазаның ерак почмакларында гизеп йөргәннән соң, 76 ел дигәндә, яңадан пәйда була. Ул 10 нчы елда безнең Кояш һәм Җир яныннан узып киткән иде. 1986 елда яңадан килеп чыгарга тиеш. Минем аны тагын бер кат күрәсем һәм инде саубуллашасым килә. Тагын яңадан 76 ел яшәп булмас бит.

*Сөрген. Зөфәр абыйсына язган хаттан.*
11.05.1951

Могҗизамы?
Кешеләр мәш килә.
Яшь-җилкенчәк шунда, карт-коры.
Бу –
        койрыклы йолдыз узып бара,
Караңгы төн китә яктырып.

Әйтеп өлгер – кабул була теләк,
Малай уйда, яшь ул –
ни әйтсен?
Йолдыз белән җитмеш алты елдан
Соң да очрашырга нияте.
Бетте.
Кап-караңгы.
Гүя кемдер
Җир өстенә каплый толыбын.

Якты хатирәгә өртер шагыйрь
Туган якның караңгылыгын!

Афәт әле ерак...
Ә яшьлекнең
Кәрнизенә уелыр бу кичләр.
Кара күктә Галимҗаннар балкыр,
Атылып калыр япь-яшь Бабичлар.

Казанда да, Себер күгендә дә
Шул йолдызлар.
Ярый алар бар.
Япа-ялгыз барганда да җирдә
Мәңге синең белән калалар.

Узды йолдыз.
Галәмдә үз юлы.
Койрык-эзе генә югыйсә,
Күк гөмбәзе буйлап сузылган да
Җир йөзенә һаман нур сибә.

Шагыйрьләр дә шуңа охшаш ласа...
Китә алар, ләкин эзләре
Кылыч кебек төнне ярып керә,
Балкып куя гомер үзәне...

...Йолдыз нуры җыйган күзләренә
Таң гөленең чыгы сирпелгән.
Нинди уйлар били сине, шагыйрь? –
Нигә күз карашың биртелгән?
Себер кыраулары эремәс шул...
Шуңадырмы чәче дә аның
Аксыл нурланыштан гыйбарәт ич, –
Хәтерләтә Себер буранын.

Сынык күңелгә соң күпме кирәк? –
Туган илендәге илендә –
Гөлләргә су сибә дәшми-тынмый,
Ялгыз Туфан
Аккош күлендә.

Һәрбер куак дусты аның хәзер,
Сөеп үтә һәрбер үләнне...
Җан хөрлеген тартып алып булмый!
Сорап алып булмый, теләнеп...
– Күрдек! – диеп, кемдер күкрәк кага,
– Күрдек...– диеп, кемдер офтана.
Ул эндәшми.
Шигърияттә – туфан,
Ә тормышта –
Үлән тыйнаклыгы Туфанда.

9

...Монда көн дә 5–6 кеше үлеп тора. Шешендем.

...Фатих Кәрим дә безнең камерада. Аның эше яңадан каралырга тиеш. Иректә бергә үткәрелгән көннәрне, балаларны, Кадрияне, сине искә төшереп, кайгыларны уртаклашып бергә яшибез.

...Халкым каршында, ил алдында аз гына да гаебем юк минем! Моның шулай икәнен киләчәк тиздән бик ачык итеп раслар.

*Төрмә. Хатыны Луизага язган хатлардан*

Керфексез күз ишек тишегенә
Береккән дә һаман күзәтә...
Сөялмәскә!

Черем итмәскә!
Син
Күз уңында хәзер, тозакта...

Их, озакка сузылды ла хөкем,
Йә атсыннар, яисә лагерьга...
Иңләр калын Себер урманнарын
Саз-пычракта,
    карда,
        яңгырда.

Маңгайларга безнең язылганмы –
Син татарсың, димәк, лашманчы!
Урыс дәүләтенә урман төплә,
Черки-җаның күккә ашканчы.

Әлегә син япун ышпиуны...
Туган балаларың хакына
Карышмасын кулың, имзаңны сал,
Дошман идем, диеп, халкыма.

Баш миендә гүя ачкыч чыңы...
Ыңгырашып ишек ачылса,
Кысыла да эчтә ачы сагыш,
Күзләргәчә менә ачысы...

Иләк аша үткәрәләр монда...
Ары-бире йөри караул:
Ишетелә итек тавышлары –
Йөрәк аша гүя бара ул.

Шыгыр-шыгыр атлый.
Шигырь-шигырь...
Башларымны гына ашадың... –
Сарыла ул төрмә диварына:

Тудым... үлдем...
Кайчан яшәдем?

Сөялмәскә!
Ачкыч шалтыравы
Телде җанны, үтте үзәккә...
Камерада – мин ул.
Керфексез күз
Береккән дә мине күзәтә...

Ни эзлим мин төрмә диварында?
Берәр имза, тамга-фәләнме?
Кемнәргәдер матур дөнья
Нигә
Безгә арты белән әйләнде?

Бу диварны төртеп аударырлык
Көчем дә юк минем, юк үчем...
Безне уктан саклаган ул элек,
Саклый безне хәзер ук өчен.

Башны ташка мәңге ора шагыйрь...
Уе сезнекеннән үзгә дә,
Ләкин төрмә шул ук!
Керфексез күз
Тын да алмый безне күзәтә.

10

...Минем бит матрас та, одеал да, мендәр дә юк. Өс киемнәре шулар хезмәтен дә үтиләр.

...Уналтынчы ел инде менә минем галстук бәйләгән һәм ул турыда уйлаган да юк.

...Кечкенә өйнең тәрәзәсенә Анна Михайловна килеп: «Александр Иванович, тиз генә ызбага кер әле, хәзер үк!» – дип эндәшеп китте. Нәрсәгә икән, дип уйладым...

*Сөрген. Зәфәр абыйсына язган хатларыннан*

Истә калды, Себер, мәңгелеккә
Жырыңдагы гүзәл гадәтең;
Хатыннарың биргән изге икмәк,
Малайларың биргән тәмәкең.

*Х.Туфан*

Гули гүя Себер далалары –
Ул авазлар кайдан килә соң?
Астан, астан...
Мең ел элгәреге
Тояк тавышлары, күрәсең,
Сеңгән монда – тирән катламнарга –
Көнбатышка чапкан атларның.

Ә син – җиһангирләр нәселеннән –
Этап белән кире атладың...

Гули, гули кыпчак далалары!
Моннан инде яңа хуҗалар,
Коллар куып, һаман элеккечә
Көнчыгышка таба узалар.

Бозау кадәр этләр ырлый янда –
Адымыңны, тоткын, чамала!
Читкә чыксаң – маңгаеңа пуля, –
Элеккечә һаман замана.

Башын иеп шагыйрь сазлык изә –
Тартыр аны нинди тегермән?
Каерылып артка карый...
Кем ул?
Мин...
    абына-тора
        йөгерәм...

Сузам кулны...
Егыла күрмә, Туфан!

Этләр монда усал, явыз бик!
Була алмый, була алмый шигырь
Явызлыкка каршы авызлык...

Башын иеп ул сазламык изә,
Төшенгәндер эшнең серенә –
Тиран белән килешалмый шагыйрь:
Үтерелә яки сөрелә!

Сүзе кала әмма...
Ничә гасыр
Оран салып җирдә үч йөри –
Озын юлдан Назон атлый һаман,
Петефиләр зынҗыр өстери.

Гүли гүя Себер далалары –
Ул авазлар кайдан килә соң?
Астан, астан...
Мең ел элгәреге
Тояк тавышлары, күрәсең...

Көтү көтә шагыйрь...
Һәрбер мажик
Әверелгән хәзер түрәгә!
Йөгерә ул...
Чыбыркысы арттан
Кара еллар кебек сөйрәлә.

Иңбашына кем ул төртә тагын? –
«Прометей» дигән үгезе
Сәлам бирә аңа.
Чыңлап куя
Мөгезендә чылбыр өзеге...

Башын иеп шагыйрь сазлык изә,
Еллар уза шулай, яшь бара...
Нинди язмыш? –
Үгез булып үгез
Дәшә сине азат яшәргә.

Сагынулар кысып ала җанны,
Тормыш авыр, авыр, газаплы...
Кол булганда халкың,
Шагыйрьләргә
Генә килә алмый азатлык.

Гүли дала.
Ничә гасыр гүя
Оран салып җирдә үч йөри –
Озын юлдан Назон килә әнә,
Салаватлар зынҗыр өстери.

Мөлдерәмә тула күз чокыры,
Җәяүле син хәзер, и татар!
Бу дала бар – аунап елар өчен,
Яшәр өчен ләкин дөньяң тар.

Кит, Овидий, син дә!
Ул тиң түгел,
Аның юлы мең ел кирегә...
Ул сыерлар көтә...
Ә бабалар
Толпарларга менгән биредә.

## 11

Син сорама, мине җәлләсәң,
Җәлладларныңниләр кылганын:
Мин җавапның әйтермен бары
Трибуналга илтә торганын.

*Х.Туфан*

Әзәрлекли кайчак ул үткәннәр!
Тынгы юктыр, ахры, кешегә.
Күрде төш авыру шагыйрь бу төн,
Төрмә керде тагын төшенә.

Нигә һаман уе гомеренең
Китә караңгырак ягына...
Сагындыра язылмаган шигыре...
Туфан
гомере буе
сагына.

Төш күрде ул.
Инде ничәнче кат
Җәлил керә.
– Муса, исәнме?!
Ник сөйләшми...
Бер елмаеп шунда
Син бирешмә, картлач, дисәче...

Суырылган шагыйрь,
кыйнаганнар.
Нинди васыятең бар, кадерлем?
Төш бит кыска.
Хәер, озын ла ул, –
Татар бугазына кадәрле.

Күзләрендә бетмәс-төкәнмәс моң,
Юатасы иде эндәшеп.

Тик арада ничә дистә еллар, –
Болыт белән кайткан күз яше
Туган җиргә күптән сеңгән инде.

...Кулы белән кыскан бөерен.
Иренендә әйтелмәгән сүзе.
Бугазында газап төере.

Төрмә керә авыру шагыйрь төшенә,
Пышылдап кына кемдер эндәшә.
Муса?!
...Ничә дистә еллар аша
Туфан Җәлил белән
исәнләшә.

## 12

Мин үземнең мәгънәви байлыкларымның күпмелеген яхшы беләм. Шуңа күрә бер көн бәхеткә ирешәчәгемә бик нык ышанып гомер кичерәм. Уйлыйм ки, ул көн – үлгәннән соң гына булмас.

*Сөрген. Зәфәр абыйсына язган хаттан. 1.5.1951*

(10 июнь)

Соңгы тапкыр озатабыз аны.
Шул хакыйкать
барып җитми
кебек башка.

Ышанасы килми-и!
Ә югыйсә беләбез бит –
Кайт, дип, хатлар
Бармаячак аңа башка.

Соңгы тапкыр озатабыз аны.
Таныш түгелләре,
танышлары,
дуслар.

Мәңгелеккә юнәлә шагыйребез.
Татар зиратына
юнәлә
автобуслар.

Беренчесендә шагыйрь үзе бара.
Озатучылар белән тулы ике автобус.
Дүртенчесе – иң соңгысы... буш түгел.
Һәммәсенең юлы
татар зиратына.

Соңгы автобус! Соңгы автобус!
Беркем күренми.
Ләкин энә төртер дә
урын юк монда.
Озатырга килгән – үзе бара кайгы,
Процессиянең соңгы
автобусында.

Бөтен юллар да зиратка илтә.
Беләм дә бит, ләкин
Тәлгәш-тәлгәш күз яшьләре җанда,
Иңбашымда сагыш көлтә-көлтә.

Автобуслар
шундый тиз җилдерә.
Чәчәк күмәр тиздән аның каберен.
Уйлап куяр дөнья:
«Хәтта татар
Хөрмәт итә үзенең шагыйрен».

Гөлләр кала...
Кала нарасыйлар.

Таш биналар ышыгында алар
Көлә-көлә таган атына.

...Процессиянең соңгы автобусы
Кайгы
  төяп
    бара
      татар
        зиратына...

*1985 – 1991*

* * *

Көнне күмеп киткән көнчел болыт.
Күтәрелгән кылыч, ук очкан,
Дан-дәрәҗә, алтын-көмеш өчен
Туган белән туган орышкан.

Ә орышта иман онытылган.
Онытылган килер буыннар.
Җаннар киткән байлык-мал хакына-а...
Җаннарга да хәтта дөнья тар.

Батырлары канга батып яткан.
Шагыйрьләре үлгән егылып.
Тарих моны гафу итми икән,–
Җилгә очкан шөһрәт көл булып...

Дәһшәтле ат калган бары безгә.
Хәрабәләр калган өелеп.
Җырлар гына килеп җитмәгән тик,
Һәм югалган инде бөеклек.

# ТАШ ТУРЫНДА РИВАЯТЬ

Таш ташыйлар коллар –
Тау битендә
Уелып-уелып коллык эзе калды!
Таш ташыйлар коллар.
Ә ташлары
Тормыш кебек авыр,
        язмыш кебек саллы.
Арык иңнәрдәге шул авырлык
Бавырларны изгән бер мизгелдә
Асыллары күтәрелә илнең,
Асыллары сафка тезелә...
Селтәп ташлый берәү иңендәге ташны,
Таш тәгәри түбән,
    түбән,
        түбән!
Кузгала тау...
Һәм таш оча алдан –
Ул ләззәт таба үзенә ияртүдән.
Дустым, кеше!
Син үзәннән карап
Акыл сатма, тукта...
Кайчагында түбән тәгәрәү дә
Бөеклеккә илтә дөньялыкта.

# ИКЕ ФИЛ

Мин – һинд. Менә ул – минем ил.
Филләр сугыша, ике фил.
Иң гүзәл һәм иң куркыныч –
Филләр арасында сугыш,
Кем җиңәсен кем белә?
Утлы шар бөтерелә.
Бөтерелә утлы шар –
Ике фил сугыша.
Кан һәм тир...
Син – Будда!
Баһадирга бәһа бир.

Мин – һинд түгел. Менә ул – безнең җир.
Филләр сугышты – ике фил,
Ике фил йөгерә үзәннән.
Мин – шагыйрь. Мин тезләнәм...
Яшеренеп ят күзләрдән
Ике фил йөгерә үзәннән.

...Үләргә...
Соңгы сүз – черкиләргә.

# ИДЕЛ

*Равил Фәйзуллинга*

Дулкыннарың сугылалар килеп,
Алар, бәлки, хәтер сагында...
Син коточкыч чит шул миңа, Идел!
Син коточкыч миңа якын да.

Ерак әбием керен чайкагандыр,
(Туры килә безгә сыгарга!)
Коенырга дип кереп киткәндер дә
Оныткандыр кире чыгарга.

Әллә җилләр каерып атканмы аны
Ярдан читкә, сазлык-салкынга...
Син коточкыч ерак миннән, Идел!
Син коточкыч миңа якын да.

Ничә төннәр инде алтын балык
Төшләремә кереп йөдәтә.
Кара сулар туйдырдылар мине,
Каршы йөгер, Идел, йөрәккә.

Дүрт гасырлык сагыну бу сине,–
Әйдә, кемдер калсын пошаман.
Безнең якта арбалар да хәтта
Көймәләргә шундый охшаган.

Үткәннәре, киләчәге өчен
Мин ярлыкау сорыйм халкыма.
Син коточкыч ерак бездән, Идел!
Син коточкыч безгә якын да.

## ТӨНГЕ ӘКИЯТ

Иделемнән бөркелә бер яктылык,
Аймы әллә төшкән аңа атылып?

Яктырып китте күк менә дөньялар,
Күңеленә һәрбер нурын җыя бар...

...Җил йөгерде Идел-дәрья өстеннән.
Кемнәр килер тагын аның эзеннән?

Күмеп китмәкче дулкыннар шул айны,
Шашты алар, ә ай һаман елмайды.

Өзгәләмәкче булалар шәүләне.
...Аңаргамы соң аңларга хәйләне?

Ай һаман шул, тынып калды җил генә,
Идел-ярда сәҗдә кылам илемә.

## НИГЕЗ

Югалдың да оныттың, диеп,
Ромашкалар үбә теземне...
Кайттым менә туган нигеземә –
Туфрак бөртеге дә – безнеке!

Ташлап киттек шушы изге җирне,
Гадәтләрне онытып, йоланы.
А, тынгысыз нәсел, сәер нәсел! –
Аста ташлар сыкрап елады.

Шул токымнан – сәер нәселдән мин,
Кан да шул ук, шул ук – ярсулы!
...Чабуымнан тотып, җибәрмичә
Тора хәзер шәһәр шау-шуы.

...Шул нигез бит ерак бабайларның
Санап барган һәрбер көн-аен.
Яңартасы иде менә аны...
Ә яңартып булмас, мөгаен.

## ТАТАР

*(Филологик шигырь)*

Бу атка сыйган буатлар:
чиннәрдә – да-да, та-та...
румнарда – тартар...–
Җәһәннәм!
Асылы белән хата.

Туктаган юллар чатына,
тәкъдире кайсы якта?
Авызлык чәйни төнге ат,
кемнәрдер уктан ата.

Тат та бар биредә, ар да...
Бар да бар, тик... күңел тар!
Ятар ул монда кадерсез...
Аннан таң булып атар.

# ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕ ӘҺЕЛЛӘРЕНӘ

Булсагыз да сез аз санлы,
Кызганмыйча көчне,
Көрәшәсез күпчелекнең
Мәнфәгате өчен.

Йокы сарган, йоклый кавем –
Аңа шулай рәхәт.
Уятырга маташсаң да,
Беркем әйтмәс рәхмәт.

Сөрәнченең сере гади –
Сала, сала сөрән:
Барасы юл шактый ерак,
Чоңгыллары тирән!

Исән әле, исән, шөкер,
Бераз ил дә, тел дә.
Күзгә карап тавыш-тынсыз
Язмыш кына көлә:

Кысыла гына төшәр кыса –
Сөенергә иртә,
Азчылыкны яклаганда
Бу күпсанлы фирка...

# ЭТ-ТАТАР

Спи, младенец! Не то злому
Псу-татарину отдам!

*М.Цветаева*

Күтәр,
 төшер,
 менгер, татар!
Муенга ас!
Өстерә!
Мәгърибкә җит!
Шәрекъне ал –
Әнә хуҗаң өстерә.

Без беркемнең баласын да
Алмадык тартып ансы...
Йокласын ул төшләр күреп,
Һәм елмаеп уянсын.

Үссен, типкәләсен безне,
Түзәрбез, димә, ничек? –
Койрыгы кисек этләр сез!
Һәм мин үзем дә көчек...

Куалар юлдан һай-һулап,
Җирдә юк безгә бәһа.
Безнең кан белән тукланган
Юха күптән аждаһа.

Сиңа дигән тәре, татар!
Җилкәгә сал!
Өстерә!–
Ишәйгән әнчекләреңне
Синең өскә өстерә.

Өрмибез инде, шыңшып тик
Көч сорыйбыз Алладан...
Ә алар безнең исемне
Бүки итә ич һаман.

...Йом күзеңне, беркем тимәс...
Тик бәхилләш, әй бала.–
Алабуга өсләрендә
Шомлы гәүдә чайкала!

* * *

Халкым минем төнгә кереп китә,
Нефть суыра, иген игә дә...
Вакыт ага чәчем арасыннан,
Һәм төбәлә нидер чигәгә.

Җилгә оча сүзем. Әгәр дә ул
Арттыралса җилнең куәтен,
Көзге яфракларга уранырмын,
Давыл белән ябыныр оятым.

Беткән Хәтер, онытылган Тарих!
Тәрәзәсез-нисез туң йортта
Шат, бәхетле булып яшәү җиңел,
Әверелсәң гамьсез маңкортка.

Эндәшүем сезгә килешәме?
Юк, диярсез
Сез тук килеш, шәт?
Горурлык та
эреп
юкка
чыга,

Үз җиреңдә булсаң килмешәк.
Минме синең улың, мокыт кавем?
Кем син?
　　Кайда?
　　　　Кемгә хезмәтең?
Үзеңә тиң дөрес тарихыңны
Кайсы гасырлардан эзләттең?

Башка менми, иңгә оешса кан.
Иңдә камчы эзе, йөк эзе...
Башка телле таш калалар баскан
Бабаларның изге нигезе
Убылса да, кабер булып убар.
Кубарылып чыгар бер халкык:
Ерагаер якын дигәнебез,
Якынаеп китәр ераклык.

## УРЫС КЫШЫН ОЗАТУ

Ку әйдә, ку бу атларны!
Атлар юк чыдамаган.
Без үткәрсәк тә, бәйрәмне
Без уйлап чыгармаган.

Озатабыз урыс кышын.
Телдән йозак төшкән чак.
Язгы җилдән терелмәкче
Күптән тончыккан учак,
Күңелләрдәге учак.

Яз килгәндә бераз җанда
Уяныл китә өмет,
Тирәкләрдәге бөреләр
Күккә үрелгән кебек,
Нурга төренгән кебек.

Дөньяны түгәрәк, диләр,–
Ку әйдә, ку атларны!
Куып җитеп булмас, беләм,
Данлы-шанлы чакларны,
Әманәтле хатларны.

Ку әйдә, ку! Бар өметләр
Бара-бара кысыла...
Кайнарлатмас инде канны
Урыс аракысы да,
Сары урман кызы да...

Озатабыз урыс кышын,
Ул әле килер тагын...
Ә бүген язны кабул ит,
Узганнарыңны сагын!

# Һәйкәлләр

Двусмысленны все постаменты
на территории татар.

*В. Соснора. «Терцины»*

Шәһәрдә эңгер дә үзенчә
Куера урамнар өстендә...
Беркем юк беркемнең исендә,
Нинди моң – һәйкәлләр күзендә?

Һәрвакыт төшәләр юлыма...
Аста җир сыкранып куя да
Сак кына сөякләр уяна.
Шул сызлау күченә кулыма.

Казанда һәйкәлләр терелә!
Һәммәсе эңгергә уралган,
Вокзалга чабалар урамнан,
Мәскәүгә кайтырга, кирегә...

Түрәнең әмере бер генә:
Абдулла, ишеккә йозак ас!
...Беркем дә рөхсәтсез озатмас –
Һәйкәлләр мәңгелек сөргендә.

Кат-катлап сүгенә постта мент...
Ленинны тота да бөтереп:
– Синме бу? – дип,– тагын, и өтек!
Һәм эзли төн ката постамент.

# АЧЫК БАЛКОННАР

Кил әле, кил, диңгез, мен ярга,
Сөйләшик бер икәүдән-икәү.
*Х.Туфан*

Абхаз илен аз-маз таныйм хәзер –
Диңгез буе, таулар.– Гүзәллек.
Сылуларның ымлы карашлары...
Биредә дә булмый төзәлеп.

Балкон ачык Лорка теләгәнчә.
Диңгез шаулый, шаулый.
Кил, диңгез!
Тезләремә мен дә сөйлә әле,
Хәлләреңне синең белербез.

Исеңдәдер безнең нәселдәшләр,
Үзгәрсә дә сүзләр, исемнәр...
Төпкә киткән ачы язмышларга
Дулкыннарың башын исеннәр.

Онытсаң да, хөкем итмим сине.
Ни ул тарих?
Өстә – агайлар...
Озын булса, кыскарталар аны,
Кирәк икән – уйлап табалар.

Абхаз илен аз-маз таныйм хәзер.
Таулар йөгерә диңгез буена.
Монда яшәгәннәр җәннәткә дә
Кызыкмыйдыр кебек тоела.

Яу чапканнар бик еш бу якларга,
Илбасарга һәрчак юрган тар...
Халыкларны Себер сөрер өчен
Эшелоннар әзер торганнар.

Абхаз җире әле абхазлы ул...
Вакыт җитми калган, күрәсең.
Бәлки, башка сәбәп... Кем соң белә
Юлбашчыга ни уй керәсен?

Изүләрен чишкән Каф таулары...
Кара диңгез – яңа танышым.
Ярларына басып уйлыйм менә
Башка халыкның мин сагышын.

Ниндидер моң биләп ала җанны,
Күңелем тын, тып-тын, арылган.
Күбекләнеп комга сеңә дулкын,
Ахрысы, ул Кырым ярыннан.

Яңгыр булып явар туган җиргә!
Мескен сүзләр белән юатма...
Дулкыннар да безнең кебек, мәңге
Үз ярларын эзли, югалтса.

Балкон ачык Лорка теләгәнчә!
Диңгез шаулый, яңгыр сибәли.
Дөм караңгы төннәрдә дә, имеш,
Әйләнәбез Кояш тирәли.

Бермә-бер киң күңел офыклары,
Диңгез шаулый, шаулый.
Кил, диңгез!
Тезләремә мен дә сөйлә әле,
Хәлләреңне, бәлки, белербез.

# ТӨНГЕ САБАНТУЙ

*Гәрәй Рәхимгә – Гөргеригә*

Карт-корылар яши торган авыл –
Исеме Тәмте иде шикелле...
Төнге сабан туе – серле тәгъбир –
Шул авылга безне китерде.
Истә әле һаман тымызык кич,
Төнге яңгыр шавы... Шәп рәсем:
Яшеннәрнең күкне телгәләве
Күңелемдә яши.
Яшәсен!
Киң мәйданны яктыртты ул.
Дәшәм!
Шигыремә хәзер кер, яшен!
Төнге сабантуйның моңы истә –
Язмый түзеп булмас, күрәсең.
Борынгы мин шигырь шикелле үк,
Керәшеннәр кебек яшь тә мин...
Көчле булып яшәсәм дә һаман,
Үчле булып ләкин яшәмим.
Кайчагында кайбер Канашевич
Үреләдә карый үр аша.
Яшен керә кеше күңеленә...
Керәшеннәр төнлә көрәшә.
Таңга күчә.
Калмый караңгыда,
Чыланыплар чыга чыклардан.
Чукындырган чагында да хәтта
Көрәш дәрте истән чыкмаган.
...Елга үзәнендә яшел чирәм.
Су юк хәзер.
Никтер чигенгән.
Безнең арттан йөгергәнме әллә,
Бәреп чыгып ярлар чигеннән?

Минем нәсел ерак-ерак киткән,
Куып җиталмас су берничек.
Диңгезләргә агып булмас инде,
Ярты юлда гына күрешеп.
Яшәп яту шунда – торган җирдә,
Аҗаган дип белеп яшенне.
Кирәк чакта төштә көрәш күреп,
Эчтән генә укып ясинне.
Монда менә төнге сабан туе,
Кайнар аркаларда – ап-ак пар.
Әгәр мине йокы сарса,
Хыял! –
Төнге көрәшләргә алып бар!

Таң алдыннан елап кузгалырмын,
Кемдер үрелеп карар үр аша.
...Коры ярда әшнәләшеп алган
Керәшәләр генә серләшә.

# ҖЕП

Рус белән тормыш кичердек сайрашып...
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп...
*Г.Тукай*

Җир иркен дә, күңел тар шул...
Йодрык кебек кысылган
Кырым
    мәхрүм итә безне
Бүген ипи-тозыннан.

Сытты безне туган җирдә
Илбасарның табаны...
Өстәвенә вәхши диеп
Өскә яла ягамы?

Ак күңел нигә аклансын?
Кем чиста – аккан яшьтән?
Нарасыйлар каны монда
Ташлар булып укмашкан.

Нинди язмыш? – үз йортыңның
Ишекләрен ачалма...
Җимерелгән каберләрдә
Ауный бүген таш чалма.

Кайда соң ул Тукай күргән
Без бергә теркәлгән җеп?
Гәрәйләрнең сөякләре
Хурланып ята, рәнҗеп.

Аһ, башка төшкән бу вәхшәт!
Татарга тигән гарьлек,
Җир кебек бүлгәләсәң дә,
Урыска да җитәрлек...

## ЛИТВА – 1991

Агачларның күккә очуларын
Ничәнче кат төштә күрәм инде...
Күптән онытылган йолдыз җиле
Җилкендерә инде йөрәгемне.

Боз сөңгеләр коела ябалдаштан –
Яңабаштан дөнья үз тоела.
Еллар таккан ямьсез йолаларны
Йолкып ат та юлда – ела, ела!

Дулкыннарны ярлар ярлыкамый!
Тыны кысылган кысыр балык сыман
Берән-сәрән сикерәбез өскә,
Имеш, күңел күккә алгысынган.

Тончыгабыз – өркеп төн чыгабыз...
Тончыгабыз – сөрсеп беткән көне...
Киләчәкне томан томалаган,
Гөман һәм шик сарган үткәннәрне.

Кайнатабыз дегет капкаларга –
Йөздән сөртеләсе сөремме үз?
Күзне буа өстә йөргән өрәк –
Абынабыз, тагын сөртенәбез.

Ә агачлар китә-китә бездән,
Тамырлардан тама түбәнгә ләм...
Галәм күләмендә тантанага
Яшел алкыш...
Шагыйранә әләм.

# ALMA MATER

Бабам минем Казан йөргән, диләр.
Надан түгел, бераз уйлагандыр...
Бу мәһабәт бина янына ул
Якын килергә дә кыймагандыр.

Мин дә менә гасыр ахырында.
Маңгаема тиеп көннәр ага.
Бүтән заман, башка заманда без! –
Йөз ел тула бөек сходкага...

Альма матер! Ул көннәрнең рухы
Әле исән! Безнең истәме соң?
Музееңда хәзер алар эзе...
Көрәш сүзе – синең синонимың!

Табанымны таный урам ташы,
Альма матер, мин дә үттем синнән.
Хәтеремдә, дустым Һашим белән
Чыгып киттек тарих дәресеннән...

Без тарихтан чыгып киткән икән,
Ничә тапкыр менә, ничә тапкыр...
Бүген инде кичерә күр безне,
Аклап кичер әмма, альма матер.

Кабат килдем сиңа, синең алга,
Биек бинаң сорый кебек иелеп:
«Һашим кулы тигән диварларга
Киләчәктә кем орыныр килеп?»

Мин дә аның кебек авылныкы –
Монда безгә хөрмәт, кадер хәтта...
Тулай торак өстендәге күк тә
Авылыбызның күген хәтерләтә.

Тик кайда соң шәрекъ?
Мәгърип кайда?
Кая карап җанны юатырга?
Бу шау-шулы таш калада бик тиз
Кыйбланы да мөмкин югалтырга.

Ялгыштык та... Охшап калды күңел
Керле тулай торак мендәренә.
Яңабаштан без пакьләндек килеп,
Альма матер, синең мөнбәреңдә.

Рөхсәт итче, мин үземчә итеп
Синең исәнлеккә дога кылам.
Кушылыр аңа, бәлки, дустым Һашим,
Казан артындагы бер авылдан.

Альма матер! Ул көннәрнең рухы
Синдә исән! Ә без аргы ярда...
Килдек сиңа, кулың тидер, зинһар,
Аңыбызга,
        җанга,
                карашларга!

# ЗИНДАН

Агыла да болыт, агыла...
*Х.Туфан*

Терәдем башны тәрәзгә,
Күңелем китте түгелеп.
Безгә ят түгел болытлар,
Болытлар безгә ят түгел...
Тәкрарлыймын: ни син, кеше?
Пәрәвездә сүгенү сүзе
Чәбәләнде, чәбәләнде,
Ватылды идәнгә төшеп.
Борынгы, ирекле болыт
Дымлы иреннәре белән
Керфекләремә орынды –
Тәрәзә куйды сулыгып.
Кеше икәнеңне, егет,
Онытма, онытма-а,–
Тәрәз аша моңсу-моңсу
Пышылдадылар болытлар.

*1983*

* * *

Ярга бәрелеп,
Күңел ярларына,
Көмеш сулар шаулый, көмеш сулар.
Дулкын арты дулкын килә безгә,
Югалтулар арты югалтулар.

Көмеш сулар – кемнең кайтавазы?
Ярсып-ярсып ала, тагын тына...
Кайсы чордан килә бу дулкыннар
Бүгенемнең нәни ярларына?

Югалтулар арты югалтулар,
Ак күбеккә батып, ак төсләрдә...
Алтын балык тоталмаган мәллә
Безнең нәсел шушы инешләрдә?

Җавап көтеп ерак гасырлардан
Бер мизгелгә дөнья кала тынып.
Судан ыргытылган балыклардай,
Эзем кала ярда тыпырчынып.

Яраларга бәрелеп шаулый сулар
Яры ишелеп торган инешләрдә.
Югалтулар арты югалтулар...
Ак төсләрдә.

## ТАТАРСТАН

Ярсып килгән дошман явы,
Дошман безне аткан, аскан.
Буйсынмаган беркайчан да,
Татарстан, Татарстан!

Абынсак та, егылсак та,
Без ул – аягүрә баскан.
Ярдәм итсен безгә Алла,
Татарстан, Татарстан.

Азатлыктан яздырырга
Беләзекне богау кыскан.
Күңелләргә богаулар юк,
Татарстан, Татарстан.

Томырыла аргамаклар,
Узганыбыз – гүзәл дастан.
Кузгалабыз изге юлга,
Татарстан, Татарстан.



# V БҮЛЕК

Таулар арасында мәгарәнең авызы ерактан каралып күренә иде. Килеп кергәч тә ниндидер сөрсегән, көкшегән ис – караусыз картларның ятагыннан гадәттә шундый ис килә – борынга килеп бәрелде. Мин тизрәк түргә ашыктым. Андагы юешләнеп торган стенага чүкеп нидер язылган иде. Әллә күзләрем тәмам чепиләнгән, әллә вакыт җиле әлеге язуларны тәмам ашаган, әллә мин бу хәрефләрне бөтенләй танымыйм – бернәрсә дә укый алмадым! Яшьлеккә кайтара торган дару! Тик мин аны ничек ясыйм? Миңа бик кирәк иде бит ул... Кипшенгән кулларым өметсезләнеп дымсу ташны капшады, мин түзмәдем, тавышсыз гына сулкылдадым.

Иртән мине бизгәк тота иде инде. Калтырыйм, тешем тешкә тими. Мәгарә дивары бер ерагая, бер убылып өстемә килә. Шул вакытта язуы да ачык укыла сыман... Бер почмакта аунаган өч аяклы нәни казанны алып килдем – ул борынгы илтабарныкы иде! – аңа стенадан саркыган суны җыеп салдым. Әлеге бәллүр суга кесәмнән алып имән кайрысы салдым – безнең як имәненнән! Олтанымнан коры тузан җыеп сиптем – безнең юлның тузаны! Учак җылысыннанмы, әллә дулкынлануданмы, мин шулкадәр эсселәгән идем, маңгай тире тып-тып итеп казанга тамды. Мәгарә уртасында таралып үскән сары чәчәкне өзеп мин шулар өстенә ташладым. Тик бу дару түгел иде әле. Мин чарасыз калып учак янына чүктем. Күземнән яшь сытылып чыкты да кайнап торган шул сихри измәгә төште. Казан эчендә нидер чытлады, өскә таба яшел ялкын суырылып күтәрелә башлады.

Мин, шул казанны күкрәгемә алып, кайтыр юлга чыктым.

...Көн кичкә авышкан иде инде. Башка кабарлык эссе сүрелгән, талгын һаваны дулкынландырып бераз гына җил дә исеп куйгандай булды.

Теге ярда бер ир-ат чалгысын кулга алды, янады, аннары кискен генә селтәнеп печән чаба башлады. Әле генә үзара ни турындадыр пышылдашып утырган кыяклар, каерылып, киң пакуска ава барды. Э-эх! – ир-атның шат, көчле тавышы бөтен болынны яңгыратты, кайтавазы ерак тауларга бәрелеп кире кайтты, үлән арасындагы чикерткәләр өркеп чык тамчылары сыман тирә-якка сибелеште. Ир кеше киң алдырып алга бара, кояшта

*янган ялангач аркасындагы мускуллар нәни бурсыклар сыман бер-берсенә таба йөгерә иде.*

*Кәтүк буйлы бер малай, учларын җәеп, аның артыннан чаба, печән арасыннан сикергән эре-эре җир җиләкләре аның өстенә төшә, малайның бите, куллары кып-кызыл җиләккә буялган...*

*– Э-эй! – дип кычкырдым мин, тик бу авазны агымсулар йотты, ир кеше белән аның малае, пакус аудара-аудара, кызгылт офыкка кереп югалдылар. Шулай да мин аларны танып калдым – печән чабучы ир – әтәем, аның артыннан җиләкләргә җилдерүче малай – мин үзем идем.*

# ШИГЪРИ ТӘФСИРЛӘР

* * *

*(2 нче сүрәдән)*

Күз яшедәй бәллүр дулкын килеп
Ялан аягымнан үбә тагын.
Кагылам да аккош иңнәреңә,
Мин сәҗдәгә сине уятамын.

Тып-тын күлдән балык сирпелгәндәй,
Нурлар сикерешә безнең күздә.
Үзгә кебек бу өр-яңа иртә!
Күңелләр дә бераз үзгә, үзгә.

Аллага да мәдхиябез бүтән –
Дәртлерәк һәм кыска...
Дөнья башка!
Мин текәләм сиңа, гүя мамык
Өзгәләнеп карый чакматашка.

Алла бүләк иткән бу ләззәттән
Өзгәләнсен җаннар, өзгәләнсен...
Күпергән дә көтеп ята үзән
Сәҗдәгә дип таулар тезләнгәнен.

Шарлавыклар аска томырыла,
Офык күтәрелә пәрдә сыман.

Елгаларның тагын сөте арта,
Бал саркыла туфрак арасыннан.

Син әйдисең мине куакларга,
Һәм башлана барысы да кабат –
Ымсындыра сине сусыл алма.
Мин сузылам аңа меңенче кат.

* * *

*(99 нчы сүрәдән)*

Мең яшәрлек дәү имәннәр беркөн
Шырпы кебек сынар, урман гүләр!
Калкып чыгып җирнең карыныннан
Авыр, авыр иман китерүләр.

Тимер ага эреп ярмәкләрдән,
Күк гөмбәзе күптән чәрдәкләнгән,
Бер сүнә дә офык, бер яктыра,
Адәми зат!
Ярлыкауны сора...

Тәкъва кебек кыланса да дәһри,
Ул беркайчан алдый алмас Аны.
Юк диярга барны мөмкин түгел,
Бар, дип ышандырып югалганны.

Җирнең карыныннан кузгалырбыз.
Туфрак коелыр бездән, тамар сулар...
Дошманнарын күреп сөенер кемдер,
Дусларына карап ямансулар.

Күз алдыннан үтәр узган гомер.
Ни эшләдек, кылдык нинди дога?
Кем онытты изге Бисмилласын,
Кеше булып юлга кузгалуга?

Берәү карар – күләр тиле кебек.
Берәү карар – тып-тын гына елар.
Хәтерләтеп безнең яшәешне,
Бер мизгелдә күздән узар еллар.

Куанырбыз аз булуын күреп
Бездән калган явызлыкның,
Әгәр
Сискәнмәсәк әрнеп шул чагында –
Кылган игелек тә – тузан кадәр...

* * *

*(90 нчы сүрәдән)*

Ничә ел мин бу шәһәрдә инде?
Таныш бугай хәзер һәр ташы.
Кем ук итәр кара диварларга
Бәрелеп сынган минем карашны?

Офыклар юк. Сүрән йолдызлар да
Шәһәр утларында эрегән.
Диңгез төсле шаулый төнге кала –
Дулкыннары куба эредән.

Кара-кучкылланган урам ташы,–
Әллә тузан инде, әллә кан.
Шунда яшибез без! Юкса Алла
Җирдә казганырга яраткан.

Янәшәдә ятимнәрнең зары,
Коллар ыңгыраша күптәннән,
Коргаксыган кулын суза кортка –
Хәер эсти үткән-сүткәннән.

Беркем күрми. Аллы-гөлле балкыш
Тимер рәшәткәләр эчендә.
Анда мәңгелек туй! Утлар балкый
Ярлы-ябагалар өчен дә.

Ә тантана бүтән! Мыштым гына
Якынлаша утлы гарасат,
Без күрербез аның күләгәсен,
Бер-беребезнең күзенә карасак.

Коргаксыган кортка кулларыннан
Наз эзләрләр... Кирәк булыр наз!
Ут ияртеп килгән уңганнарга
Уңга таба юллар табылмас...

* * *

*(77 нче сүрәдән)*

Атчабарлар чыккан юлга,
Җилдерәләр бер-бер артлы.
Игелек һәм яманлыкның
Арасы бит шундый шартлы.

Әмма алар төгәл белә:
Кем син? Ни син? Эчең-тышың,
Алып килә сиңа хөкем
Шул җайдакларның ярышы.

Килә вәгъдә ителгән көн,
Тотасыңмы аны истә:
Таулар очар тузан булып,
Һәм күкләр ишелер өскә.

Бу көнне ялган диюче!
Ярлыкау юк, бар да үткән, –
Синең мескен ялваруны
Беркем дә ишетмәс бүтән.

Без хуҗа! – дип күкрәк суга,
Халык сәхнәгә менүгә,
Мәңгегә килгәндәй уйный,
Аннан...
Давыл себереп түгә.

Килер вәгъдә ителгән көн,
Сурдан чыгар шулчак өн, ди...
Әлегә туй дәвам итә,
Монафикълар дингә өнди.

Атчабарлар чыккан юлга,
Инде соңармаслар бүтән.
Ямансу кичләргә күчеп,
Мин дә менә кичерү көтәм.

* * *

*(80 нче сүрәдән)*

Су йөгерә яшел үләннәр эчендә,
Нидер безләп төклетуралар күчелә.

Йөзем тәлгәшләре үрелеп кояш эчә,
Кошлар сайрый бакчаларда элеккечә.

Мин бер сукыр – тузанлы юл буйлап киләм, –
Яланаяк, ә өстемдә иске җилән.

Күрмәсәм дә: будыр кешелекнең язы! –
Ишетелә анда пәйгамбәр авазы.

Ава-тора, йөзем куаклары аша,
Тәнем-җаным шул авазга якынлаша.

Бакыйлыкта хозурына керерменме,
Һәм Тәңренең нурлы йөзен күрерменме?

Тынны кысып бер читтәрәк көтеп тордым.
И пәйгамбәр! Ник йөзеңне читкә бордың?

Шул мәнидән яраткан бит юкса Алла,
Һәммәбездән бер калкулык туфрак кала.

Сур тавышын син, пәйгамбәр, искә төшер, –
Туган туганны күрмичә йөгерешер.

Берәүләрнең йөзе балкыр шул сәгатьтә,
Сукырларның күзләре дә ачылыр хәтта.

Мәңгелекнең шулчак мин күреп узармын
Тәкәбберләр чыраендагы тузанын...

* * *

*(94 нче сүрәдән)*

Сәҗдәгә әгәр егылсаң,
Тәңре күкрәгеңне ачар
Өстән иңгән хакыйкатькә,
Һәм яңгырар җанда – ашшар!

Канга баткан иңнәреңнән
Ул авыр йөк төшәр шулчак,
Кочак-кочак өмет өстәп,
Офыкларда янар учак.

Җанга җиңел булган чакта
Иңдәге йөк – мамык сыман.
Җиләс җил йөзне иркәли,
Исеп таулар арасыннан.

Йөрәкне ачып Аллага,
Чалмаларны сыга-сыга,
Алга омтылу ул безнең
Үзе дә төкәнмәс дога...

## ГОМЕР

Буран дулый,
Җанны кыйный,
Бәргәләнәм, йөгерәм.
Галәм кебек чиксез кырда
Юл табалмый тилмерәм.
Буран дулый,
Кар диңгезе.
Кар түгел бу, шом ява!
Җаннар мәллә?
                    Офыкларда
Меңәрләгән ут яна...
Күбәләктәй күренәләр,
Сәлам безгә җәйләрдән!
...Дөрестер ул – кеше җаны
Күбәләккә әйләнгән.

Буран дулый,
Җанны кыйный,
Бәргәләнәм, дивана!
Кызыктырып офыкларда
Меңәрләгән ут яна.

* * *

Ташларгамы җанны чиксезлеккә
Йолдыз белән кыскарсын дип арам?
...Юк шул, юк шул, сәгать саен менә
Туган туфрагыма иңә барам.

Бик гадәти шул мин – Җир малае,
Бик гадәти нәни, соры өем.
Йоклыйм шунда, ипи ашыйм –
Монысы
Туган җирем белән үбешүем.

Бураздадан бәреп чыккан нәсел,
Җан асрыйм бик гадәти якта,
Тарту көчен җиңүчеләрне дә
Күз алдына китералмыйм хәтта.

Мин үземә шундый охшаганмын,
Талпынырга юк куәтем, чарам.
Береккәнмен җиргә шулкадәр дә:
Туфыракка әверелә барам!

...Үзең үзең инде, ә бит җаның?
Ул бит күккә аша дисездер дә,
Җан дигән сүз матдә түгел,
Әмма
Ул да менә сеңә бара җиргә.

## Ә КҮКЛӘРДӘ

Җиребезгә әкрен генә иңә төн –
Сизәсезме күзгә кояш сеңгәнен?

Тамырымнан ага тынлык җай гына...
Изри бәгырь – хисләр кайта ярына.

Бәлки, күңел шул халәтне сагынган?
Туа шигырь – ага сагыш җанымнан.

Шушы тынлык йөрәгемне сорады!
...Ә күкләрдә дулый йолдыз бураны.

## КҮРЕНЕШ

Дәү кеше, кеп-кечкенә әрем,
Алсу офык, зәңгәр күк гөмбәзе.

Дерелдәде әрем – исте җилләр,
Офыклар бер-берсенә йөгерделәр,
Һәм күк гөмбәзе егылды түбән,
Әрем башын игән.

Өнме соң бу, төшме?
Зәңгәр офык, алсу күк гөмбәзе,
Зуп-зур әрем, кеп-кечкенә кеше.

Нигә шаккаткан соң? Сәҗдәгә егылган
Кемгә?
Нинди сурәт
Әремгә эләгеп калган ул күк гөмбәзендә?

## КҮК КАПУСЫ

Яшел үләннәрнең бәгырендә ак кар.
Кыш буена дөнья болытларны аклар.

Җылы эзләп үлән җиргә сыгылган ла! –
Күккә карый икән ул да егылганда...

Сусыл ылыслардан оеп коела бәс,
Язга кадәр инде каплар безне гөмбәз.

Нарат пумаласы омтыла да өскә,
Күк капусын ясый манчып яшел төскә.

Хан тирмәсе кебек түм-түгәрәк ак өй...
Кем соң ул төн ката шакый, шакый, шакый...

Яшел үләннәрем төренгәннәр акка...
Үлән җаны китә, ачылырмы капка?

# ХӘСРӘТ

Бу нинди дөнья булды соң?
Бу нинди... нинди... нинди...
Аның белән тураям дип,
Мин авыш булдым инде.

Кузгалганнан бирле юлга,
Җилләрен юллый...
ачы...
Кыйблага йөзне борырга
Хет бер җилкән булсачы.

Башны куеп җиргә – үксим,
Тып-тын авыл зираты.
Мин дә соң әллә җиһанга
«Ят яратылган»нар заты?

Гүргә иңдердем әтине,
Ләхет төбе алкын су...
Чайкалды да күк гөмбәзе,
Кымшанып куйды басу.

Күккә сикерде чыршылар.
Сабырлык бир, и Аллам!
Каләмем сары мәтегә,
Алкын суга буялган.

Бу нинди дөнья булды соң?
Бу нинди... нинди... нигә...
Язны алып киләсе җил
Кырда ак кәфен тегә.

Ташлыйлар туфрак кабергә.
Ә мин... мин үксим, үксим...
Нигә шундый мәрхәмәтсез,
Шундый гаделсез Күк син?

Әтием, кадерлем минем,
Алкын су аккан якта.
Саклармы урманнар исен
Өстендә имән такта...

Бу нинди дөнья булды соң?
Бу нинди... нинди... ничек...
Үлгәнче барыр озата
Язмышым – кара көчек.

Без дә яшәгән булабыз –
Хәсрәтле, гамьле Адәм!
Һәр мизгел афәт сагалый,
Көтә бер читтә матәм.

Кем юата алыр инде? –
Сузылам да ишектән,
Яр буендагы талларның
Сулкылдавын ишетәм.

*6 апрель, 1990*

## ЗИЯРӘТ

Килдем менә...
Беләм, беләм юкса
Зиратларда сагыш йогасын.
Кипкән үләннәргә сыенган да
Тын калган җил...
Кыла догасын.

Тыгыз һава иңнәремә баса,
Тубыктан ук иңәм, и Раббым!
Чабуына ябышам бу дөньяның,
Яраттым мин аны, яраттым.

Өянкеләр көянтәләр булып
Иеләләр.–
Татар холыгы...
Бугазымнан кайнар сумаладай
Акты төннең караңгылыгы!

Юксыну да зынҗыр сыман икән!
Кысты туфрак, кысты аягым...
Авыр төштән уяткан кук,
Миңа
Син кул суздың, дөнья.
Аядың.

Эзләп киттем сине гомер аша,
Зират каенындай якты син!
Бугазымнан кайнар сумаладай
Акты төн,
акты
төн...

## КАРА ТӘКӘ

Юллар ерак алып китсәләр дә,
Кайттым менә табып уңаен...
Өебез соң инә төшкән мәллә?
Юк,
Күк биегәйгән, мөгаен.

Оеп ятам берьялгызым гына
Әрем исе килгән чоланда.
Үз нигезем!
Рәхәт.
Тик нигәдер
Баш астында ястык чылана.

Түбәләрдән түбәләргә сикереп,
Кара тәкә чаба.
Мөгездән
Чаткы чәчрәп йөрәгемә төшә,
Мин шуңардан шигырь тергезәм.

Кеше икән күңеленә яшен
Туган нигезеннән эзләсен.
...Яңгыр ерып мин зиратка барам –
Яңгырларга кушыла күз яшем.

Тыйнак кабер.
Күзме томаланган –
Тоныкланган сыман ташы да...
Мин ышанмыйм...
Салмак атлап әтәй
Килеп чыгар кебек каршыма.

Югалдың, дип битәрләмәс ләкин,
Урап кайтам уйда көн саен.
Кабер генә менә иңгән бугай...
Юк!
Күк биегәйгән, мөгаен.

## КЫШКЫ ЮЛ

Йолдызлар шыгырдый олтанда.
Бу таңда
Мин кайтып җитәргә тиешмен,–
Ак карлар эчендә йортым бар,
Ә анда – үземнең нүешем.

Кар көрте сузыла каршыга.
Пар чыга
Өстәге бу мыштым толыптан.
Болыттан коелган да карлар,
Киредән менәргә оныткан.

Тукталам мин капка төбенә.
Күңелдә
Хисләрем икеле-микеле...
Туннарын җилбәгәй җибәреп,
Әтәем кар көри шикелле...

## СУ

Язмышым этте туфракка,
Уралдым мин туган якка...
Тамырларымны тик сакла,
Син, астан саркылган су!

Язмышым күккә тибәрде,
Гөмбәзгә башымны бәрде –
Чылатма тик керфекләрне,
Син, өстән саркылган су!

# АНА

Тәрәзәгә багып тып-тын гына
Ул күз яшен юрый йолдызлардан.
Йокысыз төн. Төпсез күк йөзендә
Аның күзләредәй ай кызарган.

Урамнарда өйсез җилләр йөри,
Өшеп куя ишек кашагасы.
Улын уйлый ана: нигә кайтмый,
Киеме бар микән, ашаргасы?

Бу изге сүз борынгыдан калган:
Туган нигезеңне онытмаска!
Безме соң ул истә тоталмаган...

Балаларга васыять, оныкларга!
Болытларга баккан әни тып-тын...
Ак каеннар кайный офыкларда.

# КИЧЕКТЕРЕЛГӘН СӘФӘР

Офыкларга уранып мин китәр идем!
Нигә алгысыта мине бу сәфәр?
Инешләргә иеләм дә юлны юрыйм –
Күрәннәре күзләремне кисәләр.

Күрәсезме – монда йөргән өрәкләр дә
Зәңгәрсу ай нурларыннан өртелгән...
Азга гына ваз кичсәм дә бу сагыштан,
Гөләпләрнең керфегенә төртеләм.

Китәр идем дәверләргә әверелеп!
Мине алгысыткан ачык ишектән...
Ләкин җирдән баш калкыткан үлән аша
Гөрләвекләр челтерәвен ишетәм.

Чәбәләнә бер кош куак арасында,
Ни кәтим мин канатланган куактан?
Дөнья минем бугазымнан кысып тотты,
Борчылма, дип, шул дөньяны юатам.

Гөмбәзләргә орынып, аһ, китәр идем!
Яфрак сыман коеп кеше сүзләрен.
Тик кем сөртер дымлы иреннәре белән
Офыкларда күз яшемнең эзләрен?

# ӨЗЕЛГӘН ДИСБЕДӘН

*(Кыска шигырьләр)*

## 1. Кендек

Минем юлым таңнан таңга кадәрле!
Чыгып киттем менә – көтә төнем.
Кендек өзеген кысып барам учыма,–
Мәңгелеккә ялганасым бар минем.

## 2. Төнге хыяллар

Тетрәнерме керфекләрем минем,
Ишетә алсам бу гөлләр исен?
Канатларын җилпеп оча йолдызлар,
Елмаю булып җиргә егылыр өчен.

## 3. Сукмак

Аһ, бу уртак йортның артык салкынлыгы,
Сулаганда бәс коела түшәмнән.
Беләм ләкин: мин китәсе ыртын сукмак
Сандугачлар тавышыннан түшәлгән.

## 4. Хәтер

Салкын туфрак ташлыйм менә тагын
Мине белгән кеше каберенә...
Бер-бер артлы танышларым үлә,
Мин дә үләм алар хәтерендә.

## 5. Үлем

Япь-яшь килеш китеп барды...
Йолдызларга эндәшәмен:
Теге дөнья – юк сүз булса,
Ни мәгънәсе бар яшәүнең?

## 6. Урыс зираты, татар кабере

Ылыс сата карт марҗалар һәр яз саен...
Куяргамы кабер ташына?
Янәшәдә көздән калган кәрлә каен
Сиздермичә саргылт яшь коя...

## 7. Көз

Көз җитүен мин, ниһаять,
төшендем:
ашыга-ашыга киенделәр кешеләр,
һәм агачлар акрын гына чишенде.

## 8.Гөнаһлар

Минем дә бар сул иңемдә фәрештә,
Фәрештә бит- намуслыдыр һәр эштә:
Язган, ахры, кирәкмәсен, кирәген,
Әледән үк авырсына йөрәгем.

## 9. Гомер

Шатлыктанмы тама яшем?
Кайгыданмы тама яшем? –
Беренче кат яшим җирдә!
Тик бит... соңгы тапкыр яшим...

## 10. Минем яшәвем

Җир тирәли ак күгәрченме әйләнә?
Әллә Җирме ак күгәрчен тирәли?
Нәрсә ул эз... Ак шәүләгә ияреп,
Хәл кадәре мин... йөгерәм әле.

## 11. Походта

Һаман борчый шул мәңгелек сорау:
Кеше сугыш өчен яралганмы?
Ике аяк белән бәрә җиргә,–
Әйтерсең Җир – поход барабаны.

## 12. Сугыш

Ул егылды окобына.
Йомылды күзләре
Үз окопларында.
Хәтта тезелеп төшкән
бомбалар да
үзләренә окоп эзләде.

## 13. Каралама

Ап-ак кәгазь.
Мин шигырьгә бүген
Күчермәкче идем ярамны...
Яздым-сыздым. Сыздым!
Кәгазь хәзер
Минем чырай кебек караңгы.

## 14. Иске Яңа ел

Сузылды да һаваларга
Озын нәфис куллар,
Яңа елның муенына
Коелды
Былтыргы кар.

## 15. Урам шәмаиле

«...Мин пар эзлим,
Кара чәчле булсын, озын буйлы...»
Белдерүләр белән тулы
Яшел такта янында,
Бөкре карчык турайган да
Иреннәрен
кыймылдата.

## 16. Бер дустымның портреты

Ә күзләре?
Соры күз карасы!
Бүреләр кебек – явыз ниятле...
Арт аякка чүккән,
Түгәрәктән
Сикерергә әзер гүяки.

## 17. Һәркемгә — үзенеке

Дөнья юкка чыкмый күзне йомып,
бөтен гәүдә гүли – дөнья эчтә.
Икәү генә җиргә сеңәр өчен
үз ширбәтен һәркем үзе эчә.

## 18. Шикле кеше

Нигә инде шикле карашларың?
Ни уйлыйсың син минем турыда?
Чәчәкләрнең бәрхет яфраклары
Чыланган бүген йолдыз нурына!

## 19. Күзәтүче

Кичер, язмыш: юл читенә тукталдым ич!
Һичбер кемне бу бәйгедә узмадым.
Максат, диеп күпме аксак юллар саба,
Ә мин тыңлыйм йөрәгемнең сызлавын.

## 20. Авылда

Китапларны куеп, башны тышка суздым
Пәрәвезләр сарган иске чоланнан.
Анда исә чык тамчылары җемелди,
Ә хыяллар күз яшенә чыланган.

## 21. Мәңгелек җиңелү

Шагыйрь белән чалпы* каршылыкта.
Дуэль дигән шушы атышта
Җирәбә гел көнлекчене сайлый,
отыш чыга һәрчак Дантеска.

## 22. Авырганда

Баш очында йолдыз түгел хәзер...
баш очында нәҗес чүлмәге,–
«Җиңелмим!» – дип баш калкыткан саен,
Җиңеләй, дип теләк теләде.

## 23. Яңа мәкаль

Юатса да теге мөһер
«Бар да уза» дип юкса,
Дошманның йөзенә төкер,
Аузың тулы кан булса.

## 24. Гайре

Чия чәчәге – таҗында
Өч бал кортын тирбәтте.
Язгы һавага саркылды
Сәер сөю сурәте.

* Чалпы – толпа, көтү.

## 25. Ау

Куабыз ла, әй куабыз дөньяны,
Кышкы урманда куган күк куянны.
Кул изи, ашыктыра еллар аша,
Һәм әҗәл кочак җәеп якынлаша.

## 26. Ниһаять

Таралса да таңда мәҗрух аңым,
Үз-үземә борылып карадым:
Күзге яңгыр кебек пычрандым мин,
Төнге кояш сыман каралдым.

## 27. Үрмәкүч

Чылана яңак. Яңарып
Пәрәвез йөзгә сылана.
Чалыма кемдер баш ия...
Яшь кызлар күзгә чалына.

## 28. Кысыр юаныч

Бернигә дә гаҗәпләнмим
Бу инкыйраз дәверендә:
Әдәбият бетчәләре
Байбәтчәгә әверелә.

## 29. Күзге тәэсир

Соңгы шигырь төсле саркып күздән
Күк йөзендә сыңар болыт йөзә...
Кулын изи, үзәкләрне өзә...
Ул да әмма эреп бетәр тиздән.

## 30. Парадокс

Буй үскән саен,
күк түбәнәя.
Яшь арткан саен,
яшь кызлар күбәя.

## 31. Яшерен сөю

Төнгә сулар агып керде,
көннең күзләренә
ярлар ишерелде.

## 32. Нәтиҗә

Толларның мендәре җылырак.

## 33. Өметсезлек

Дарда дару сорамыйлар
баш авырткannan.

## 34. Эңгер

Төренде сулар
сирень шәүләсенә.

## 35. Мәрхәмәт

«Иртә уянган юлдан уңа,
иртә өйләнгән улдан уңа».
Күктә ялгыз киек каз эзе!
Юлсызларга, улсызларга кул изә.

## 36. Элемтә

Диңгез авыр сулагандыр,
күлләвектә давыл купты.

## 37. Дәгъва

«Бездән соң да эз кала»,– дип,
көймәләр сөенә.

## 38. Шәһәрдә яз

Урам кырыйларында
кырыкмыш өянкеләр,–
Кояшның кытыршы учы
Сипкелне юмарт сипкән!

## 39. Төнге күк

Ыргыттым коега ыргак,
эзлим өзелгән чиләкне,–
тырткән саен йолдыз чиртә,
тик чиләк үзе эләкми.

## 40. Аерылу шатлыгы

Аерылабыз. Эзләрне җил ялый.
Таулар һаман бергә, иңгә-иң,
авыр сулап юлга карый алар...
Тау булырга, юк, мин теләмим.

## 41. Каһкаһә

Элек кемдер әйткән безнең хакта:
«Җиңеп булмас! Алар итекле...»
Татары-ыстан! Мәхлук илем бүген
Борынлаган чабата тикле.

## 42. Экология

Табигатьне кирәк сакларга, дип,
Күпме китап язды ул, исәр...
Ә кешеләр шуңа кәгазь өчен
Калын урманнарны кисәләр.

## 43. Өмет

Давыл үтте урман итәгеннән,
богыллар тузды,
агачлар сынды...
челтерәп көлде зәгыйфь үлән.

## 44. Яңа тарих

Коллар без – үзара хан булып кыланабыз,
Үзебез ятлардан телебезне теләнәбез.

## 45. Үзбәя

Кеше горур яңгырамый!
Ул – бары тик кеше генә...
Бик көлке бит- яңгыр тама
Синең борын тишегенә...

## 46. Тәмам камиллек

Тамак өчен җирдә көрәш бара...
Кемдер ачка үлә, кем ачыкмый...
Тик кабердә камилләшә кеше –
Ул ашамый инде, тышка чыкмый...

## ТУЗГАНАК

Безнең гомер – тузганак гомере,
Яшибез дә җилләр белән кочаклашабыз.
Һәм ашабыз һаваларга.
Гомерне булмый дәвалап.

Безнең гомер – тузганак гомере.

Мин һавага бүтәнчәрәк аштым!
Нәни кызчык – алты яшьләрендә.
Килде миңа бүген,
Кояш исе аңкый иде чәчләреннән.

Нәни кызчык килде миңа,
Сорамадым исемен, чыгышын...
Нәни кызчык килеп бакты миңа,
Кочакладым аның сулышын.

Безнең гомер – тузганак гомере.

## АНАТОМИЯ ТЕАТРЫНДА

Скелетлар тезелеп баскан.
Тагын...
Тынлык бар тагы!
Иң озынына төртеп күрсәттек –
Диделәр: ат карагы.

Күммәгәннәр. Сирәк экземпляр –
Тузаннарын сөртеп сакларлык.
Сөякләре күптән туфрак булган
Ул урлаган тулпар атларның.

# СӘРХУШ СӨЛӘЙМАННЫҢ МИҢА ӘЙТКӘН СҮЗЛӘРЕ

Вакыт – юк ул!
Кеше генә уйлап тапкан аны.
Без киләбез һәм китәбез.
Мәгънәсез эш – эзләү югалганны,
Китүчеләр кире кайтмый.
Мин сәгатьне күптән тәрәзәдән
атып бәрдем.
Чәлпәрәмә килде вак хыяллар.
Акча, дәрәҗәләр
хакында уй хәтта миндә булган...
Сәгать белән Вакыт төшенчәсе
очты.
Без ялгыз бит бу Галәмдә!
Моңа икән
тик берүзең калгач төшенәсе.
Вакыт – юк ул.
Тик сирәкләр генә
табигатьтән бүләк – канат ала,
Кояш килә, елмая да китә,–
Һәм көн саен шулай кабатлана.
Күршеләрнең тимер гаражыдай
тоела көн.
Рәхәт күршебезгә!
...Үзгәрәбез, дөрес. Ә Вакытны...
Ә Вакытны...
Ике кипкән кизләү эзе йөздә.

## ЗИРАТ КАРАВЫЛЧЫСЫ ТУРЫНДА

Түгә кеше күпме көчен,
Үзе кебек адәм каршында
Йөз суын түкмәс өчен.
Иректле булыр өчен, бәйсез булыр өчен!

Һәрбер колның иң бөек максаты нидә?
Иректле булсаң иде лә,
Һәм... Хуҗа булсаң иде!

Ләкин язмыш җиле өчен
Морҗадан чыккан төтен ич без, –
Иксез-чиксез гаскәр башлыгының аяк астында
ятарбыз
ахыр чиктә, бөтенебез.

## СОҢГЫ ЮЛ

Халык бик күп. Соңгы юлга
Озаталар аны.
Ул – зур кеше.
Кайсыдыр бер министрның замы.

Китә кеше.
Җавап-фәлән алырлармы баргач?
Гомерендә бер тапкыр да
Утыртмаган агач.

Халык бара. Катафалк.
Кем булса да – авыр...
Бюрократ юк табигатьтә,
Күтәп тора кабер.

Берәр каен утыртырлар –
Уңдырышлы җире...
Мәрхүм сулаган һаваны
Бирсен безгә кире!

## ТАҢДА ХУШЛАШУ

Зеңләп куйды пыялалар,
Атлар үтте, атлар үтте...
Кем ул анда таңнан торып,
Тәрәзәмә шәраб түкте?

Ник сарыла әле офык –
Иреннәре кемне күргән? –
Тәрәзәнең сулкылдавы
Соңгы сүрә төсле сүрән...

Өянкеләр шыбырдаша...
Таңнан торып кем ул икән,–
Калай табут тәрәзенә
Бу алсу гөлләрне сипкән?

Түшәмнәргә төшә шәүлә,
Идәннәргә ул түшәлә...
Түшкә кушырылган куллар...
Батынкы эз буш түшәктә...

# ТУЛГАК

Төн эчендә һичшиксез син инде.
Күренмисең, сиздермисең.
Әмма
Төн сискәнә –
Төпкелендә, димәк,
Төпкелендә синең җаның яна!

Ишетмисең, караңгыда, бәлки,
Адашкандыр инде зәгыйфь өнем.
Төн эчендә ләкин һичшиксез син,
Син! –
Илаһи хакыйкатем минем.

Тибенәсең төннең карынында,
Нәкъ тугыз ай яткан сабый төсле.
Шул нарасый сыман көчсез дә син,
Шул нарасый сыман бик тә көчле!

...Офыкларга кызыл кан җәелгән,
Төн-сылуның газиз, кызыл каны.
Ул сискәнә әнә, еш-еш сулый...
Соңгы тулгак тота бугай аны.

# ТИЛЕЛӘР ЙОРТЫНДА

Кумирлар юк монда!
Үзләре – Фәйзуллин, үзләре – Фөзули!
Егылган борынгы таш баба.
Йөзенә чәйнәлгән яфраклар
Төкереп ташланган,
төкереп ташланган.

Ниемә хаҗәт ди, зур дөнья?
Үзе бер гаҗәеп дөнья ул –
Илаһи сары йорт – таш кальга, –
тәрәзгә чәйнәлгән яфраклар
төкереп ташланган, берни дә күренми,
күренми.
Шундый җир, шундый җил, шундый көн,
шундый көз –
Шәп-шәрә чаганнар!
Кем анда галәмгә очмакчы?
Кем күкне төпсез, ди? Бу – ялган!
Зәңгәргә буялган гөмбәзгә
Чәйнәлгән яфраклар төкереп ташланган...

# ЮГЫЙСӘ

*Наис Гамбәргә*

Канатсыз кош әвеш-тәвеш,
Шул инде безнең яшәеш...
Ымсындырып җил исә.
Яңагымда кипмәде яшь,
Егылганга эт тә иптәш –
Торасы бар югыйсә...

Далада ут уйчан-уйчан...
Авып кала, төбен уйсаң –
Без шул кылган түгелме?
Бәгырьләргә басып үтә,
Әле үкенүне көтә,
Кисә көннәр гомерне.

Янә кошлар күтәрелә,–
Күздәге яшьне сөртергә
Сихри көч бар канатта.
Без елап дөньяга килдек,
Кара су булып түгелдек,–
Егылганга ук атма!

Умырткасы сынган чура
Көннең пәрдәсен ачарга
Беркайчан тора алмас.
Әмма ул егылган җирдә,
Минем бу көйгән бәгырьгә
Су тибәр дә – югалмас.

Ашыгырлар очар кошлар.
Тагын тараер куышлар,
Тамырларны су кисә!
Безнең күңелләр гел киңнәр,
Тик йөрәк кенә иңерәр:
Күтәрел, дип, югыйсә...

# БОГАУЛАНГАН БРУНО МОНОЛОГЫ

*Өстә Кояш – хаклык уты...*

Якынаям шуңа, күтәреләм,
Шул иманым минем, шул денем.
Күтәреләм йөзләренә басып
Гайбәтләрнең, өметсезлекнең.

Якынаям шул кояшка таба,
Шул кояштан булыр һәлакәтем.
Ул ярата алмый, дисәләр,
Ышанмагыз!
Шул кояшка минем мәхәббәтем.

...Һәм беркөнне мин югалсам күктә,
Күренмәсәм сезгә кичкә хәтле,
Таптамагыз җирдә җанын биргән,
Канатлары көйгән күбәләкне.
Төнлә кабат өстен калырмын мин
Барлык ваклыгыннан бу дөньяның –
Чәлпәрәмә, чәлпәрәмә килеп
Күккә сибелер җаным.

...Йолдызларга багып мәхзүн җанны
Төшерерсез искә,–
Галәм өчен яратылган затның
Кабере дә өстә!

# ЯЛГЫЗ ТОРНА

Аерма мине...
*С.Хәким*

Кемнәргә ошамый минем телем,
исемем?
Мин – торна.
Минем илем – моң.
Минем телем – моң.

Язмышым!
Шул моңнан аерма.
Мин – торна,
Мин очам һәм булмый туктап.
Кемнәр өчендер кара нокта...
Торыйк... торыйк!
Кычкырам.
Туктаталмас кебек һичкем, һичбер...

Авазымда минем мең мәгънәле төсмер.
Моң мин булып күккә ашкан,
Һәм мин капламыйм җирне кояштан.
Бөреләргә җитми бер сүз генә:
Торыйк...
Таң беленә.
Мин – торна.

Син, язмыш, аерма бу телдән.
Бу җирдән аерма...
Миңа бүген төшәргә җир кирәк,
Син миннән көчлерәк,
көчлерәк.
...Мин чылбырдан калдым өзелеп –
Ялгыз торна...
Ташлама, изгелек!

* * *

Җир әйләнә,
әйләнә Җир,
Җир әйләнә!
Тәндә эзе, карашымда эзе кала...
Мәңгелеккә килдем димә бу дөньяга,
Кем булсаң да
Югалырсың! Мин югалам, ул югала...
Әйләнә Җир, Җир әйләнә, әйләнә Җир.
Маңгаеңа төшеп калган эзе әнә.
Планетаның орбитасын эзләмә син!
Ул һәркайда... Иң кыйммәте –
Җир әйләнә! Җир әйләнә!
Тоялмасаң шушы хәрәкәтне,
Кулың сузма күккә ялкын сорап:
Торган саен кышлар эссе килә,
Торган саен җәйләр салкынрак.
Җир әйләнә,
Җир әйләнә, әйләнә Җир!
Офыктагы каенлыкта яз шәйләнә.
Кызык та булмасын ди дөнья...
Иң мөһиме –
Йөрәк тирәсендә җыр әйләнә.

# МАТӘМ

*(Поэма)*

Окину взглядом Север и Восток,
песчаную и ледяную сушу,
и не географический восторг,
а мысль прожжет мятущуюся душу, –
о том, что предки шли не торопясь,
осваивая реки и наречья,
не для того, чтоб износилась связь
полустальная, получеловечья.
Землепроходцам – исполать и честь,
и полководцам – исполать и память
за то, что нефть, и лес, и хлопок есть,
и есть простор, где оборону ставить.

*Станислав Куняев*

Төньякка һәм Шәрекъкә карыйм,
ком чүленә, боз диңгезенә,
сокланудан аһ итмәсәм дә,
бер горурлык балкый йөземдә, –
бабаларым ашыкмый барган,
үзләштереп телләр, суларны,
кешечә дә, корыч белән дә,
киселмәгән шуңа юллары.
Яугирләргә – мәңгелек шөһрәт,
батырларның данлыйк кылычын:
нефть тә бар, урман, мамык та,
һәм киңлек тә – сакланыр өчен.

*Станислав Куняев*

1

Сары торбалардан, җанны кыйнап,
Ниндидер бер ят көй ага... ага...
Зират каеннарын тибрәтә дә
Сузылып чыга ул авылга таба.
Туган җиремдәге шушы кабер
Мәңге төзәлмәс бер яра кебек –
Пуля тиеп егылгандай, авар

Армиядән үлеп кайткан егет.
Ул бабасы белән үскән иде,
Ятим иде – ялгыз куак гүя...
Бөтен афәтләрен иң беренче
Нигә язмыш ятимнәргә өя?

Әй син, көяз Мәскәү генералы!
Парижларда теккән мундир киеп,
Син сөйләмә безгә «бурычларны»,
Сискәндермә «дошман яный!» диеп.
Без сизәбез сезнең кем икәнне...
Аптырыйбыз: ни Чын, ни соң Ялган? –
Безнең патриотизм хисләренә
Әфган якларында нәрсә калган?

Илбасардан илен саклый икән,
Исем әзер аңа, димәк – дошман!
Баскыннардан җирен яклаганнар –
Басмачылар.
Кемдер шулай кушкан.
Нигә һаман чит илләрне яулап
Саклыйбыз соң туган илебезне?
Җуя-җуя юлда атыбызны,
Җуя-җуя туган телебезне...

...Япь-яшь кызый күз яшьләрен коя,
Башын бәрә-бәрә бусагага.
Хатын-кызның бәгыре шулай ката,
Күңелләре шулай усаллана.
Аның бүген шундый кара көне –
Сулыгып-сулыгып елый шул яшендә...
Шигыремнән мең мәртәбә авыр
Бу кызыйның сыңар күз яше дә...

Зират уртасында кан табыдай
Кала кабер, кала кәгазь гөлләр.

Онытыла ниндидер бер ят көй,
Комиссардан ишетелгән телмәр.

Контингентлар кайтыр туган илгә,
Континентлар җиңел сулап куяр.
Айшә исемле кыз ләкин мәңге
Шигыремә күз яшьләрен кояр...

2

Өстәл үзенә тарта аксакалны,
Ният тарта, ният – зурайды:
Телдән телгә күчсен, илдән илгә,
Набат булып суксын бу кайгы.
Язылганны балта юна алмый,
Төрмә көчсез аның янында.
Бәет яза шуңа төнката карт,
Онытының манып канына:
«Тарих мең дә тугыз йөз дә
Сиксән бернең язында,
Күз яшьләренә чыланып
Бу хикәят языла».
Әюп картның тәүге бәете бу,
Соңгы бәет инде, төшенә.
Бик зур кайгы этәрде шул аны
Беренче кат иҗат эшенә.
Ә күзләре – бизмән чокырлары.
Мөлдерәмә тигез кайгысы.
Чайпала да тама ак кәгазьгә –
Ярап тора әле анысы...
Шылт итсә дә бәет чыгарганнар,
Чоры шундый булган. Ә монда
Онытын бер цинк табутка салып
Кайтарганнар туган ягына.
Батырларча үлгән, диләр менә...
Шулайдыр, ул – Әюп каныннан!

Ләкин нигә, нигә? Башка сыймый:
Ник әҗәл нәкъ аңа кагылган?

Узган сугыш каһарманы бу карт.
Булмый әле һаман онытып.
Кырык елга якын тынычлыкта
Нигә табут? Нигә оныгы?
Кызлар кулын тотмаган да иде.
Дошман әнә тоткан да утка,
Туган ягына ул юлга чыккан,
Юлга чыккан цинк табутта.

Яз бәетең, әйдә, Әюп бабай,
Кемдер аны укып елар да,
Искә алыр ерактагы улын,
Һәм мәрхәмәт сорар еллардан.

3

«Нинди сугыш?
Нинди Әфганстан?
Тукта тизрәк дөнья болгатудан! –
Сәвит Миннәт миңа төкрек чәчә: –
Сезнең нәсел болгатырга туган».

Көрмәкләнә бераз гына теле,
Чырай – кызыл, гәүдә шактый авыш.
«Онытма,– ди,– бабаң Зәйдулланы,
Шул көн котә сине, пынимаеш!
Кычкырдылар теге вакытта да,
Ирек, диеп, хөрлек, фәлән-төгән...
Ну, без инде хөрдек, канишныжы,
Матрас тектек кызыл әләменнән.

Чүпрәк житә –
Сәвит өстендә дә

Җилфердәде исерек тукымалар.
Контрларның оныклары хәзер
Хаклык эзләп җанда тукыналар.
Син дә артык сикеренмә, туган,
Дилбегәне бераз бушатудан
Ни үзгәрә? Тәртәсе бит имән!
Дуласаң да тәртәсенә тимә...
Яшәп булмый җир йөзендә ансыз:
Тәртә – тәртип, алар бер тамырдан.
Сталинның корыч кулы кирәк,
Сталинны
сагынып
мин каңгырам...»

Миннәт үлгән, беләм.
Ләкин бүген
Рух,
Сүз ирке, имеш.
Шуңа әнә
Йөзен әләм кебек җилфердәтеп,
Ул дөньяга калкып чыга янә.
Даһиларның күләгәсе кебек,
Елмаюын төреп мыегына,
Безнең арттан килә.
Форсат җиткәч,
Иңсәбезгә сугар кыю гына.

Ә мине ул таный.
Карый шүрләп
Корбанының нәсел-нәсәбенә:
«Бабаң кем?» – дип, анкеталар суза,
Шикле караш ташлый мәсләгемә.
Төкрек чәчә менә:
«Пыр-паганда!
Ни сөлисең анда, нинди афәт?
Һәлак булмаган бит мескен солдат,

Үлгән бары,
вафат булган, вафат!»

Цинк табут җиргә иңә бүген,
Мөхәммәтне алып үзе белән...
Алып батыр түгел,
Япь-яшь малай...
Чит...
җирләрдә...
гомере...
өзелгән...

4

Өч нокталар кәгазь өстенә
Күз яшьләре кебек түгелде...
Иртәгәге, кичәге түгел,
Кайгы шул ул – мәңге бүгенге.
Ярага тоз салма, дисезме?
Сугыш инде хәзер узган эш?..
Анысы шулай.
Тик яшь гомергә
Нокта кую минә кызганыч.
Шуңа, ахры, өч нокталар күп
Бүген минем кәгазь өстендә:
Сөрлегәм дә тагын кузгалам –
Яшьтәшләрем төшә исемә.
Күтәрелә һөҗүмгә алар.
Командирның кырыс авазы
Алга куа. Йөрәк урынында
Тибә бугай приказ кәгазе.
Экран буйлап чаба шәүләләр...
Нигә минем күзгә чалына соң
Кыядагы бер чалмалы баш?
Болытларга тигән чалмасы.
Мең биш йөз дә илле икенче
Елның шыксыз кара көзендә

Саклаган күк Казан каласын,
Гаҗизлек бар аның йөзендә.
Кулын суза ярдәм сорап ул
Мөхәммәттән, күктән, Алладан.
Туганнарын сугыш үтергән,
Калаларын ялкын ялмаган.

Ә Мөхәммәт автомат алып
Төби аңа.
Сугыш – шобага...
Аккорд булып яңгырый залп
Төгәлләнми калган догага.

5

Хәрби советтан соң патша аңа тоткарланырга боерды.

– Без сиңа зур ышаныч күрсәттек, Шегали,– диде Иван, мыскыллы елмаеп.– Син канәгатьме?

Шаһгали, карашын идәнгә төбәп, түбәнчелек белән башын иде.

– Сезне Алла рәхим-шәфкатеннән ташламасын, галиҗәнап...

Иван ашыкмыйча гына сүзен дәвам итте:

– Син Казанга иң башта һөҗүм итүче яуның башында булачаксың, чирүең ышанычлымы, шыр җибәрмәсме?

– Һич юк, галиҗәнап, яугирләремнең барысы да кыю, аларны берни туктаталмас! – Шаһгали янә башын иде.– Безгә күнегәсе түгел, без һәрвакыт алгы сафта сугышабыз.– Аның тавышында горурлык төсмерләре сизелеп алды.– Казанда нинди ганимәт кулга төшәсен барыбыз да яхшы беләбит... Алып булса...

Иван тәхетеннән сикереп торды, арлы-бирле тыз-быз йөренә башлады.

– Алырбыз! – дип акырды.– Күрәзәчеләр әйтте: Казанның көне санаулы.

Шаһгалинең ирен читләре тартышып куйды. Шайтанымамы күрәзә? Шундый көч белән дә янә алып булмаса ул каһәр төш-

кән шәһәрне, хатын-кыз көлмәге генә киясе кала инде. Ә казанлыларның булыр-булмас илле мең гаскәре бардыр. Соңгы тапкыр хан булып торганда, дарыларына да су салып китте ич ул. Казанның көчсезләнүе өчен турыдан-туры Шаһгалигә бурычлы Иван. Хәер, нәрсә белә соң сугыш эшендә бу маңка? – Казан халкына булган нәфрәте Шаһгалинең йөрәген кысып куйды. Өч тапкыр куып җибәрделәр бит... Югыйсә тычкак Мамай каны катнашкан шушы малай каршында баш иеп торыр идемени ул... Ул – бөек Чыңгыз нәселеннән булган Шаһгали бине Аллаһияр!

Ә бәлки... дүртенче кат урнашып калып булыр?

Иван тынычланган иде, кире тәхетенә барып утырды.

– Ханбикәнең хәле ничек? – дип сорады ул, карлыккан тавыш белән.

– Аллага шөкер, галиҗәнап,– диде Шаһгали. Үзенең күз алдына Сөембикәнең кара янган йөзе килеп басты. Кирмәнгә алып кайта алса да, йөрәген яулый алмады ул аның.

– Казанның диварлары биек,– дип, тагын иске эзгә төште патша.– Яугирләрең сынатмасмы, Шегали? Ни әйтсәң дә, дин бер, тел бер, кан бер дигәндәй... Укларның юнәлеше үзгәрмәсме?

Шаһгали акрын гына көлеп куйды. «Безнең кавемне белми икән әле бу...» дип уйлады ул.

– Малның нәселе юк...– Аның күзләреннән идәнгә кара чаткылар чәчрәде.– Этләрең мал исен сизделәр инде, галиҗәнап...

Шаһгалинең сүзләре Иванның күңеленә хуш килде.

– Син минем иң яхшы этем, Шегали,– диде ул, кулын өскә күтәреп. Бу – китәргә мөмкин дигән сүз иде.

– Алла сезне рәхим-шәфкатеннән ташламасын, галиҗәнап,– дип, тагын кабатлады Шаһгали һәм башын иеп ишеккә таба юнәлде.

Иван күз карашын аның шәлперәйгән колакларыннан ат яурыны кочакларга күнеккән кәкре аякларына күчерде. Авыр ишекләр акрын гына ябылгач, йөзен чытып идәнгә төкерде. Гүзәл Сөембикә пармы соң инде бу хайванга, дип уйлады ул...

## 6

«Көннәр озын. Гомер озын
кебек биредә.
Исә җилләр – истәлекләр
җанда терелә».–
Бер хатыңда шундый сүзләр
иде шикелле.
Бүген алар күңелемә
тиде шикелле.
Исте җилләр, истәлекләр
килде, чорнады.
Айкап чыкты шигырь уты
еллар-чорларны.
Ләкин бер көн күз алдында
тора да тора.
Керфекләр күләгәле дә
тагын яктыра.
Аның соңгы киче иде
туган өендә,
иясез уйнады гармун
авыл көенә.
Иптәшләре ашый-эчте,
иркен табыны.
Сагынып ул бу кичәне,
бик тә сагынып.
Әюп картка моңсу иде,
сизә, ахыры...
Ни язгандыр... Инде яхшы
бетсен ахыры.
Намаз саен юкса һәр көн
син теләк телә:
Хезмәт итәсе урыны
булсын дип илдә.
Кайтты да менә оныгы
бераз елмайды:

Миңа – Кабул. Синең теләк
кабул булмады.
«Без китәбез, сез каласыз» –
җырлар җырланды.
Әюп бабай да авызын
йомып тормады.
Кыстап алды: «Сөйләшегез
берсәк салып сез...
Яуда, агай-эне, булмый
безнең халыксыз:
Түгел беренче мәртәбә,
үзем мин менә
Үлми-нитми генә барып
җиттем Берлинга.
Минем бабайның бабасы
Парижны алган,
Бонапартның яңагында
уч эзе калган».
«Гололобый» малайларга
бу сүз хуш килде.
Ант иттеләр, без дә, диеп,
сакларбыз илне!

Озата чыкты Мөхәммәт
дусларын тышка...
Хушлашты.
Күз яшен егет
агызмас бушка.
Кем ул әнә тып-тын гына
почмакка поскан?
Бу – бергә китәсе дусты...
Күңелен коскан.
Авыртыр башы. Төзәтмәс.
Болай да төзек.
Мазар-и-Шәрифтә аны
алырлар өзеп.

Талпыныр җәеп кулларын,
гүя очар кош
омтыла туган җиренә!
Һәм иңри:
Хуш!
Хуш...

7

йолдызлар монда ничектер эрерәк
өрәкләр озынрак һәм нәзек
көн саен алар ничектер буйга үсә
беләзекләрендә җирнең орбитасы
аларга бу якта күңелсез түгел
шуңамы шаркылдап көләләр кайчакта
сискәнәләр дә сәясәт кемсәләре
һәм таш төшеп китә тау башына җиткәч
һәркем үз илен сагына
үлем күргән күңел нечкә була гаҗәп
дөнья яулый
урыс малае владимир
мөхәммәт
таҗик турсун
кырым татары әмәт
курыкмыйлар чалмалылар чалуыннан
өрәкләрдән өрекмиләр диеп булмый
тик кайвакыт моңсу булып китә
каен яфрагын куясы килә йөрәк турына
уяу алар уяныргa кирәк түгел
тегеләр бит төбәлгән ди бу төбәккә
океан аша дәгъва итәләр икән
бу ил безнең
тормыш интересларының сферасы диеп
дошман һөҗүмгә ташлана
телләрендә алла
мөхәммәт өммәте

мөхәммәтнең автоматы кыза
өммәте юк өмете генә исән
россия ул һәрчак тынычлык тели
һәм саклана алга бара-бара
соңгы сулыш
шәһит киткәннәргә соңгы
соңгы сугыш башланмаска тиеш
йолдызлар монда ничектер эрерәк
өрәкләр озынрак һәм нәзек
лепкәләре эләгә гөмбәзгә
йолдызлар җиргә коела гүли-гүли
күтәрелә мәңгелек тузан

## 8

*Мөхәммәтнең көндәлегендәге сөйгән кызына атап язылган юллар*

Сезнең турда басып тордык...
Ни турында сөйләштек без?
Истә дә юк. Сезнең тур ул
Мәхәббәттә безнең «ликбез».

Иң кирәк сүз иреннәрдә
Кипшенгәндер, дым көткәндер...
Безнең өчен җир йөзендә
Соңгы дошман дөмеккәндер...

Җилләр исте арабыздан,
Орынды кошлар канаты.
Дәррәү яфрак ярды каен,
Һәрбер яфрак – сәлам хаты...

Көтәрсеңме мине, дидем.
Карашым белән кагылдым.
Моңсуланып синең күзләр
Керфекләреңне ябынды.

Кем китмәгән, кем кайтмаган?! –
Безгә бит ул уен гына...
Син кульяулык суздың шулчак
Кыенсына-кыенсына.

Тиз генә алып яшердем.
Бөркелде күңелем эченә
Хушбуй исе белән бергә
Синең тәнеңнең исе дә...

Күтәрсеңме мине, дидем.
Кабатладым ахмак сыман.
Дәррәү яфраклар коелды –
Пышылдадың: «Вәгъдә-иман...»

9

Мөхәммәтнең автоматы тынды.
Тау кымшанып куйды:
«Дөмекте!»
Кояш – шул ук.
Җир дә...
Татар ята –
Өммәте юк...
Сүнгән өмете.
Тор син, батыр, тор, яшьтәшем минем!
Әнә дошман, әнә үрмәли.
Ә Мөхәммәт берни ишетмәде!
Ә Мөхәммәт берни күрмәде!

Дерелдиләр бераз керфекләре.
Исән икән, шөкер.
Тор инде!
Туган якның дымлы болытлары
Юешләсен канлы иренне.
Ерагая туплар гөрелтесе,

Тынлык били якын-тирәне.
Ә Мөхәммәт берни ишетмәде!
Ә Мөхәммәт берни күрмәде!

Күкне тере керфекләрең белән!
Ава...
Авыр, гүя кургашын.
Күк астында, чит-ят күк астында
Сытылдың син, дустым-чордашым!
Тор, син, батыр, тор, яшьтәшем минем.
Исән килеш җырга кер әле!
Ә Мөхәммәт берни ишетмәде...
Ә Мөхәммәт берни күрмәде...

## 10

Озын-озак гыйбадәттән соң, князь Всеволод кятибен чакырып алды. Кятиб ишектән ничектер яны белән керде, тиз генә килеп өстәлгә каурый каләмен куйды, суларга да куркып хуҗасының йөзенә текәлде. Князьнең кәефе юк икәнен ул ишеткән иде инде. Соңгы арада аның кәефе юк шул. Халык хәерче – эшләмәгәч ничек бай булсын? – дружинага түләргә акча юк...

Димәк, яу, яу, яу!

Ганимәт мал Владимир иленең эшләрен җайга салыр, шөһрәтен тагын да өскә күтәрер.

Князь майланган озын чәчләрен артка сыпырып куйды, шешенке күз кабакларын иренеп кенә күтәреп кятибенә карап алды, алдындагы сыра чүлмәген читкә этәрде. Мәгәр сүз башларга ашыкмады.

Болгарларны җиңү җиңел булмас.

Җиңәрбез.

Ач бүренең ачуы яман...

Болгарлар сугыш белән бик мавыкмый, алар сәүдә итә, монда да туар ишләре күп... Князь үз сәүдәгәрләренең дә сугышка каршы булуын искә төшерде, җирән төкләр баскан дәү йодрыгын йомарлады. Урыс сәүдә итә беләмени?! Урыс – сугышчы!

Яугир! Сугыш булмый торса, эчкегә бирелә ул. Менә болгарларның умырткасын сындырыйк әле. Кан кирәк, яңа кан кирәк урыска! Югыйсә тамырлардан аракы ага башлады. Добрыня баһадир кебек борылып китмәбез, итекләрен салдырырбыз, җирләрен воеводаларга өләшербез, чабатага калыр болгар!

Тик кыпчаклар килмәде, каһәр. Алар да булышса, болгарларның көлен бөтенләй күккә очыра идек...

Князь кипшенгән иреннәрен сыра белән чылатып алды.

Ә бит төркиләр мәңге бер-берсе белән алышырга яратты. Аларның бит һәрберсе үзе генә өстен калырга тырыша. Бу юлы Хан нигәдер киреләнде: «Без бер халык, бер-беребезнең канын кою – язык»,– дигән була, мөртәт. Басурманнар! Димәк, кыпчаклар да Магометка табына башлаган.

А-а, хәйләкәр Хан, бер халык, язык-фәлән, дип маташа, князьнең казнасы бушаганын сизгән ул. Җиткергәннәр...

– Яз! – дип боерды князь.– Хөрмәтле туганым – Бөек князь Святослав!

Тик нәрсә язарга? Болгарларга каршы барырга кыпчак ханы риза булмады, дипме? Үтенечемә төкерде, дип акланыргамы? Святослав миннән кычкырып көләчәк бит, бөтен Киев көләчәк...

– Кыпчакларны чакырырга теләмим,– дип, хатын дәвам итте ул.– Аларның нәселләре дә, телләре дә бер үк.

Төркиләрнең бер-берсенә
кылыч күтәрергә баш тартуын
тарих шулай хәтерли.
Шуңа күрә бу гайре табигый вакыйганың
төгәл елы да билгеле –
милади белән 1183 санә.

## 11

Цинк табут иңә...
Кем соң анда?
Бу турыда сүзне башламам.
Мәшрикътан мәгърипкәчә җирләр
Безнең халык белән ашланган.

Ыргылганнар яуга җайдагатлар,
Татар аты – затлы,
әшәке...
Таратканнар сөңге очларында
«Урыс коралы»ның дәһшәтен.
Үз атына мәхәббәтле халык
Ят дан хакына яуга атылган.
Көенә белгән Сөембикә өчен,
Һәм Шаһгали кебек сатылган.

Эзләр белән чуарланган дөнья.
Тузан сарган. Әмма ап-анык –
Бу эзләрне бабаларым салган,
Таныйм бабаларым табанын.

Мәшрикътан мәгърипкәчә җирдә
Шул ук эзләр, шул ук – охшаган.
Ул эзләрне мин Польшада күрдем,
Яңа хисләр кайтты Польшадан.

Ят төбәккә алып китте «фиат».
Ят ук түгел бугай бу юлы.
Чатта торган такта юл күрсәтте
Алга...
Анда – «Татар авылы».

Магистрның калын муенына
Туган морза аткан аркандай
Суырып алды чорлар.
Кан, кан тартты –
Ниндидер бер магнит бар канда.

Җиде-сигез татар калган, имеш.
Даны белән миңа ят алар –
Тевтоннарның тимер когортасын
Ботарлап бук иткән татарлар.

Яхшы беләм: су үзгәрсә әгәр,
Тел үзгәрә, холык үзгәрә...
Нидер кала икән...
Таныш төсмер
Киң тупсалы йөздә, күзләрдә...
Талпынды уй –
Галиҗәнап Тарих
Туктамышта туктап калгандыр.
Бу хыяллар чындыр әле, баксаң,
Ә чынбарлык үзе ялгандыр?

– Исәнмесез! – дидем бер бабайга.
Карашында өркү, шик иде.
Җиргә килеп төште минем сәлам
Ук эләккән шоңкар шикелле.
СССРны уйлап чыгып киттем
Манарасы биек мәчеттән.
Күзләремне дым элпәсе япты,
Иренемдә калды әче тәм.
«Мөхәммәде...» – диеп сузды мәзин,
Бу исемнең көче әле бар...
Каравылчы Али дога кылды,
Монда да күп икән Алилар.
Үзебезчә бер сүз әйт әле син! –
Тәкрарлап бер җырлар язарлык.
Онытылган,
үлгән,
корыган тел...
Бер сүз калган – мазар.
Мазарлык...

Үз атына мәхәббәтле халык
Ят дан хакына яуга ялланган.
Идел кичкән үчен кылыч итеп,
Тик чорларны кичә алмаган.

## 12

*Мөхәммәтнең көндәлегендәге үзе өчен язылган юллар*

«Олтаныңда туган җир җылысы!
Юнәлсәң дә кайсы якларга,
Син баскан төш, димәк, татар җире,
Туры килер аны якларга».

Минем сүзләр түгел, бабайныкы.
Бабасыннан күчкән аңа да...
Ахры, алар мондый сәфәрләрне
Егетлеккә, данга санаган.

Урта гасырлардан килгән сүзгә
Мөнәсәбәт анык, билгеле...
Ләкин көрәш – һәр чорда да көрәш,
Син мәйданда – бирмә биләңне!

Дөнья монда – мөлдерәмә касә.
Мөлдерәмә... Вакыт аңларга:
Кем язмышы канга әверелер –
Соңгы тамчы булып тамарга?

Сәер сугыш бара, соңгы сугыш...
Син солдат тик – гамәл аклана.
Ут яңгыры.
Аеру да кыен –
Кем яу чаба, ә кем саклана.

«Йөрәгеңдә туган җир җылысы!
Юнәлсәң дә кайсы якларга,
Син ауган төш, димәк, татар җире,
Туры килер шунда йокларга».

Тик җир килешмәсә кеше белән?
Таш шикелле монда җир – каты.
Безнең җир ул бары – без күчәсе
Тыйнак, моңсу татар зираты...

Бу яклар ят безгә.
Кояшы да
Мунча миче булып торырлык.
Тауларында безнең күңелләргә
Аңлашылмый торган горурлык.

Шуңа миндә нәфрәт.
Һәм курку да...
Яшеренгән анда дошманым.
Кем әмерен, белмим, үтидер ул,
Ә мин командирым кушканны.

Ә кушканны үти беләбез без!
Шуңа күрә БАСКАН җиремнән
Мин чигенмәм!
Һәрбер ташы аның
Безнең җаныбызга төренгән.

## 13

Кем килде исә җиһанга, шик юк ки, китәр...
*Сәйф Сараи*

Үзгәрмәс хакыйкать белән кеше килешергә мәҗбүр. Алтын Урда дәүләте заманында яшәгән борынгы шагыйребезнең бу юллары дөнья беткәнче мәңгелек турында уйларга этәрер...

Җиһанга һәркем бертөсле килә. Ләкин һәрберсе үзенчә яши, үзенчә китә. Ни рәвешле китә? – юкка гына шушы сорау меңнәрчә шагыйрьләрнең күңелен бимазаламагандыр...

Солдат чит дәүләттә батырларча һәлак булды. Тик ни өчен? Ни хакына?

Йөзләрчә татар егете әфган туфрагына башын салды.

Кем җибәрде аларны анда?

Һәр халыкның язмышы үз кулында булырга тиеш.

Язмыш атының йөгәне кем кулында, атның язмышы да шуның кулында.

Бер иярдә ике җайдак була алмый. Иртәме-соңмы аның берсе егылып калырга тиеш. Чәрдәкләнгән башын акрын гына тарих тузаны күмәр...

Асылда, бу дөньяда бар нәрсә дә вакытлы. Яралар төзәлә, кайгылар басыла.

Әюп бабай, оныгының үлеменнән соң тагын да бөкрәя төшсә дә, сау-сәламәт кенә йөри әле. Дөрес, ул хәзер үзалдына нидер сөйләнеп йөри, күзләре дә моңсурак, әллә еллар элпәсе каплаганга гына шулай моңсу тоеламы? Еш кына ул эшләпәсен алдын артка кия, кайчакта ыштанын төймәләргә оныта. Сәер гадәте дә бар: тик торганда «идрит-кудрит!» дип кычкыра да, офыкка карап, кемгәдер йодрык болгый.

Ә офыклар һаман алсу...

Айшә исемле кыз шәһәргә эшкә киткәннән соң озак тормады – урыс егетенә кияүгә чыкты. Инде малае йөгереп йөри, диләр. Аңа Володя дип исем кушканнар, имеш. Владимир Ильич Ленин истәлегенә...

Сулар ага, ага... Күкләр авырлыгыннан каберләр иңә. Җир бирә, җир ала. Гомер – бер уемнан бер уемга уй тизлегендә сикерү генә...

Мөхәммәтнең дә исемен сирәк телгә алалар хәзер. Хәер, Павлик Морозов исемендәге дружинаның яшь пионерлары үз отрядларына Мөхәммәт исемен алу өчен ярыш башлаганнар дип, район газетасында пионервожатыйның хәбәре басылып чыккан иде, ни белән беткәндер, авторга мәгълүм түгел.

Мин шуны беләм: кәҗәсенә печән сорап баргач, авыл советы рәисе Әюп бабайдан Мөхәммәтнең Әфганстанда һәлак булуы хакында белешмә китерүен таләп иткән: «Бәлки, ул малай анда үпкәсенә салкын тиеп кәңкәйгәндер?..»

«Бездә шундый закун! –
Галстугын
Төзәткәләп куйды Миннәтев: –
Безнең алда юньле кәгазь булсын,
Справка китер юнәтеп...»

Бу соң әллә сәвит Миннәтенең
Оныгымы? – бигрәк охшаган.
Күзне шүрләтерлек шәрә җанын
Яхшы кәчтүн белән тышлаган.

Алар барсы бер нәселдән ләса! –
Мәңге-мәңге бетмәс бер токым
Илне киләчәккә өнди һаман,
Каплаштырып бераз ертыгын.

Утыра менә иркен бүлмәсендә,
Белә кулның кулны юганны...
Тагын кая юллар авылдашын –
Кайсы яуга? – «өлкән туганы».

Миннәтевме, әллә Шаһгалиев? –
Йөзе бер үк аның, асылда:
Үгез үлсә – аңа калҗа бары,
утын була – арба ватылса.

Мөхәммәтең-ниең аңа нәрсә?
Ул матдәгә бары ышанган.
Рух ят аңа...
Ул Рух безнең аңда
Котылырга тели тышаудан.

## 14

Ни газизрәк – бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкатдәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр?
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!

*Дәрдемәнд*

Минем сүзем үләннән дә түбән.
Мин пышылдыйм, алар шыбырдаша.
Тамырлары буйлап аска саркыйм –
Аралашам гади шигырь аша
Чорлар белән...
Чорнап ала мине
Әллә кайчан онытылган зарлар –
Калкулыклар тауга әверелә,
Бер-береннән ерагая ярлар.
Пәрдә кебек күтәрелә офык –
Сәхнәләргә безне дәшә мәллә?
Белмиме ул – ат уйнатып булмый
Үләннәрдән түбән яшәгәндә.

Буразнада күзе алашаның,
Кемнәрнеңдер нигә талашканын
Ишетми дә...
Уе аның олы:
Ул камчыдан өркә,
көтә солы...

Тик җыенмыйм гаепләргә аны:
Кымшандым да бераз буразнадан,
Казна эше кире җиргә кысты,
Калкынырга, ахры – юк, язмаган...

Хәтерләтә җирем язгы таңда
Ашъяулыкны... Матур чигелеше.

Буразналар сала безнең халык,
Межа салмый дәүләт чиге өчен.
Чиктә түгел һич тә илнең көче,
Чиксезлектә – кодрәт.
Чикләнмибез.
Галәм ирене тигән туфрактан без –
Шуңа күктән йолдыз чүпләмибез.

Минем сүзем тын сулардан да тын.
Бу күз яше гүя соңгы балык,
Мәрхәмәтне көтеп читкә чәчри? –
Сеңдералмас аны чиккән яулык.
И син, сүзем,– тын сулардан да тын,
Ник җанымда табалмыйсың урын? –
Оран булып түгел, бер гамь булып
Колаклардан колакларга орын.

...Кидергән чак булды җырга зынҗыр,
Чигәләрдән үткәрделәр чикне.
Тик Иманны җанда саклап,
Барыбер
Илтәчәкбез киләчәккә тикле.

Иләмәннең биләмәсе бүген –
Туган тел ул!
Менә минем Ватан.
Соңгы көне булып сүреләм дә,
Өр-яңадан таңы булып атам.

Ә тегермән исән...
Таш әйләнә...
Кемгә тагын, кемгә, кемгә матәм?
Бичаралык...
Мин дә менә хәзер
Дон-Кихотны, бәлки, хәтерләтәм.

Кайда соң юл?
Кем юлбашчы бүген?
Йөрәкләргә сукмак кайдан уза?
Бармак яный һаман, уяна да,
Колымада кол биләгән Хуҗа.

Үз язмышын башка халыкларга
Тапшырган да
татар –
мескен кавем,
Тыңлап ята хәзер хуҗаларның
Үз исеменә матәм уйнауларын.

Җилләр исә. Диләр: Үзгәрешкә!
Һәр җил арттыра тик канат көчен...
Коммунизм язар бу тегермән
Безнең канга манып канат очын.

Кайда соң юл?
Эзлим юлбашчыны...
Исән-имин ярга чыгарырлык.
Көчләп җиккән имән тәртәләрдән
Мескен алашаны тугарырлык.

Без кем белән бүген ярашабыз?
Без кем белән тагын талашабыз?
Кайчан сикерер җиргә толпар булып
Йөрәктәге мәхлук алашабыз?

Кидерсә дә дошман җырга зынҗыр,
Чигәләрдән үткәрсә дә чикне,
Безгә тигән өлеш – бу Иманны
Илтешергә киләчәккә тикле.

Шигырь юлым – бал кортының юлы.
Мин бал эзлим җаны хәстәләргә.

Әгәр чаксам – ул да дәва өчен,
Соңгы юлга сезне хәстәрләргә.

Кыяматкә кадәр эзлим мин юл!
Сездә әллә кайчан җуелганны...
Җуелса да фани чырайларда,
Язмыш тактасына уелганны.

Эзлим мин юл.
Йөрәкләрдән эзлим –
Табарбызмы кыяматкә хәтле
Мөхәммәтне – димәк, мәхәббәтне,
Мөхәммәтне – димәк, мәрхәмәтне.

*1987–1990*

## ЧИШМӘ

*(Риваять)*

Төн караңгысын ертып,
Кояш көнне чакыра.
Эссе нурларга коена
Иксез-чиксез сахра.

Арган-талган юлчы атлый,
Хәлдән тайган тәмам.
Кара тир тама маңгайдан,
Һәм ком кыза яман.

Ничә чакрым үткән аяк
Сызлый шундый, йончый.
Авыз кибә, сусызлыктан
Газаплана юлчы...

Кинәт!
Иксез-чиксез чүлнең
Шул тынлыгын ярып,
Җир астындагы ташларның
Салкынлыгын алып,

Агып чыккан бер чишмәнең
Челтери көмеш суы.
Өмет белән мосафирның
Сузыла ике кулы.

Тезләнә – гүя сәҗдәдә...
Калдым, диеп, исән,
Сузыла ул. Ә анда
Тик ком җиле исә.

...Соңгы тамчы күз яшьләре
Комга агып төшә.
Иксез-чиксез ком чүлендә
Шул – бердәнбер чишмә...

## ӘРЕКМӘН

Монда берни үзгәрмәгән. Быел да
Тавыш-тынсыз гына алма коела.

Ә йолдызлар элеккечә күк тулы,–
Иренемә тамар сыман сытылып.

Кинәт яңгыр тамчылары сибелде...
Пешкәк сусап тапкан сыман гөбене,

Кымыз исе таралды ич тирәгә! –
Эт эчәге кебек җирдә сөйрәлә.

Манзарасы булса да шул ятышлы,
Һәрни пышылдый төсле: син – ят кеше.

Ник сузыла шул чагында ярыктан
Бу – тузанга баткан уйчан әрекмән?

Мин иеләм, аның белән кавышам,
Җир астыннан ишетелә алкышлар...

# НОСТАЛЬГИЯ

Салкын тынлык. Шуыша кардан кара шәүләм;
Гүя каләм, ап-ак кәгазь өстендәге.
Бу дөньяда япа-ялгыз калганда да
Мин барыбер кемнәрдәндер өстен әле.

Искән җилдә мин очырдым мескенлекне...
Бездән башка да ул табар үзенә ишләр.
Сөенергә генә. Көенсеннәр әйдә
Шушы гүзәллекне төшенмәгән кешеләр.

Дошманнардан читтә, дуслардан да читтә,
Беркем озатмаган һәм беркем дә көтми.
Барам иркенәеп – дөнья берүземә.
Ләкин нидер җитми, белмим, нидер җитми.

# САТАШКАН КЫШ

Яз кояшы – декабрьдә,
Табигать тә үзгәрде.
Килә язлар, интеккәндә
Озаталмыйча күзләрне.

Күктә яз кояшы балкый,
Онытып дөньяви уем,
Күзәтеп торам тәрәздән
Чыпчыклар елмаюын.

Сөяккә җылы йөгергән,
Туңса – шул җаным туңа.
Дөнья да чишенеп ташлаган,
Дөнья – анадан туma.

Яфрак ярып маташуы
Саташкан алмагачның.
Рухы өйгә кермәсме дип,
Тәрәзне киереп ачтым.

Тышта әрсез гөрләвекләр,
Тышта бураннар эри.
...Тәрәзәмдә умырткасы сынган
Яфрак көлемсери...

# ҖИҺАНГИР

Безнең кебек түземсез ул.
Үз дигәненә тиз генә
Ирешмәкче. Шундый ым бар
Пәрәвез сарган йөзендә.

Урманнар яна төтенсез.
Бу – Көз дәгъва итә көнгә,
Җәй инде кызлар шикелле:
«Кирәк түгел»,– дип үтенә.

Фасылара хәл асылы
Шундый кыен икән әле...
Яфраклар десанты төшә:
Җәйнең барлык өлкәләре
Иртәме, соңмы яуланыр.
Язмышның булмый ялгышы...
Көз менәр үз тәхетенә,
Җиһангир сыман сагышлы.

# КИЗЛӘҮ

Күзнең бозлы җиле исте:
һавадагы пәрәвезләр
әкрен генә йөзгә күчте.

«Үзгәрде әшьялар төсе...» –
салкын йолдызлардай күчте
төнге учакларның исе.

Селтәп атты аргамагым:
акбүз әләм сулышыдай
дерелдәде бармакларым.

Кирәк микән кулны изәү? –
тибеп ята кар астында
ялгыз кизләү...

# ХАТИРӘЛӘР

Дәрья яры буйлап киләбез без.
Шәүлә дә мин. Барам елышып.
Ком өстеннән мыштым җил шуыша –
Тәнне пешерә дәрья сулышы.

Дәрья яры буйлап киләбез без,
Моң ишелә өскә, түз генә...
Баскан саен ком сискәнеп куя,
Баскан саен үзәк өзелә.

Ком кымшанып куя – нинди ым бу?
Нинди тәгъбир, аны кем белә?
Йөрәгемдә минем тынлык бүген,
Тынлык йөрәгендә – зилзилә!

Дәрья яры буйлап киләбез без,
Шул эзләргә карап,– и хәтер! –
Мең елдан да мине – ком бөртеген –
Хатирәләр килеп имгәтер.

# ТӨРБӘ

Нарат исе аңкый өй эчендә бүген,
Төн кымшана тышта эзләп ышык урын.
Тәрәзәне ватып сикерермен кебек,
Көнгә йөгерермен таңга кермәс борын.

Яңа актарылган буразнадай симез,–
Үреләдә бу төн тәрәзәмә чиртә.
Монда утырырга инде бик соң бугай,
Көнгә кузгалырга әле артык иртә.

Мичтә дөрләп яна каен пүләннәре!
Таңга кадәр безгә шулкадәр дә ерак.
Мин учакка карап оеганда тып-тын,
Җыр әйләнеп кайтыр урманнарны урап.

Таныш түгел кошлар очалардыр анда.
Карлар сирпеләдер канат очларыннан.
Бөтереләдер җилдә салкын тынын бөркеп...
Мәхрүм итмә төнне, Тәңре, ак карыңнан.

Кочып ала мине кысып ут шәүләсе,
Туймас кызлар сыман җибәрмәскә тели,
Керфекләрем тишкән төннән дегет саркый,
Беркем күренми тик, берни ишетелми.

Ышык урын эзләп, төн кымшана тышта,
Дөрләп яна мичтә каен пүләннәре!
Beләм: өстә-өстә вак йолдызлар пыскый,
Шыта аста җәйнең аксыл үләннәре.

Кавыштырып өйне күк гөмбәзе белән,
Багана күк гүләп күтәрелә төтен.
Мин әрвахлар белән – Мөхәммәдьяр төсле –
Шагыйрь өчен һәрчак хан төрбәсе бу төн...

# РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА ТУРЫНДА КАЛӘМДӘШЛӘРЕ

* * *

Казан дәүләт университеты студенты Ркаил Зәйдуллинның дүрт шигыре басылып чыккан. Яратам мин бу малайның шигырьләрен, өметем зур ул егеткә. Мин аңарда иҗат кешеләренә иң кирәкле сыйфат – тынгысызлыкны күрәм. Җаны тынгысыз аның, яшьлеккә хас бунтарьлыгы да бар. Бик әйбәт. Яшь чакта да бунтарьланмагач, картайгач ни кала? Мыштым гына каш астыннан карап йөргән малайлардан куркам мин. Чаттан торып бирәр этлек эшләп, җанны өшетерләр сыман. Әдәбият ачык йөрәкле (душа нараспашку) затларны яратарак төшә.

*Туфан Миңнуллин*
*(Казан утлары, № 5, 1983)*

* * *

Миңа бүгенге шагыйрьнең гадәти тормышта әлегәчә беркем дә абайламаган матурлык һәм гариплекне күреп алуы, шуны хәленнән килгәнчә әйтеп бирүе кыйммәт. Үз учында пешә-пешә алып килгән ут белән үрләтеп җибәргәндә генә аның шигырь учагы укучыны җылыта ала. Яңа шигырьләрен укыган саен ышана барасың: сүздә саксызлыкларын, бераз поза ясауларын искәрткән хәлдә дә – яшьләрдән әлеге юлга иң якыны Ркаил Зәйдуллин бугай. Яшь шагыйрь кайбер күренешләрне бәяләгәндә кайнарлана, ашыга төшә, хикмәтен табып өлгерә алмый. Ләкин бу әлегә аның кимчелеге түгел, бу аның иҗади кыюлыгы турында сөйләүче билге: ягъни Р.Зәйдуллинның тормыш катламнарына шагыйрь буларак үз кордашларыннан алдарак, тирәнрәк үтеп керүе нәтиҗәсе.

*Салих Маннапов*
*(«Сезгә ышанам», ТКН, 1984)*

* * *

Минемчә, шигъри иҗат үзеннән алда яшәгән шагыйрьләргә булган ихтирамнан, мәхәббәттән башлана. Ркаил дә борынгы җырчылар – Кол Гали, Мөхәммәдьярларның каберләрен эзли, бүгенгегә, киләчәккә аларның изге зиратлары аша карый, «Һәммәбездә шул Такташлар каны, вакыт-вакыт уты ала көйрәп» дип белдерә, ул утлардан үзе дә «нәни генә учак тергезә». Мөхәммәдьярларның дөрләп янган хатларының җылысын саклаган, туган туфракта үзе тергезгән учак.

Шигъри сүзне яратучылар бу нәни учакны ерактан ук күреп алырлар һәм аның янына җыелырлар дип ышанам. Ә яңа учак кабызучы егерме ике яшьлек егетнең әйтер сүзләре заманча кыска, саллы, үтемле...

*Илдар Юзеев*
*(«Кояшлы күзләр» китабына кереш сүз, ТКН, 1984)*

* * *

Успех его первого поэтического сборника не был неожиданным. Молодой поэт, естественно, стремится передать свои мысли без ложной помощи лжемудрых, лжемощных слов. Он прекрасно понимает, что читателя надрывом не проймешь. Порывистость чувств, смелая и образная игра мысли требуют разнообразия стихотворной формы. И поэт, к счастью, лишен нудной монотонности.

Поэма-размышление о жизни Хасана Туфана говорит о полной гражданской зрелости Р.Зайдуллина. Судьба великого поэта стала для него своеобразным разрезом, где видны глубинные пласты судьбы личности и родного народа. Материал поэмы Ркаила Зайдуллина сугубо современный. Но поэт пропитал его тугим воздухом истории. Получился крепкий, органический сплав истории и современности. Сплав, одухотворенный личностью поэта Хасана Туфана.

*Зульфат*
*(Рекомендация для вступления в Союз писателей СССР. 1984)*

* * *

Еш кына калын-калын шигырь томнарыннан да хәтергә уелырлык, күңел мөнбәренә шәмаил итеп эләрлек зур фикерләр, күзгә ташланырдай шигъри картиналар табу кыен. Ркаилдә алар бар.

Ркаил катлаулы образлар белән шаккатыруны максат итеп куймый, аның табышлары табигый, шигырьнең эчке хасиятеннән килеп чыга, шагыйрь гадәти сүзләрне хисле, экспрессив, югары көчәнешле итеп бирүнең серен белә.

*Әхмәт Рәшит*
*(Идел, №4, 1989)*

* * *

Р.Зәйдулланың лирик героена, гомумән, вакланмаска тырышу, егетләнү, тормыш-яшәеш мәсьәләләрен бер талпыныш, бер селтәнү белән хәл итәргә омтылу, көчле кешеләрчә яшәргә теләү хас.

Шуңа күрә дә мин «торгынлык чоры» дигән төшенчә әле тумаган да бер вакытта менә шул афәтне җаны-тәне белән сизеп, аның асылын тоеп алган шагыйрьнең, уйлап-уйлап та уйларының очына чыга алмаганнан соң, эчендә кайнап күтәрелгән җан ачысына түзә алмыйча:

Никтер шушы кырмыска оясын
Таяк тыгып болгатасы килә,–

дип әйтүеннән гаеп тапмыйм. Шагыйрьнең нинди кырмыска оясын болгатмакчы, актармакчы булуы аңлашыла ич. Бүгенге акыл югарылыгыннан караганда, көн кебек ачык: яшь шагыйрьнең кайчандыр «хулиганлык» дип бәяләнгән күңел омтылышы, асылда, аның торгынлык чоры тәртипләренә карата бик табигый, хәтта самими реакциясе булган. Дөрес, оя туздыруның ниндие дә яхшы түгел инде аның, бу мәсьәләдә Т.Миңнуллин белән килешмичә ярамый. Ләкин без торгынлык дәверенең хәмер парларыннан сөрсегән һавасына, күңелләргә ябышкан, шакшы пәрәвез сыман сарылган рәсми ялганнарына, кешене бөҗәк хөкемендә яшәтүгә корылган тәртипләренә каршы баш күтәргән япь-

яшь (егерме яшьлек!) шагыйрьне аңларга, аның бу изге омтылышын тәкъдир итәргә бурычлыбыз.

*Фәиз Зөлкарнәй*
*(«Чакма чакмый ут чыкмый», ТКН, 1991)*

* * *

Күк темасы – Ркаил иҗатын үзенчәлекле итә торган кызыклы темаларның берсе. Нәкъ менә шушы «Күк поэтикасы»нда ул Такташка якыная, аның шигъриятенә хас традицияләрне дәвам итә. Ритмик иркенлек ягыннан да (шунсыз мөмкин дә түгел, җир – күк арасындагы очсыз-кырыйсыз хыял очышын бирү өчен кирәк ул), поэтик байлык, образларның, символларның егәрлеге, фикер куәте ягыннан да. Әмма бу тема ниндидер катып калган, абстракт яисә мистик тема да түгел. Бу – беренчедән, авторның башта ук үз өстенә алган көрәшчелек вазифасын искәртеп тору өчен кирәк булса, икенчедән, аның романтик рухы, бай фантазиясе, көчле гомумиләштерү сәләте хакында сөйли.

*Галимҗан Гыйльманов*
*(«Көрәшә» китабына рецензия // Социалистик Татарстан, № 185, 12.8.1988)*

* * *

Ркаилнең кайбер шигырьләре беренче карашка шактый ук тупас, усал кебек тоелырга мөмкин, шигырьләренең күбесендә ритм, көй булмау да моны көчәйтеп җибәрә. Әйтерсең ботаклы-сатаклы кытыршы каен тактасы, кайсы якка ышкыласаң да, ышкы тимере килеп төртелә. Бу беренче карашка шулай. Ә менә ныклап игътибар итеп уйлап карасаң, бу – шагыйрьнең шактый ук көчле бер чарасы икән: шигырь шома гына үтеп китми, сискәндерә, уйландыра һәм... авторның болай әйтергә хаклы икәненә ышандыра.

*Нәҗип Нәкъкаш*
*(«Көрәшә» китабына рецензия // Казан утлары, № 9, 1989)*

* * *

Ркаил шигырьләренең тирән мәгънәле эчтәлеге белән танышуны укучының үзенә калдырып, биредә үзебезнең бер зур куанычыбызны гына әйтеп узасы килә. Шагыйрь зур Шигърият юлына килеп чыккан. Иң авыр, иң олы каршылыклар тупланган юлга аяк баскан. Талант һәм каһарманлык иң күп сорала торган юл ул... Бу гасырның башында Тукайлар атлаган юл! Гасырның ахырында, инде гасыр тәмамланып килгән чагында, Тукайча әнә шундый кыю аһәңле яшьләрнең ул юлны дәвам итүе – татар укучысына гына түгел, ә тулаем татар милләтенә дә бик зур куаныч!

*Мансур Вәлиев*
*(Казан утлары, № 3, 1990)*

* * *

Ркаил – таланты бик яшьли ачылып, шигърият мәйданына егерме яшендә үк яңа бер дулкын булып, аны яңа төсләр, рухи ярсулык белән баетып килеп кергән егетләрнең берсе.

Укучының үзәгенә үтәрдәй итеп язылган шигырьләре байтак Ркаилнең. Шунысы да игътибарга лаек – шагыйрь нәрсә турында гына язса да, үзе сурәтләгән күренешләр белән бәйләнештә булуын белгертмичә калмый. Шагыйрь бер генә вакыйгадан да читтә түгел, бернәрсәгә дә битараф түгел.

Р.Зәйдулланың шагыйрь буларак зурлыгын сөйләүче тагын бер үзенчәлеге – тема киңлеге. Анда, кайбер шагыйрьләрдәге кебек, шигырьдән шигырьгә кабатланып килә торган таныш темалар, кабатлана торган сурәтләр юк. Аның мәхәббәт лирикасы да «елаучан» сагынуга, моңлануга гына кайтып калмый. Нечектер кырыс, җитди, уйчан лирика.

*Рафис Корбан*
*(Шәһри Казан, 26.10.1990)*

* * *

Безнең заман шагыйрьләре, адашып та, кармаланып та, шигъри кыйблаларын каян гына эзләмиләр! Әмма үзебезнең изге милли мирастан, классик шәрекъ әдәбияты җәүһәрләреннән, элгәреләребез тудырган рухи байлыктан бик нык ераклашкан идек... Әнә шуңа күрә дә, кинәт асылыңа кайтып тәүбә иткәндәй, Коръәнгә иелеп, аның аятьләреннән илһам алу шагыйрь өчен дә, укучы өчен дә нык тансык булыр, мөгаен.

Әйе, бу яңа сүрәләр – вакыты җитеп илаһи вәхи алган Ркаил «пәйгамбәр»неке. Шигъри тәфсирләр дип атала. Бу – Пушкинча кыюлык, рухи эзләнүләр мисалы. Шагыйрьнең ташкын хисе, яшьлек көче борынгыдан килгән фәлсәфи нигезле, иман һәм илаһият белән ныгытылган лабаса! Афәрин! – диясе килә. Ә теле? Сурәтлелеге? Берсе дә шигъри «уен» өчен түгел, бәлки камил, тормышчан, олпат фикерләү җимеше, Тукайча омтылыш хәрәкәте...

Ниһаять, кайчандыр өзелеп, күп төймәләрен без югалткан изге дисбебезне яңадан кулга алабыз, ахры.

*Рәдиф Гаташ*
*(Ватаным Татарстан, 4.9.1992)*

* * *

Шагыйрь Ркаил Зәйдулла катлаулы Казанны Алла биргән сәләте белән авызлыклый алды.

Ләкин Казан ардыра торган шәһәр...

Шагыйрь күктәге Чүмеч йолдызының торышына карап сусый башлый: бу шәһәрне ташлап торырга вакыт җиткән. Туган авылына кайтып, ул әнисе бисмилла әйтеп сауган җылы сөт эчә, кайнар мунча тәрәзәсеннән бәрәңге бакчасына карап илһамлана, кытыршы кәүсәле өянкеләргә сөялеп, муенга-муен «кочаклашып» иркәләнгән атларны күзәтә, әрекмән яфрагыннан егылып төшкән кырмысканы учына ала, мич төбендә пешкән арыш ипиенә батып кергән күмер кисәген тешләп карый, ма-

лайлык тәхетенә менеп, күккә кадакланган тилгәнгә бармагын төби, кабыгын салып, үз-үзен яңарта белгән еланга карап гыйбрәт ала. Шушы эчкерсез табигать, офык аръягынача җәелгән олы дөнья булып, шагыйрьнең йөрәк сулкылдавына кушыла. Хыялында гасырлар, илләр убыла. Ул дөньяны, сүз кодрәтенә буйсындырып, яңабаштан сүтеп җыя. Җыя да, комнан йорт төзегән сабый кебек, самими бер алгысыну белән, соклану, әрнү, ачыну хисен бүлешү өчен аркадашлары хозурына ашкына башлый. Аңа бу хисләр белән тизрәк бәхилләшергә кирәк, алда – шигырь баганаларына таянасы яңа гөмбәзләр калкырга тора. Шагыйрь иген үстергән авылыннан фикер үстергән Казанга ашыга.

*Марсель Галиев*
*(Шәһри Казан, 29 август, 1992)*

* * *

Төрк дөньясында яңарыш һәм җирләшү агымнарының татарлар арасында Тукай һәм Дәрдемәнд кебек көчле исемнәрне дөньяга чыгаруы бүгенге татар әдәбияты өчен дә сәламәт бер традицияне мәйданга китерде. Ркаил Зәйдулланың шигърияте дә гамәлдә бу көчле әдәбиятның мирасына үз өлешен өсти.

Шагыйрьнең китабындагы шигырьләр эчендә «Күлтәгин ташы» бигрәк тә дикъкатебезне җәлеп итте: белгәнебезчә, Совет дәверендә Урһун ядкарьләре турында тел мәсьәләләренә кагылышлы бик күп хезмәтләр язылса да, яшьләрнең бу хакта һичбер мәгълүматы юк иде. Шул сәбәпле татар әдәбиятының иң яшь буынына мәнсүп бу шагыйрьнең, «Мин– Күлтәгин ташы!» диеп, бер кыюлык белән каршыбызга чыгуы гаҗәпкә калдыра.

*Мостафа Өнәр, төрек язучысы*
*(Төрк культуры, Анкара, № 374, 1994)*

* * *

Пора мужской зрелости, осознание своей силы... В некотором роде развязка, когда образ двуликого Януса, олицетворяющего замечательный символ Входа и Выхода, ясен и приближен. Именно в такой точке находится Ркаиль Зайдулла: трудно жить, но прекрасно быть в объятиях жизни.

От стихов поэта веет здоровьем мятежного духа. Он знает, что за словом стоит мучительно добываемый опыт души и музыка усилия сердца. Бесполезных, проходных строк у него нет. Душа его – о достоинстве, мужестве, отечестве. Он ощупывает свою корневую систему, а не шарит попусту руками, не восклицает, но говорит о необходимом, а это глубинное, прочувствованное проживание, не мельтешение на подмостках. Мосты держать важнее!

*Рустем Кутуй*
*(Казань, № 3–4, 1995)*

* * *

Соңгы елларда әдәбиятыбызда борын төрткән күренешләр арасында әдипләрнең, бигрәк тә яшьрәк әдипләрнең милли тарихка йөз белән борылуын мин сөенеп күзәтеп киләм. Алар халкыбызның ерак үткәненнән рухлары өчен аерым бер мәгънә, көч-мәдәт алырга, милләтнең катлаулы язмышын тирәнрәк аңларга омтылалар. Шундый әдипләр арасында Р.Зәйдулла үзенең тарихи прозасы, көн кадагына сугып язылган кайнар сулышлы публицистикасы белән аерылып тора.

Ул иҗат юлын шагыйрь буларак башлап җибәрде. Әйе, чал тарихка игътибар, халкыбыз үткән катлаулы дәверләр турында уйлану аның шигырьләрендә дә үзен гел сиздерә килде. Аларда шулай ук әйтеп үтелгән публицистик ялкын, тормыш күренешләренә битараф булмау да көчле агымны тәшкил итә иде. Соңгы елларда Р.Зәйдулла, шигырь кысаларына гына сыймыйча, акрынлап прозада да көч сынап карый.

Әсәрләре белән танышканнан соң, безнең алда заман су-

лышын нечкә итеп, аның проблемаларын йөрәк аша үткәреп, замандашыбызның рухи ихтыяҗын тирән аңлаучы, һәр язган сүзе белән аның фикерен кузгатырга, күңеленә тәэсир итәргә омтылып яшәүче язучы образы килеп баса.

*Солтан Шәмси*
*(Идел, № 4, 2000)*

* * *

Ркаил Зәйдулла заман һәм җәмгыять, милләт һәм кешеләр турында усал итеп, әрнеп, ләкин аңларга тырышып түгел, ачыктан-ачык гаепләп, «маңгайга бәреп» сөйләүче шагыйрь. Шигърияттә генә түгел, чәчмә сүздә дә шулай икән. Ркаилнең тоткан юлы, кыйбласы бер: ул җәмгыятьне дә, шәхесне дә аямый, турысын әйтә, бәяли, гаепли... Шигърияттәге лирик героеннан да усалрак автор-хикәяләүче үзендә югарыдан торып сөйләрлек көч таба. Ул – хөкемдар.

Р.Зәйдулланың хикәяләрендә әдәбиятка яңа сулыш өрүе күренеп тора. Аның эстетик эзләнүләре, модернистик алымнарга, символларга мөрәҗәгать итүе әсәрләрне укучы өчен дә кызыклы ясый. Укучы үзгәргән, әдәбияттан мәгълүмат түгел, бәлки, стильләштерү, автор сурәте көткән бер вакытта эчке мәгънәне символларга йөкләү – язучының табышы, уңышы.

*Дания Заһидуллина, филология фәннәре докторы*
*(Мәдәни җомга, 18.8.2000)*

* * *

Шагыйрь Ркаил Зәйдулла гаҗәеп оста итеп прозада да яңа образлар иҗат итә.

Киләчәккә син үзең булып фәкать милләтең белән бергә генә, аңа хезмәт итеп, бар сәләт, талантыңны хезмәт иттереп кенә бара аласың. Диңгезләр тамчылардан җыела икән, милләт җаны аның һәр кешесеннән җыелмый нидән җыелсын инде... Шаһгалиләр тарката башлаган татар баласы язмышы Ркаилнең һәрбер хикәясенә күчеп кергән.

Ркаилнең һәр хикәясе үзенә бер ил, аларның һәрберсенең үз мантыйгы, үзмаксаты, фәкать шушы хикәядә, шушы ситуациядә генә үз асыллары ачыла ала торган шәхесләр икән.

Без зур проза осталарының үзенчәлекле шәхесе белән очрашабыз. Татар әдәбиятында Ркаил Зәйдулла биләгән урынны мин шулай билгеләр идем. Ә инде төрки әдәбиятлар арасында татар әдәбиятының тоткан урынын билгеләсәк, Ркаил Зәйдулла дигән язучыбыз төрки әдәбият дөньясында да үз биеклегендә кала.

*Нәҗибә Сафина*
*(Казан утлары, № 12, 2000)*

* * *

Я знаком с творчеством большинства писателей Татарстана. Из сороколетних – Ркаиль, пожалуй, самый интересный. Его стихи уже получили высокую оценку у любителей поэзии и критиков, у его прозы таковая пока еще впереди. Много читающий, внимательно следящий за новинками литературы, Ркаиль мягко, но настойчиво раздвигает рамки традиции в татарской прозе. Он хочет и умеет быть занимательным, настойчиво добивается любви широкого круга читателей – и не только татарского. Похоже, ему это удается.

*Сергей Малышев, 2002*
*поэт, заслуженный работник культуры,*
*лауреат Державинской премии*

* * *

Ркаилгә хас тыйнак кыскалыктан туган әдәби төгәллек, подтекстка төеп тутырган фикер тыгызлыгы... Кем ярыша ала бүгенге татар прозасында Ркаил Зәйдулла белән?

Әсәрләрендә – татар милләтенең фаҗигале язмышы, аның рухи-мәдәни, дөньяви-җәмгыяти йөзе.

*Миргазиян Юныс*
*(Татарстан яшьләре, 25.7.2002)*

* * *

Ркаил Зәйдулла, үз әсәрен дөньяга тәүге тапкыр күрсәтер өчен (мишәр егете бит), Камал театры сәхнәсен сайлап алды! Асылынасың килсә, асылын агачның асылына, ди безнең халык – аны күздә тоткандыр иде... һәм – ялгышмаган булып чыкты. Беренче пьесасын кемнән куйдырды, диген әле – Марсель Сәлимҗановның үзеннән! Хәзерге вакытта аның «Саташкан сандугач»ы, чут-чутларын еракларга ишеттереп, өздереп сайрый.

*Ризван Хәмид*
*(Казан утлары, № 4, 2002)*

* * *

Ркаил Зәйдулла сүз, матбугат ирегенә юл куелгач кына формалашкан шагыйрь түгел. Ул әдәбиятка бик тә яшьли, 70 нче еллар ахырында ук килеп керде. «Казан утлары» журналында беренче шигырьләр шәлкеме басылып чыкканда, аңа әле нибары унҗиде генә яшь иде.

Ркаил – табигате белән мәйдан шагыйре. Мал иясенә охшый дигәндәй, Ркаилнең шигырьләре дә үзенә охшаган– алар да кызу канлы, ярсу, җилбәгәй...

Ркаил – төрки-татар тарихын үзлегеннән өйрәнеп, шактый бай мәгълүмат туплауга ирешкән шагыйрьләрнең берсе. Шуңа да иҗатында тарихи темаларга кыю мөрәҗәгать итә, тарихи материалларны шигъриятендә дә, проза, публицистикасында да мул файдалана.

Ркаил иҗатта беркайчан да сәяси конъюнктура белән шөгыльләнмәде. Торгынлык чорында да, хәзер дә. Совет дәверендә иҗат иткән бик күп элгәрләреннән һәм остазларыннан аермалы буларак, шагыйрьнең иҗатында системага турыдан-туры хезмәт иткән идеологик опуслар юк дәрәҗәсендә. Ә 1917 елдан соңгы татар шигъриятендә андый шагыйрьләр бармак белән генә санарлык.

*Газинур Морат*
*(«Җәяүле кошлар», ТКН, 2002)*

* * *

Күзгә күренгән өметле яшьләр безнең өчен һәрчак әдәби киләчәк булды –сөенеп каршыладык. Ркаил Зәйдулланы, мәсәлән. Мәктәптән килде. Кызыклы шигырьләр, хәтта поэма белән килде, һәйбәт шагыйрь булып җиткән иде. Ә ул... тотты да прозага – чәчмәгә күчте. Әйбәт чәчмә әсәр – «Ил» китабын язды; бу – проза гына түгел, шигъри чәчмә дә...

Заман болганды.

Заман үзгәрде.

Заман акчалы шөгыль сорый башлады. Ркаил моңа әзерлекле иде – һәр жанрда шагыйрьлек ята! Шуңа да ул «Саташкан сандугач» исемле сәхнә әсәре белән Камал театры сәхнәсенә күтәрелде. Әмма мин аны шигырьдән китте дип санамыйм...

*Мөдәррис Әгъләм*
*(Казан утлары, № 1, 2003)*

*P.S.: Биредә, билгеле, минем хактагы уңай фикерләр генә. Киреләрен кем инде китабына кертсен? Хәер, теләгән һәр кешегә, үз бәһасен теркәп куяр өчен, шушында буш урын калдырам...*

*Автор*

# ЭЧТӘЛЕК

## I БҮЛЕК

Өмет . . . 7
Хәлвә . . . 8
Бурыч . . . 8
Төсләр . . . 9
Бабай . . . 10
Әби . . . 11
Яз –1979 . . . 12
Каен кызы . . . 12
Уен . . . 13
Үзгәреш . . . 14
Дәрес бара . . . 14
Сабакташ . . . 15
«Типте тупны...» . . . 16
Көтүче малай . . . 17
Качкын . . . 26
Мөгездәге йолдыз . . . 26
Хәбәр . . . 27
Малайның бозау белән хушлашуы . . . 28
Авыл малае . . . 29
Яңгыр. Болын. Ат . . . 30
Төнге рәсем . . . 31
Рәхмәт . . . 31
«Карт этне...» . . . 32
«Өй артында...» . . . 33
Сәрви куагы турында түгел бу шигырь . . . 34
Каз өмәсе . . . 35
Тупыл . . . 36
Буран . . . 37
Кышны озату . . . 38

Көрәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
«Бәреп чыккан дөньялыкка...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Зилзилә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
«Түбәдә шыбыр-шыбыр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Печән өмәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Алма бакчасында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
«И серле күл!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
«Тарта мәллә һаман туган җирләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Булмый елап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Яңгыр гына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Ике оч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Вәхши . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Келә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Шәһәрзадә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Минем кайбер әйберләр белән хушлашуым *(Көндәлек)* . . . . . . . . 54

## II БҮЛЕК

Дала җиле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
«Без очарга әзерләнгән идек...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Челтәр аша . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Ихласлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Чит җирдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Гомеремнең... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Чакыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
«Җәйрәп ята...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Йокысызлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Кавышу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Киләчәккә хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Күз яше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Озатмагыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Дәвам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77

## Багышлаулар

Аяз Гыйләҗевкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Мәһди өне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Сыктау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Эдуард Мостафин рухына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Фәннур Сафин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84

Бозваткыч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Ул төн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Рөстәм Мингалимгә бер мишәрнең монологы . . . . . . . . . . 87
«Кара кошлар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
«Ык өстеннән күләгәләр шуа...» . . . . . . . . . . . . . . . . 89
«Зыңлап тора һава бу далада...» . . . . . . . . . . . . . . . 90
«Чапты атлар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
«Без сабыйлар иленнән бит, дустым!..» . . . . . . . . . . . . 93
Битлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Бәхәс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Тулай торак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Исемсез кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Олтан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Портрет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Халәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Истанбул базары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Эчтем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Яралгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Балта осталары *(Пермь дәфтәреннән)* . . . . . . . . . . . . . 105
Ишек ясый Гали-баба . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Төш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Шаулый урман – яңгыр килә, ахры . . . . . . . . . . . . . . . 108
Ат абзарында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Максатсызлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Таптый язды... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Әрлән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Бөҗәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
«Урам чаты...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Аһ-зар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
«Көзне күзләп барам...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Күпер *(Поэма)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116

## III БҮЛЕК

Еллар аша . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
«Бернинди аваз...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
«Үлән ерып...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Шәһри Болгар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Күргәзмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Нәни бер сер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134

Тыңлыйсыңмы?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
«Яна йөрәк...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Саубуллашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
«Сәфәр китәм ...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
«Битараф идем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
«Җир белән күк...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
«Нигә моңаясың?» – дисең...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
«Чәчәктән чәчәккә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Үкенү хисе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
«Кил, сөеклем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Бер өмет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
«Йомылдылар йолдызларым...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Бер сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Манзара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Юкәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
«Нигә аңа тартыласың...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Сахраларда, суда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Ике кызый... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Капка төбендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Сүзем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Кыз урлау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Чаган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Мәҗүси догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Көзге урманда төнлә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
«А, чибәрлек!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Әрәмәлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
«Җирдә язлар!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Алмагач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Чияләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Туйлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
«Барча шигыремне...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
«Җиргә караңгылык...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Сабыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
«Җемелдәп китте төш...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Сау бул! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
«Яратамы, яратмыймы?..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
«Мин камышка сине...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
«Мин сине яратмадым...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Сонетлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Сине көткәндә, таныш түгел кеше... . . . . . . . . . . . . . . 165

Яңа елда буйдак башына килгән уйлар . . . 167
Тимә . . . 168
Гайбәтчеләргә . . . 169
Туй . . . 170
«Бүлмәмә ул керде...» . . . 170
Хәрчәүнә . . . 171
«Итәгеңнең җиле...» . . . 172
Җайдагат . . . 172
Тәшвиш . . . 173
«Мин янам, шатланам...» . . . 173
Үтенеч . . . 174
Әя . . . 175
«Төн караңгысы...» . . . 176
«Мин томанга төренгәндә...» . . . 176
Бу дөньяда . . . 177
«Дарумы бу?..» . . . 177
«Изрәп йоклый...» . . . 178
Хан чатыры . . . 179
«Назлы сүзләрне...» . . . 180

## IV БҮЛЕК

Безнең илдә . . . 184
Карурман . . . 185
Төркләр . . . 186
Лашманчылар . . . 187
Сезнекеме? . . . 188
«Карап торам бүген Казаныма...» . . . 189
Бисмилла . . . 190
Пирамида . . . 191
Чаң . . . 192
Хәтер . . . 193
Утлы көпчәк *(Триптих)* . . . 194
Әхмәт ибне Фадлан . . . 202
XVIII гасыр. Батырша догасы . . . 203
Каләм турында баллада . . . 204
Җәлил кояшы . . . 206
Шагыйрьләрнең каберләрен эзлим . . . 207
Койрыклы йолдыз *(Поэма)* . . . 208
...Көнне күмеп киткән... . . . 238

Таш турында риваять . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 239
Ике фил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Идел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
Төнге әкият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
Нигез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
Татар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
Татар иҗтимагый үзәге әһелләренә . . . . . . . . . . . . . . 244
Эт-татар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 245
«Халкым минем төнгә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Урыс кышын озату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
Һәйкәлләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 249
Ачык балконнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
Төнге сабантуй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Җеп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254
Литва – 1991 . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 255
Alma mater . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
Зиндан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
«Ярга бәрелеп...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 259
Татарстан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 260

## V БҮЛЕК

Шигъри тәфсирләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264
Гомер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 270
«Ташларгамы җанны...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 271
Ә күкләрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 272
Күренеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 272
Күк капусы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 273
Хәсрәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
Зиярәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 276
Кара тәкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 277
Кышкы юл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
Су . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
Ана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
Кичектерелгән сәфәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
Өзелгән дисбедән *(Кыска шигырьләр)* . . . . . . . . . . . . 281
Тузганак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 290
Анатомия театрында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 290
Сәрхуш Сөләйманның миңа әйткән сүзләре . . . . . . . . . . 291
Зират каравылчысы турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292

Соңгы юл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
Таңда хушлашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 293
Тулгак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 294
Тиләләр йортында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 295
Югыйсә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 296
Богауланган Бруно монологы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 297
Ялгыз торна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298
«Җир әйләнә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 299
Матәм *(Поэма)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300
Чишмә *(Риваять)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 325
Әрекмән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 326
Ностальгия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 327
Саташкан кыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 328
Җиһангир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
Кизләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 330
Хатирәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 331
Төрбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 332
Ркаил Зәйдулла турында каләмдәшләре . . . . . . . . . . . . . . . 333

Литературно-художественное издание

*Ркаиль Зайдулла*
*(Ркаиль Рафаилович Зайдуллин)*

**ПЕЩЕРА**

Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х. Корбанов*
Рәссамы *Н.Ю.Воропаева*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.02.2005. Форматы 70×108 1/32. Офсет кәгазе.
«Futuris» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 15,40 + форз. 0,17.
Шартлы буяу-оттиск 15,92. Нәшер-хисап табагы 12,44 + форз. 0,29.
Тиражы 2000 д. Заказ А-94.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.